ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

Төзүчесе Халидә Гатина

Тавил Хаҗиәхмәтов рәсемнәре

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 1974

С(ТАТ) 2
Т 23

Бу китапка тылсымлы әкиятләр белән бергә тормыш-көнкүреш әкиятләре дә, шулай ук хайваннар тормышын тасвирлаган әкиятләр дә тупланган. Аларның кайберләрендә халыкның тирән акылы, эшчәнлеге һәм батырлыгы чагылса, кайберләрендә исә ялкау, саран кешеләрдән һәм башка җитешсезлекләрдән үткен итеп көлелә.

Җыентыкта моңарчы басылмаган яңа әкиятләр дә бар.

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Т $\frac{0762-042}{М132(03)-74}$ 152—74

© Татарстан китап нәшрияты, 1974.

АКЫЛЛЫ КЫЗ

Ярлы гына бер кеше була. Аның бер кызы була. Картны патша чакырта, ә ул бармый.

— И әти, нигә бармыйсың,— ди кызы.

— Куркам,— ди атасы,— аның таганы асулы, * килгән бер кешене астырып тора, мине дә астырыр,— ди.

— Асмас,— ди кызы,— бар. Ул сиңа берничә сорау бирер, ди, шуларга җавап бирсәң, бер нишләтә алмас. Беренче сорау: йөгеректән-йөгерек дөньяда ни йөгерек, дип сорар. Син әйт, йөгеректән-йөгерек куян, аннан да йөгерек күңел дип әйтерсең. Икенче

* Таганы асулы — бу урында дар агачы мәгънәсендә.

сорау: катыдан-каты ни каты, дип сорар. Син, катыдан-каты таш, аннан да каты баш, дип әйтерсең. Өенче сорау: татлыдан-татлы ни татлы, дияр. Ә син, татлыдан-татлы бал, аннан да татлы җан татлы, дип әйт. Син шул җавапларны әйтсәң, берни булмас. Шуның өчен чакыра ул сине,— ди.

Китә карт патшага. Җавапларны әйтә курка-курка гына.

— Бу җавапны кем өйрәтте сиңа, әйтмәсәң мин сине астырам, өнә таган корылган,— ди.

— Әй, кызым әйткән иде лә,— ди карт.

— Синең кызың бик күп белә икән,— ди, бер агач сындырып алып керә, бер чирек * кенә әйбер бирә дә, — шуннан миңа такыя сырсын, күлмәк тексен,— ди патша. Елый-елый кайтып китә карт, мынавы бер чирек әйбердән кеше әйбер тегә аламыни дип.

Өйгә кайтып кергәч кызы әйтә: «Бер дә курыкма, әти, ди, бер агач бирә дә, син аңарга шушы агачны илтеп бир, ул миңа шуннан киндер суга торган станок ясап бирсен, ди, бүтән төрле агач кертмәсен, бертөрле генә булсын»,— ди.

Патша кыз җибәргән агачны алып карый да: «Ай-яй, кызың күп белә икән, ди. Алай булгач мин алты кәҗә тәкәсе җибәрәм, таң атканчы шуларны бәтиләтеп, бәтиләре оргач (ана) булсын»,— ди.

Карт тагын елый-елый алып кайтып китә инде. Кыз кәҗә тәкәләрен курүгә шатлана башлый.

— Безгә яхшы булды бу, без аларны берәм-берәм суеп ашарбыз,— ди.

— Әй, сиңа көлке, патша шул тәкәләрне бәтиләтергә кушты,— ди.

— Бер дә кайгырма, әти, ди, рәте табылыр,— ди кыз.

---

* Чирек — бер метрның дүрттән бер өлеше.

Патша бер көн көтә, икенче көн көтә, кәҗәләр дә юк, үзләре дә килмиләр. Китә үзе патша кызларга. Кыз патшаның килгәнен күргәч, әтисенә әйтә: «Бар, хәзер үк мунчага, мин үзем җавап бирермен»,— ди.

Карт мине алырга килә икән инде дип йөгерә инде мунчага. Патша килгәндә кыз килегә тары салган да тары төеп тора.

— Үзең тары төясең, ди, килеңдә ничә бөртек тарың барлыгын беләсеңме? — ди.

— Әй, падишаһым-солтаным, хәзер генә килеп кердең, сездән безгә хәтле ничә адым булды, санадыңмы? — ди кыз.

— Санап атламадым шул,— ди патша.

— Мин дә тарыны санап салмадым,— ди кыз.

— Атаң кайда? — ди.

— Мунчада, бәбәйләргә китте,— ди.

— Әй, ахмак, ир кеше бәбәйлиме инде, ди. Кая соң кәҗә тәкәләре,— ди.

— Бәй, карт кешегә синең йомышка йөргән өчен аяк җалы кирәкмимени,— ди кыз,— суеп ашадык,— ди.

Патша уйлый: «Тукта, ди, мин бу кызны яучы җибәреп үземә ала алмам микән»,— ди.

Бер дә беркөнне патша яучы җибәрә. Кыз риза була, ә карт:

— Бара күрмә, кызым, икебезне дә астырып үтерер,— ди.

— Юк, ди, кыз, мин барам, бармасам икебезгә дә начар булыр, — ди.

Патша кызны алып китә.

Азмы-күпме бергә торгач, патша яланнарны карап кайтам дип чыгып китә. Чыкканда әйтә: «Миннән башка беркемгә дә хөкем итмә», дип. Патша чыгып киткәч, кыз чарлакка менә дә карап тора. Патшаның хезмәтчеләре эшли. Кайсы кибән куя, кайсы җыя, кайсы нишли шунда. Ике кеше килделәр дә атларын

тугарып җибәрделәр, үзләре печән чаба киттеләр. Обедка кайтсалар тегеләрнең атлары колынлаган. Колын ике тәртә арасында ята, ә үзе печән ашап йөри. Болар икесе дә килгәннәр дә карап торалар. Берсе әйтә: «Бәй, бия колынлаган бит»,— ди. Икенчесе: «Бияме соң, колын тәртә арасында ята бит, арба колынлаган»,— ди. Сугышып кара канга баталар болар. «Әйдә хөкемгә патшага барыйк»,— диләр. Киләләр патшага:

— Патша өйдәме?

— Юк,— ди хатын.

— Кая китте соң?

— Тау башына тары чәчкән идек, шул тарыны көн дә күлдән чуртан чыгып чүпли, ди, шуны карарга китте,— ди.

— Бәй,— дигән берсе,— тау башына чуртан чыгып ничек чүпли ул тарыны? — дигән.

— Чүпли шул,— дигән хатын,— әле сез килдегез бит, бия колынламый, арба колынлаган дип. Кайчаннан бирле шуның өчен сугышасыз. Ничек инде арба колынласын? Барыгыз, кайтып китегез,— ди.

— Без ялгышканбыз икән,— дип кайтып китәләр болар.

Кайтып керә патша.

— Хөкемгә килгән кеше булмадымы? — ди.

— Килделәр, ди, печән чабучыларның биясе колынлаган, ди. Шуңа арба колынлаганмы, бия колынлаганмы икәнне белергә, хөкемгә килгәннәр, ди. Безгә килгәндә сугышып каннары агып тора иде, ничек хөкем итмисең инде,— ди.

— Син нәрсә дип әйттең соң? — ди.

— Менә тарыны күлдән чуртан чыгып чүпли, шуны куарга китте дип әйттем, — ди.

— Әй, — ди патша, — син миннән узып хөкем иткәнсең, ди, мин кайткач килерләр иде, —ди.

— Эш кешесен ничек көттереп торыйм инде, хөкем иттем дә җибәрдем, — ди.

— Юк, ди, безнең сөйләшкән сүз миннән башка хөкем итмәскә иде, ди, мин моңарга риза түгел, бүгеннән аерылабыз, үзең теләгән әйбереңне ал да кит,— ди патша.

— Ярар,— ди хатыны, — бер атнага рөхсәт бир, аннан китәрмен, — ди.

Хатын яхшы иттереп бал куя да бер көнне әйтә:

— Инде миңа китәр вакыт җитте, ди, әйдә китәр алдыннан икәү утырып чәй эчик,— ди.

Хатын эчерә патшаны, теге исереп тә китә. Хезмәтчеләргә әйтә: «Ат җигегез дә патшаны чыгарып салыгыз»,— ди. Ат җигелгәч, патшаны чыгарып салалар. Хатын үзе ат башына менеп утыра да алып китә патшаны. Әй ат белән йөри бу, әй йөри чокырлы җирләрдән, патшаны айныта инде. Патша айнып, сикереп тора да:

— Бәй, нишләп йөрибез без бу яланнарда, — ди.

— Сине үземә алып кайтып барам. Син бит үзең теләгән әйберне ал да кит дидең. Минем теләгәнем син, шуның өчен сине алып китеп барам,— ди хатын.

— Их,— ди патша,— минем хатын үземнән акыллырак икән, миңа шундый хатын кирәк тә. Әйдә, бор атыңны, өйгә кайтабыз,—ди.

Болар яңадан яхшы гына тора башлыйлар. Килгән кешегә икесе дә хөкем итәләр, киңәш бирәләр. Хатын иренә караганда да тугры хөкем итә икән ди.

ҮГИ КЫЗ

Бер ир белән хатын була, аларның бер кызлары була. Бик әйбәт кенә торганда моның әнисе авырып үлеп тә китә. Әтисе икенче хатынга өйләнә. Аның да бер кыз баласы була.

Бервакытны әтиләре тегермәнгә киткәч, кызлар җыярга булалар. Бик күп иттереп, өйне тутырып җыялар болар. Үги кызга ызбада утырырга урын да калмый, шул хәтле күп җыялар инде. Үги ана, сукыр лампага ут төртә дә үги кызның кулына тоттырып мунчага илтеп куя: «Бүгенгә син шунда утырырсың»,— ди. Үзенең эрли торган җепләрен илтеп бирә. Кыз курка-курка мунчада җеп эрләп утырганда ап-ак чәчле бер әби килә тегенең янына. Әби әйтә:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди.

— Әй, әби, бик барыр идем дә мин сезгә, өстемә кияргә күлмәгем дә юк бит, нәрсә киеп барыйм соң,— ди. Шул арада теге карчык йөгереп күлмәк китереп җиткерә: «Мә, кызым, ки»,— дип. Карчык күлмәк китергәч, тагын:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,
Сиңа күңелсез булмас,— ди.

— Әй, әби,— ди кыз,— бик барыр идем дә, минем бит башыма шәлем дә юк,— ди.

Әби моңа йөгереп шәл дә китерә.

Аннан яңадан:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр, —

ди.

— Әй, әби, бик барыр идем дә, минем аягыма киеп барырга читек-кәвешем юк бит,— ди.

Әби моңа йөгереп кенә читек-кәвеш тә китерә. Әби тагын:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди.

— Әй, әби, мин сезгә барыр идем дә, сезгә баргач, ябынып ятарга юрганым юк бит,— ди.

Карчык шундук йөгереп юрган китерә моңарга.

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди карчык яңадан.

— Әй, әби, мин сезгә бик барыр идем дә бит, сезгә баргач ябынып ятарга юрганым булды, баш астыма салып ятарга мендәрем юк,— ди.

Карчык шундук йөгереп мендәр китереп җиткерә.

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди.

— Әй, әби, бик барыр идем мин сезгә, анда баргач кияргә минем алмаш күлмәгем дә, корырга чыбылдыгым да, сөртенергә сөлгем дә юк бит, нишләрмен икән соң,— ди.

Карчык тагын йөгереп кенә кыз сораган әйберләрнең барысын да берәм-берәм китереп җиткерә. Әйберләрен салырга дип сандыкны да дырылдатып китереп бирә дә әйтә:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,

Җитмәгән әйберең безгә баргач булыр,— ди.

Кыз: «Нәрсә генә әйтим икән инде, бөтен әйберем дә булды бит», дип уйланып торганда, таң әтәче кычкырып җибәрә дә, әтәч тавышын ишетүгә карчык юкка чыга. Шуннан таң ата, байтак кына вакытлар үткәч, инәсе: «Кыз нишләп утыра икән»,— дип килеп караса, кыз киенгән, ясанган, зур сандык өстенә утырып, җеп эрләп утыра ди. Хатын бу хәлне күргәч гаҗәпкә кала. Икәүләп сандыкны ике яктан тотып өйгә алып кайталар. Хатын моның әйберләренә бик кызыкты бит инде: «Бүген кичкә үземнең кызымны да мунчага җибәрәм»,— ди.

Тагын шулай күп итеп кызлар җыялар, үги кыз өйдә кунаклар янында кала, ә үз кызын сукыр лампа яндырып мунчага илтә. Бераз утыргач, әлеге әби-карчык килеп керә дә:

— Әйдә, кызым, безгә,
Безнекеләр байлар,
Ашыйлар да эчәләр,
Уйныйлар да көләләр,—

ди.

Үги кыз сөйләгән була бит инде ничек баюы турында. Бу да тегенең кебек:

— Әй, әби, бик барыр идем дә, минем өстемә киярге күлмәгем юк бит,— ди.

— Әй, җүнсез, ди, ник алдыйсың мине, өстеңә кигән күлмәгең нинди яхшы. Әле сиңа һаман җитмимени, кичә дә миннән нихәтле әйбер ташыттың, бүген тагын шулай эшләмәкче буласыңмы,— дип, теге кызны үтерә дә карчык үзе күздән югала.

Иртә белән әнисе: «Кая, кызым әйберләрен алып кайта алмый торгандыр», дип мунчага барса, ишекне ача алмый. Бик каты итеп тартып җибәрсә, ишек ачылып китә, кыз идәндә ята. Әнисе мунчага җибәреп үги кызны үтертмәкче булган икән, үз кызы үлеп калган. Шуның өчен халык: кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең, дигән.

БАШМАК

Борын бер бабай яшәгән. Аның бер малае булган. Аталы-уллы яшиләр болар бер начар гына өйдә. Үләр вакыты җиткәч бабай малаена әйтә: «Балам, ди, минем сиңа калдырырлык бернәрсәм дә юк инде, тик бер башмагым гына бар. Кая барсаң да шуны калдырма, ул сиңа кирәк булыр,» ди.

Озак та үтми бабай үлә, улы ялгыз кала. Егеткә атасы үлгәндә унбиш-уналты яшьләр була.

Егет уйлый-уйлый да дөнья гизәргә чыгып китәргә була. Әтисенең сүзен исенә төшереп: «Тукта, ди, кая булса да барсаң, башмакны калдырма үзеңнән дип әйткән иде бит»,— ди. Башмакны сумкасына салып, юлга чыгып китә бу. Аягына кияргә бернәрсәсе дә булмый моның, яланаяк китә.

Бара-бара моның аяклары авырта башлый да, сумкасындагы башмагы исенә төшә. «Тукта, ди, башмакны алып киим әле»,— ди. Башмакны алып кигән иде, аягына җиңел булып китте. Башмак үзе атлап китте, музыка да уйный башлый. Моның күңеле ачылып китә хәзер.

Ярый, бу шулай бара иде, моңа бер кеше каршы очрый. Ерактан карап тора, бу шул хәтле шәп килә, исе китә моңа. «Тукта, ди теге кеше, миңа башмагын сатмас микән»,— ди, уен-көлке белән килә бит егет.

Әлеге кешенең кулында бәләкәй генә капчык белән алтын булган икән, башмагын бирсә, шушы алтынымны да бирер идем дип килә инде бу. Килеп туктыйлар кара-каршы, ял итәләр. Бу кеше әйтә:

— Син бу башмагыңны миңа сат, ди, мин сиңа аның өчен алтын бирермен,— ди.

— Ал,— ди егет, сата бу башмагын.

Теге кеше башмакны аягына киеп киткән ие, йөгертеп алып китә, һич туктый алмый. Көч-хәл белән бер тал янына барып туктый да башмакны салып кулына тота: «Әй, ди, бу шайтанлы башмак икән, үзенә кире илтеп бирим»,— ди. Егет юлда моны карап утыра торган була. Йөгереп кулына башмакны тотып килә дә атып бәрә:

— Мә башмагыңны, ди, шайтанлы икән, үзеңә булсын,— дип әйтә дә үзе йөгерә бирә. Егет тегенең артыннан кычкыра:

— Мә, хет алтыныңны ал,— дип. Теге артына-алдына карамый китеп бара, алтынны да алмады, башмакны да алмады.

Егет башмагын киеп уен-көлке, музыка белән барып җитә бер шәһәргә. Бер бәләкәй генә өйгә керә. Өйдә бер карчык утыра. Егет сорый:

— Шәһәрдә нинди хәлләр бар, әби, — ди.

— Ханның бер малае бар ие,— ди әби.— Шул малае үлде, ди. Аның үлгәненә унбиш ел инде, ди, бөтен шәһәр халкы кайгыда, көләргә дә ярамый. Хан үзе дә сөйләшми, көлми,— ди. Егет әйтә:

— Ничек алай, ди, аны юатырга кирәк, үлгән кире кайтмас, аның күңелен ачарга кирәк, ди. Мин анда барыйм әле,— ди.

— Белмим, улым,— ди карчык,— хан йортына барсаң, аның вәзирләре сине шәһәрдән куар, — ди.

Ярар, бу китә урам буйлап хан йортына таба. Башмагын кигән, уен-көлке, музыка белән бара бу.

Шәһәр халкы моны күреп исе китә. «Бу нинди кеше болай уен-көлке белән килә»,— диләр. Хан йортына җиткәндә ханның вәзире атка атланган, кылыч таккан. Моны куа башлый: «Халыкны бозып, уен-көлке белән нишләп йөрисең», дип. Моны тәки шәһәрдән куып чыгарды бит вәзир. Шәһәр читенә чыккач утырып уйланды бу: «Мин нишләп вәзир куганга карап киттем әле, тукта, яңадан барыйм. Мин ханның күңелен табарга тиеш», дип, яңадан хан йортына таба китә бу, кире бара инде. Әлеге ханның капка төбенә килеп туктый уен-көлке белән. Тагын вәзир күреп куып җибәрде моны. Шәһәр читенә чыгып бераз утыра да яңадан китә егет: «Мине вәзир генә куды бит әле, мин ханның үзен күрергә телим», дип. Уен-көлке белән хан капкасы төбенә барып туктый. Хан берүзе баскычка чыгып утырган икән. Хан сорый солдатлардан:

— Бу нинди тавыш?— ди.

— Әй, бер малай килгән, шулай уен күрсәтеп йөри, — диләр.

Әлеге хан чакырта моны, йортка керсен дип. Кертәләр. Хан үзенең халыгын җыйдыра. Мәйдан ясатып әйтә халыкка:

— Болай яшәргә ярамый, халыкның күңелен күтәрергә кирәк инде,— дип. Егетне куган вәзир дә килеп чыга мәйданга. Килеп чыга да вәзир әйтә:

— Әллә бу малай үзе уйныймы! Аның аягында шайтан башмагы, шул башмак уйный бу музыканы, уен-көлкене, ди, аны шәһәрдән куарга кирәк,— ди. Хан әйтә:

— Алай булгач, син шул башмакны киеп биеп кара әле,— ди.

Әлеге вәзир башмакны алып кия дә биергә төшә инде. Биергә дип бер аягын күтәрсә, икенче аягын кузгата да алмый бу.

— Ә,— ди хан,— башмак биетә дип әйтәсең, ди, нигә үзең биемисең башмак биеткәч?— ди. Унбиш ел буена көлмәгән ханның күңелен ачкан, көлдерткән өчен хан егетне үзенең йортына ала, кызын бирә. Хан үлгәч, халык егетне аның урынына утырта.

Вәзир ханның үлгәнен көтеп йөргән икән. Ул үлгәч, аның урынына үзе утырып, кызын алмакчы булган икән. Шуның өчен егетне үтермәкче булып йөргән икән. Егеткә казыган чокырга вәзир үзе төшкән. Хан вәзирне йортыннан куган ди.

АКЫЛЛЫ КИЛЕН

Бер картның булган икән ди шулай өч килене. Бу карт киленнәрен сынамакчы булган, кайсы акыллырак икән дип. Әүвәле чакырган бу олы киленен. Бераз сөйләшкәннән соң, аңа әйткән:

— Я, килен, әйтерсең микән син миңа, дөньяда нәрсәнең тавышы иң еракка ишетелә!? — дигән.

Килен әйткән:

— Минемчә, әткәй, кыңгырау тавышы еракка ишетелсә кирәк,— дигән.

Карт әйткән:

— Яхшы, килен, бик күркәм җавап бирдең,— дигән.

Аннары икенче киленне чакырган:

— Я, килен, әйтерсең микән син миңа, бу дөньяда нәрсәнең тавышы еракка ишетелә? — дигән.

Бу килене уйлап-уйлап торган да әйткән:

— Минемчә, әткәй, аккош тавышы еракка ишетелә булса кирәк,— дигән.

— Яхшы, рәхмәт, киленем,— дигән.

Инде карт өченче киленне чакырган. Аңа да шул ук сорауны биргән:

— Я, килен, әйтерсең микән син миңа, дөньяда нәрсәнең тавышы еракка ишетелә? — дигән.

Бу килене әйткән:

— Минемчә, әткәй, дөньяда ризык тавышы бик еракка ишетелә,— дигән.

— Ничек ул алай?

Килене әйткән:

— Бер кешене чын күңелдән кунак итсәң, ул кеше ун мең чакрымнар еракка киткәч тә сине исенә төшереп сөйләр, беркайчан да онытмас,— дигән.

Картка моның җавабы бик ошаган.

— Рәхмәт, киленем, бик гакыллы сүз әйттең,— дип, киленен бик мактаган.

КАМЫР БАТЫР

Борын-борын заманда, кәҗә команда, әби-бабай тумас борын, әти белән икәү генә торган чагында, бар иде бер карт белән карчык. Аларның балалары юк иде, шуңар кайгылары бик зур иде.

Бер заман болар исәпләделәр, уйладылар да камырдан бер бала сыны ясап куйдылар. Әби чыгып китте сыер саварга, бабай чыгып китте утын ярырга.

Керсәләр, исләре китте, акыллары таралды: камыр сыны, малай булып, кәҗә бәтиләре белән чабышып уйнап йөри.

Камыр малай төн үсә, көн үсә, ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә. Бабай ясап бирде ди моңа шартаяк. Малай бер таянган иде ди, шартаяк «шарт» итеп сынды ди. Төшеп китте ди бабай тимерчегә, ясатты ди моңа тимер шартаяк. Малай беркөнне урамга чыга — бер малайның аягын сындырып керә. Икенче көнне чыга — икенче малайның муенын сындырып керә ди.

Шуннан соң авыл халкы җыелып бабайга әйтәләр:

— Малаең малай төсле түгел, балаларны имгәтеп бетерә, теләсәң кая куй! — диләр.

Чыгып китә малай дөнья гизәргә. Ай китә, ел китә, бер саплам җир китә. Барып керә бу бер карурманга. Очрый моңа аягын тышаулаган бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп тышауладың бу аягыңны? — ди.

Теге кешè әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди, аягымны ычкындырсам, мин күккә очам, минем арттан кошкорт та очып җитә алмый,— ди.

Камыр батыр моны үзе белән ияртеп китә.

Баралар-баралар, бара торгач, очрый боларга борын тишеген бармагы белән кысып утырган бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай борын тишегеңне кысып утырасың? — ди.

Теге кеше әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди. Югыйсә дөньяда зилзилә куба, бер борын тишегем белән өрдереп тә биш ташлы тегермән әйләндерәм мин,— ди.

Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп китә.

Баралар-баралар болар. Очрый боларга эшләпәсен кырын салган ак сакаллы бер бабай.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай эшләпәңне кырын гына салдың? — ди.

Теге бабай әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди. Мин эшләпәмне туры кисәм, күз ачмаслык буран чыга, басып кисәм, җир йөзенә ике илле боз ката, — ди.

Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

Баралар-баралар болар. Очрый боларга ук төзәп торучы тагын бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нәрсә атасың син болай? — ди.

Ук төзәп торучы әйтә:

— Әәә-нә күрәсеңме, теге тауның кабыргасында, моннан алтмыш чакрым җирдә бер чебен утыра. Шул чебеннең сул күзен атып чыгарам, — ди.

Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп китә.

Тагын китәләр. Беравык баргач, очрый боларга туфрак белән уйнап утырган сакаллы бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай уйныйсың? — ди. Сакаллы кеше әйтә:

— Бу яктан сугам — бу якка тау өям, бу яктан сугам — бу якка тау өям, — ди.

Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

Барып җитәләр болар бер байга, сорыйлар моның кызын. Бай бик кире була, төрле хәйләләр кора.

— Минем кызым — бай кызы, ди, патша кызыннан ким түгел, синдәйләргә тиң түгел, ди. Әйдә, миннән булсын яхшылык, ди, йөгерешчемне узсаң, бирсәм бирермен инде,— ди.

Китәләр йөгерешкә. Аягын тышаулаган егет алтмыш чакрым җирне бер-ике сикерүдә барып җитә дә, бай йөгерешчесе килеп җиткәнче дип, тау өстендә йоклап китә. Байның йөгерешчесе йөгереп мәйданга якынлашып килгәндә теге һаман йоклаган була әле.

Камыр батыр әйтә:

— Ай-һай, ди, бай малае җиңә бит, ди. Ат әле тегеңәр,— ди.

Алтмыш чакрымнан чебеннең сыңар күзен атып алучы кеше атып җибәрә, йөгерешченең колак яфрагын чеметтереп ала. Йөгерешче уянып китә дә мәйданга бай йөгерешчесеннән алда килеп җитә.

Хәзер бай алай итә, болай итә, боларны алдап чуен мунчага яба. Әрдәнә-әрдәнә утын өйдерә, ут төртә, боларны яндырып үтермәкче була. Болар мунча эчендә пешә башлыйлар. Камыр батыр бабайның эшләпәсен туры кидерә — мунча эчендә күз ачмаслык буран кузгала. Алай да пешә башлыйлар ди. Камыр батыр бабайның эшләпәсен бастырып кидертә — мунча стенасына ике илле боз ката.

Икенче көнне бай мунча ишеген ачып җибәрсә, ботын чабып шакката: барысы да исән.

Камыр батыр әйтә бу байга:

— Башымны катырма инде, ди. Алыштанмы, салыштанмы? — ди.

— Алыштан да булыр,— ди, бай әйтә,— салыштан да булыр. Минем сиңа бирә торган кызым юк, көчең җитсә алырсың,— ди.

Китте алыш, китте егып салыш. Шундый алыштылар, шундый салыштылар, тигез җирләр түмгәк булды, түмгәк җирләр тигезләнде. Көн сугыштылар, төн сугыштылар, кич сугыштылар, бик озак сугыштылар. Бер борын тишеге белән өрдереп биш ташлы тегермән тарттыручы кеше борын тишеген сызгырттырып җибәрә — байның егерме кешесе очып китә. Туфрак белән уйнаучы бер яктан сугып җибәрә — утыз кеше күмелә, икенче яктан сугып җибәрә — кырык кеше күмелә.

Камыр батыр күсәге белән бер селтәнә, әллә нихәтле кеше кырылып бетә.

Бай түзә алмаган, кызын бирергә булган ди. Кызны Камыр батырга биргәннән соң, утыз көн уен итеп, кырык көн туен итеп, тумаган ала биянең итен пешереп, бик каты сыйлаганнар ди. Туйларында мин дә булдым, аш-суның чиге юк, бәлешләренең төбе юк, мичкә-мичкә бал куйганнар, үзләре чүмеч белән чумыралар, миңа сабы белән генә әләкте.

ТИМЕРЧЕ МАЛАЕ

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер тимерче. Моның бала-чагасы бер дә булмаган.

Озак та үтми тимерчегә бер айлык юлга чыгарга туры килә — икенче шәһәргә барамы, кая бара торгандыр инде. Киткәндә хатынына әйтә: «Бала туса, мин кайтканчы исем куштырма, ди, мин киткәч, хатын-кыз җыеп утырма», — ди.

Тимерче чыгып китә юлга. Иренең юлга чыгып китүе була, хатын пешекчене чакырта да аш-су көйләтеп хатын-кыз җыя. Мәҗлесне кузгаталар, халык күп, шау-гөр киләләр болар. Кузгаткачтын, мин сиңа әйтим, бер аваз килә: «Эти бер ишектән чыгып китте, син, ди, икенче ишектән хатын-кыз җыйдың»,— ди.

Кунаклар бик гаҗәпсенәләр, бүлмә саен эзлиләр, ишекләр бикле, беркем юк! Бераздан тагын шул ук тавыш килә. Тагын карыйлар, бер адәм заты юк. Бу ни тамаша булды бу?

Ярый, мәҗлес таралды. Икенче көнне хатын балага авырый башлады. Әби алып килделәр. Хатын ир малай тапты. Шундый матур малай ди, алма төсле ди.

Нәкъ шул чакны тимерче хатыны бала тапкан вакытта шул шәһәрнең патша хатыны да бала тапкан. Моның да малае бик матур, ул да күз явын алырлык малай ди.

Ярар. Хәзер бит тимерче кайтыр вакыт җитә инде. Тимерче кайта, үзенең малаен күреп бик куана. Бик зур шатлык булды инде моңарга.

Гомер дигәнең уза бит. Ул арада тимерче малае сигез яшенә дә җитте. Тимерче хатыны белән киңәш итте: «Бу малай тимерче генә булып калмасын, укытыйк без моны», диештеләр. Шулай сөйләштеләр дә сигез яшенә җиткәч малайны мәктәпкә укырга бирделәр.

Ярар. Патша малае да сигез яшенә җитте. Ул да ир малайлы булды бит инде, ул да бик шатланды. Патшаның малае сигез яшенә җиткәч укый башлады.

Укый торгач, тимерче малае шул хәтле ачылып китте, шундый шәп укый, үзенең укытучысыннан да артык белә башлады. Патша малае да шул ук мәктәпкә йөри бит инде.

Көннәрдән беркөнне укытучы әлеге тимерче малаена балалардан имтихан алырга кушты. Бүтәннәр бар да белә, килеп җитте патша малаена чират. Патша малаеннан сорап карады, ул бернәрсә дә белмәде. Бу тотты да, мин сиңа әйтим, тегенең яңагына чалт берне! «Күрәсең, барысы да беләләр, ә син бернәрсә дә укымагансың»,— дип. Патша малае өенә елап кайтып китте инде. Елый-елый килеп керде бу әтисе янына.

— Ник елыйсың, улым? — ди.

— Оят бит, ди, тимерче малае сабагыңны белмисең дип әйтеп яңакка сукты,— ди.

Бу патша малаеның эше шул икән, сабактан кайта икән дә тегендә-монда кәмит карарга чыгып китә икән.

Икенче көнне патша мәктәпкә малаен үзе алып бара. Укытучы янына керә дә әйтә бу:

— Син минем малайны нигә бу хәтле хурлыкка төшерттең, ди, ни өчен син аны шулай тимерче мала-

еннан кыйнаттың? Кайда ул малай актыгы? — ди, гайрәтләнә инде патша.

Тимерче малаен патша каршысына китереп бастыралар.

— Әй, йолкыш малай! Ни өчен минем малайны кыйнадың? — ди патша.

Тимерче малае әйтә:

— Патша булсаң, патша бул син; ди, яхшы гына итеп сөйләшергә дә була, малаең сабагын бернәрсә дә белми бит, — ди.

Патшаның моңа бик ачуы килсә дә эчтән генә, минем малай бернәрсә дә белми микәнни, дип уйлап куя. Шуннан соң патша тимерче малаена каты-каты сүзләр әйтә дә йөрәгенә чыдаша алмыйча, малаен атка утыртып кайтып китә. Юлда барып җитәләр болар бер урманга. Урман буенда бер Идел тармагы була. Патша малайдан сорый:

— Менә, улым, ди, монда урман бар, ди, ә менә монда су, ди. Монда нәрсәләр эшләргә булыр ие микән? — ди.

Малай уйлап-уйлап карый, берничек тә җавап бирә алмый әтисенә. Патша бик күңелсезләнде бу эшкә, минем малайның зиһене юк икән шул дип.

Икенче көнне патша үзенең малае янына утырып яңадан мәктәпкә китте. Яхшы укы дип кертеп җибәрде. Шуннан соң бу теге тимерче малаен чакыртып чыгарып, аны үз янына утыртып алып китте. Чыгып китәләр болар атка утырып. Патша тимерче малаен уң ягына утыртырга теләгән иде, малай әйтте:

— Юк, ди, син олы кеше, син үзең утыр уң якка, — ди.

Хәзер чыгып китәләр болар, бара-бара әлеге урынга да барып җитәләр. Патша сорый моңардан:

— Менә бу урында су бар, монда урман, ди, нәрсә эшләп булыр ие микән монда? — ди.

— Падишаһым-солтаным, ди малай, монда пароход кертергә булыр ие, бу бик зур су бит,— ди.

— Ә менә бу урманны нишләтергә ие микән? — ди патша.

— Бу урманны кистереп,— ди малай,— зур вокзал кордырырга булыр ие,— ди.

Шуннан ерак түгел бер җирдә бик зур бер мәйдан бар икән.

— Ә менә бу мәйданны нишләтергә булыр ие микән? — ди.

— Монда тимер юл эшләтергә була,— ди малай.

Ярый, бусы да булды. Кайтып китәләр болар. Патша бик зур уйга төште: «Их, бу тимерче малае минем малайдан бик күп зиһенле икән», дип. Уйлап-уйлап йөри дә патша бу тимерче малаен үзенә алмакчы була. Тимерчене чакыртып ала да әйтә:

— Син малаеңны миңа бир, болай гына бирмәсәң, мин аны ничек алырга белермен,— ди.

Тимерче бик зур кайгыга төште.

— Мин аны сиңа бирә алмыйм, өйгә кайтып малайның үзе белән сөйләшеп карыйм әле,— ди.

Тимерче өенә кайтып малайга әйтә: патша шулай-шулай дип әйтте дип. Малай әйтә: «Мин бервакытта да аның малае булачак түгелмен»,— ди.

Тимерчене яңадан чакырта патша.

— Сөйләштегезме? — ди.

— Сөйләшүен сөйләштек, ди, тик малай риза түгел бит әле,— ди.

— Алай булса,— ди патша,— менә сиңа ун үгез, ди, шуларны фәлән вакытка бозаулатып китерерсең, ди, китермәсәң, малаеңның башын чаптырам,— ди.

Патшаның дошманлыгын сизеп, тимерче малае үз иптәшләреннән бер рота команда төзегән ди.

Әтисе патшадан ун үгезне куып алып кайта. Тимерче малае командасы белән үгезләрне тоттылар да

суйдылар, итен ашадылар, тиресеннән үзләренә ботинка тектерделәр ди.

Ярый, үгез бозаулыйсы вакыт җиткәч, патшадан тимерчегә илче килде. Илче тимерче капкасы янына килеп:

— Тимерче өйдәме? — диде.

— Өйдәсен өйдәдер дә,— ди малай,— мич башында бала таба ул,— ди.

— Их, ди, дурак син, ди, ир кеше бала табамыни соң? — ди.

— Соң, ди, синең патшаң миннән дә дураграк икән, ди, ә үгез бозаулыймы соң? — ди.

Ярый, илче патшага кайтып әйтә: «Шулай-шулай дип әйтте тимерче», дип. Патша эченә генә салып куя егетнең тапкырлыгын.

Патша яңадан тимерчене чакырта да әйтә:

— Иртәгә мин чакырткан вакытка килеп җит, ди. Мин сиңа берничә сорау бирермен, шул сорауларга малаең җавап таба алмаса, мин аны астырам, кистерәм,— ди.

Иртә белән патша әйткән вакытка тимерче килеп җитте.

Патша әйтә:

— Менә сиңа пешкән мең йомырка, ди, шулардан чеби чыгарып китер,— ди.

Тимерче кайта да малайга әйтә: «Шулай-шулай дип әйтте патша», дип. Малай әйтә:

— Бар, ди, йомыркаларын алып кайт,— ди.

Йомырканы китереп бушаталар тимерче йортына. Егет йомыркаларны үзенең иптәшләренә ашатты да бетерде, мин сиңа әйтим.

Ярар, бусы да булды. Озак та үтмәде, чеби чыгар вакыт та килеп җитә. Патшадан илче дә килеп җитә.

— Тимерче өйдәме? — ди килгән илче.

— Өйдә юк, кырга куырган борчак чәчәргә китте ул,— ди малай.

Илче әйтә:

— Әллә, ди, куырган борчак чыга, ди, саташкан син,— ди.

— Алай булса синең патшаң миннән дә ныграк саташкан, ди, пешкән йомыркадан чеби чыгамыни соң? — ди.

Илче патша янына кайтып бу сүзләрне түкми-чәчми җиткерде ди, мин сиңа әйтим.

Патшаның бу тимерче малаена бик каты ачуы килде. Тимерчене тагын чакыртып алды үз янына.

— Менә сиңа сүз шул, иртәгә фәлән вакытка шушында килеп җит, җәяү дә килмә, киенеп тә килмә, ялангач та килмә, юлдан да килмә, кырыйдан да килмә,— ди.

Тимерче бу сүзләрне малаена кайтып әйтә дә малаен кочаклап-кочаклап елый:

— Китәсең инде син бездән, патша кушкан эшләрне эшләп булмас инде,— ди. Малай әйтә:

— Еламагыз, әти, ди, китмим мин сездән,— ди.

Тимерче малае һәр көнне иртә белән үзенең иптәшләре белән кырга чыгып йөри икән, иптәшләренә сөйли икән: «Дөньяда төрле эшләр булуы бар. Андыймондый миңа авырлык килсә, мин быргымны кычкыртырмын, сез шуннан сизеп алырсыз», дип.

Ярар. Тимерче: «Патшага ничек кенә итеп барырмын икән инде», дип кан елый икән.

Малай иртә белән торып атасын ашатты, эчерде. Боларның бер кәҗә тәкәсе булган икән. Малай шул кәҗә тәкәсен тотып алып чыкты. Чыптадан киемсыман бер әйбер рәтләп, атасының өстенә каплады, башына салам эшләпә кигезеп, кәҗә тәкәсенә атландырды. Шуннан малай атасына әйтте: «Көпчәк юлыннан да барма, читкә дә чыкма, ике арадагы юлдан бар, ди. Барып җиткәч, ди, капканың ябыла торган төшенә генә тукта»,— ди.

Ярар, чыгып китте бу. Патша подзорный труба белән карап тора. Карый, тимерче нәкъ патша әйткәнчә килә бит. Тимерченең килүен күреп, капканы киң итеп ачып куялар. Тимерче килеп җитә дә кәҗә тәкәсен капканың ябыла торган төшенә генә борып куя.

— Ярый, бусы булуын булды,— ди патша,— шулай да өч көн срок, ди, өч көннән соң мин синең малаеңны барыбер астырам,— ди.

Патша малайны астырырга урыннар күләтте, сәндерәләр: беренче сәндерәне ясатты бакырдан, икенчесен — көмештән, өченчесен — алтыннан.

Хәзер патша бөтен халыкка хәбәр итте: «Килсеннәр, күрсеннәр, гыйбрәт булсын!» — дип.

Ярый, малай килеп җитте патшаның сарае янына. Үзе белән быргысын да алган. Шунда атасы да тора. Малай атасының йөзенә карады, атасы кайгыга төшкән, әнкәсе дә күз яшьләрен түгеп тора.

Патша чыкты да:

— Килдеңме, малай? — ди.

— Килдем,— ди.

— Ну, килсәң, әйдә барыйк мәйданга,— ди.

Хәзер баралар малайны аса торган төшкә.

Малай өйдән чыгып киткән вакытта иптәшләренә әйтеп калдырган була: «Мин быргыны беренче кычкыртканда юлга чыккан булыгыз, икенче кычкыртканда ярты юлга җиткән булыгыз, өченчесендә минем янга килеп җитеп, патша гаскәрләренә ташланыгыз», дип.

Ярый, малай килеп җитте аса торган урынга. Беренче сәндерәгә менгерделәр дә малайның муенына бакырдан питлә салдылар. Малай шулкадәр матур инде, бөтен халык зар елый ди моны кызганып. Малай әйтә: «Падишаһым-солтаным, ди, үләр алдыннан бер генә мәртәбә быргымны кычкыртыйм әле»,— ди. Патша рөхсәт итә. Малай кычкыртып җибәрә, бөтен халык шакката моның моң тавышына.

Тимерче малаеның быргысын ишетеп, теге иптәшләре юлга чыгалар.

Хәзер бу малайның муеныннан бакыр питләне алып, көмеш сәндерәгә менгерәләр, муенына көмеш питлә салалар. Тагын сорады егет: «Мин тагын бер генә кычкыртыйм ла?» — дип. Кычкырт, ди патша. Икенче кычкыртканда моның иптәшләре ярты юлга җитәләр.

Инде малайның муеныннан көмеш питләне алдылар да, алтын сәндерәгә менгереп, муенына алтын питлә салдылар. Малай тагын рөхсәт сорады: «Актык сулышымны алыр алдыннан тагын бер мәртәбә кычкыртыйм»,— дип. Патша рөхсәт бирә, кычкырт, ди. Малай быргысын кычкыртып җибәрә, халык та, патша да нишләргә белмиләр, шуның хәтле моңлы, еламаган кеше калмый.

Шул вакытта малайның иптәшләре килеп җитәләр дә патша гаскәрләренә ташланалар. Патша гаскәрләрен кырып бетерәләр дә, мин сиңа әйтим, патшаның бөтен байлыгын халыкка таратып, повар кызны үзенә хатынлыкка алып, зур туй ясап, әле дә булса матур гына тормыш итәләр икән ди.

ҮТКЕН КАРТ

Бер авылда бик фәкыйрь карт кеше яшәгән ди. Балалары бик күп булган. Беркөнне ашарларына бернәрсә дә булмагач, күпме вакытлардан бирле саклап торган казны пешереп ашарга утырганнар. Карт хатынынннан икмәк белән тоз сораган. Хатыны әйткән:

— Икмәк белән тоз булса, бу казны пешермәгән дә булыр идем. Бернәрсә дә булмаганга пешердем дә инде,— дигән.

Карт икмәк булмагач, ничек ашарга икән бу казны дип, хәзрәткә алып киткән. Хәзрәт казны күргәч, бик шатланып, дога кылып алган.

Хәзрәт әйткән:

— Син безнең җәмәгатьләрне беләсең, бу казны һәркайсыбызга тигез кылып, бүлеп тә бир инде,— дигән.

Карт риза булып, казны бүлә дә башлаган. Иң әүвәл хәзрәтнең үзенә башны кисеп биргән. Аннан соң хатынына дип, муенны кисеп тоттырган. Ике аякны ике улына сузган. Ә ике канатны ике кызына дип кисеп биргән. Соңра хәзрәткә карап:

— Мин ахмакка буксәсе дә ярар,— дип, казны үзепә алган.

Картның акыл белән бүлүенә хәзрәтнең кәефе килеп, каз белән күп икмәкләр дә биреп җибәргән.

Шул авылның икенче кешесе бу хәбәрне ишетеп, биш каз күтәреп хәзрәткә килгән. Хәзрәт әүвәлге рәвешчә бу кешегә дә:

— Безнең алты җәмәгатькә биш казны тигез итеп бүлеп тә бир инде,— дигән.

Бу кеше аптырап, ничек бүләргә дә белмәгән. Хәзрәт баягы картны чакырып, казларны бүләргә кушкан. Карт бер казны хәзрәткә биреп:

— Хатының белән өчәү булдыгыз,— дигән.

Икенче казны ике улына сузып:

— Алар да өчәү булдылар,— дигән.

Өченче казны ике кызына дип тоттырып:

— Алар да өчәү булдылар,— дигән.

Калган ике казны үзенә алып:

— Без дә өчәү булдык,— дигән.

Хәзрәт картның зиһененә шаккатып, күп хөрмәт кылып җибәргән. Казны алып килүче бернәрсәсез кайтып киткән.

ӨЧ СОРАУ

Борын-борын заманда бар иде ди бер ятим егет. Бар иде моның ике өе: аның берсе кешенеке, икенчесе күршенеке иде, өйләрен салам белән мүкләгән, күк белән терәткән иде ди. Көннәрдән беркөнне менә шушы егет эш эзләргә дип читкә чыгып китә. Көн китә бу, төн китә. Шулай бара торгач, барып җитә ашлык чәчеп йөрүче бер кеше янына. Егет әйтә:

— Эшләрең уң булсын, уңышларың мул булсын, абзый кеше,— ди.

— Шулай булсын, улым,— ди теге кеше. Аннары юлчы егеттән сораша башлый.— Каян киләсең, кай җирләргә барасың? — ди. Егет:

— Эш эзләргә чыктым, абзый кеше,— ди.

Шуннан соң игенче әйтә:

— Ярар, егет, ди, эш кешесенең эштә, юл кешесенең юлда булуы яхшы, ди. Уйлана-уйлана барсаң, юлың кыскарак булыр, мин сиңа бер-ике хикмәтле сүз әйтим, җавабын уйлап таба алсаң, килеп әйтерсең,— ди.

— Ярар, абзый,— ди егет,— әйтеп кара,— ди.

Теге кеше, тубалын асып, ашлык чәчәргә тотына. Уч тутырып ашлык ала да чәчеп җибәрә.

— Менә бер тапкыр чәчтем, бусы бурычымны түләргә булыр,— ди. Икенче мәртәбә сибеп җибәрә дә: — Менә монысы бурычка биреп торуым,— ди.

Үги кыз. 8 биткә.

Камыр батыр. 19 биткә.

Шуннан өченче тапкыр чәчеп җибәрә дә: — Монысы кадерле кунакларым өчен,— ди.

Егет уйга кала: «Бу нәрсә булыр икән?» — ди.

— Ярар, абзый,— ди егет,— син миңа бераз гына уйларга бир,— ди.

— Уйла-уйла, улым,— ди игенче, шулай ди дә ашлыгын чәчеп китә. Озак та үтми, әйләнеп килеп җитә дә егеттән сорый:

— Я, нихәл, улым, берәр нәрсә чыгамы? — ди.

— Абзый кеше,— ди юлчы егет,— синең соң әти-әниләрең бармы?

— Бар,— ди теге.

— Яшь вакытында алар сине тәрбияләгәндер бит? — ди егет.

— Тәрбияләделәр,— ди игенче.

— Алайса, беренче чәчкәнең аларны тәрбияләү өчен булды.

— Дөрес әйтәсең, улым, беренчесен шулай бурычымны түләр өчен чәчтем.

— Синең ир балаларың бармы? — ди егет.

— Бар,— ди теге кеше.

— Алай булгач, икенче тапкыр чәчкәнең чыннан да бурычка биреп тору була, хәзергә син балаларыңны тәрбиялисең, ашатасың-эчертәсең, алар сиңа бурычлы булып калалар,— ди.

— Бусын да бик дөрес әйттең,— ди игенче.

— Синең кызларың бармы? — дип сорый егет.

— Бар...

— Алар синең кадерле кунакларың кебек кенә бит, үсеп җитү белән, синнән китәләр бит алар,— ди егет.— Өченче тапкыр чәчкәнең әнә шул кадерле кунакларың өчен булды,— ди.

— Бик дөрес әйтәсең, тапкыр егет икәнсең,— ди игенче, егетне мактап.

ЗИРӘК КАРТ

Элек заманда булган ди бер явыз патша. Ул җитмеш яшькә җиткән кешеләрне, барыбер эшкә ярамыйлар дип, үтертә торган булган ди. Бер егетнең булган җитмеш яшьлек атасы. Бу егетнең атасын бер дә үтертәсе килмәгән. Ул аны байтак вакытлар яшереп асраган ди.

Егет көн саен атасы янына керә икән. Атасы моннан:

— Нихәл, улым, дөньяда ниләр бар? — дип сорый икән.

Егет күргәнен-ишеткәнен барын да сөйләп бирә икән.

Шулай беркөнне егет урманнан кайткан да этисе янына кергән.

— Нәрсәләр күрдең, улым, ниләр ишеттең? — дигән этисе.

— Эти,— дигән егет,— патша үзенең вәзирләре белән су буена төшкән. Су төбендә җем-җем итеп гәүһәр ялтырый. Шуны су төбенә төшеп эзлиләр — таба алмыйлар, менгәч карыйлар, тагы да су төбендә ялт итеп күренеп тора. Шуңарга бик аптырадылар. Патшаның вәзирләре дә моның хикмәтен белә алмадылар,— дигән.

— Әй, улым,— дигән карт,— анда берәр агач үсеп утырмыймы соң?

— Бер өянке үсеп утыра анда, гәүһәрне шуның тирәсендә эзлиләр дә инде,— дигән егет.

— Өянке башында кош оясы да бармы?

— Бар.

Шуннан соң әтисе әйткән:

— Алайса, ул гәүһәр кош оясындадыр. Суга шуның шәүләсе генә төшкән булыр,— дигән.

Иртәгесен патша кешеләре яңадан су буена баралар. Карасалар, күрәләр болар, гәүһәр су төбендә җем-җем ялтырап ята, боларның суга чумулары була, гәүһәр тагын юкка чыга. Таба алмыйча, тагын аптырап кайтып китәләр. Болар таба алмагач, егет патша янына бара да әйтә:

— Падишаһым-солтаным, бер сүз сөйләр идем мин сиңа,— ди.— Бу гәүһәр су төбендә түгелдер, су буенда өянке бар, өянке башында оя бар, шул ояда булырга кирәк, шуны менеп карыйк әле,— ди.

Патшаның менүчеләре күп була, тиз генә агач башына менеп китәләр дә каз йомыркасы кадәр гәүһәрне алып та төшәләр. Патшаның исе китә моңарга. Вәзирләрен бик орыша инде бу:

— Үзегез укыган кешеләр, үзегезнең шул авыл малае кадәр дә акылыгыз юк,— ди.

Ә егеттән сорый:

— Моны сиңа кем өйрәтте? — ди.

— Үзем белдем,— ди егет.

Вәзирләрнең бу егеткә бик ачулары килә. Егет алардан өстен чыкты бит инде. Хәзер вәзирләр егет өстеннән патшага әләкләп, аны ничек булса да үтертмәкче булалар. Үтертмәкче булалар да патшага барып әйтәләр:

— Ул,— диләр,— миңа нәрсә күрсәтсәләр дә беләм,— дип әйтә. Без аңа ике айгыр күрсәтик. Икесе дә бертөсле, яннарына да килмәсен, кайсы карт, кайсы яшь икәнлеген читтән торып кына белсен ул егет,— диләр.

— Ярый,— ди патша. Шуннан соң егетне чакыртып ала да әйтә:

— Иртәгә килерсең, без сиңа шундый-шундый ике айгыр күрсәтербез, син шуларның кайсы карт, кайсы яшь икәнлеген белерсең,— ди.

Егет, бик кайгырып, ярар, дип кайтып китә. Кайткач, атасы янына керә.

— Улым, нихәл? — ди атасы.

— Әти,— ди бу,— гәүһәр, син әйткәнчә, кош оясында булды,— ди.— Тик патша миңа бүген тагын шундый-шундый мәсьәлә бирде әле,— ди.

— Әй, улым,— ди атасы,— аның өчен хәсрәтләнмә, ул берни түгел,— ди.— Иртәгә барырсың, ике айгыр китерерләр. Аларның картын-яшен шуннан белерсең: яшь айгыр ерактан ук тузгып, уйнаклап килер, ә карт айгыр башын борып, яшь айгырга юл биреп китәр,— ди.

Егет иртүк торып бара. Вәзирләре белән патша да килә. Болар ике айгыр китерәләр, икесе дә бертөсле, икесе дә бертигез.

— Моның кайсы карт, кайсы яшь? — диләр егеткә.

Ике айгыр ике яктан кара-каршы киләләр. Яшь айгыр әллә каян тузгып, уйнаклап килә, карт айгыр башын иеп кенә уза. Егет әйтә:

— Менә бусы карт айгыр, бусы яшь айгыр,— ди.

Бу егет моны да белде бит инде. Хәзер икенче көнгә моңа тагы бер мәсьәлә хәстәрлиләр. Шоп-шома итеп юнылган ике бүрәнәне күрсәтәләр дә:

— Шушы агачларның кайсы башы оч, кайсы башы төп була, шуны бел,— диләр.

Егет бик хәсрәтләнеп кенә кайтып китә. Кайткач, тагын әтисе янына керә.

— Улым, бүген ниләр күрдең? — ди карт.

— Әти,— ди егет,— айгырны белдем, син әйткәнчә булды,— ди. Миңа тагын мәсьәлә биреп җибәрде-

ләр бит,— ди. Бертигез юнган ике агач, тышыннан бернәрсәсе дә беленми, шуның кайсы башы оч, кайсы башы төп икәнен белергә кушалар,— ди.

— Әй, улым, кайгырма юкка,— ди атасы.— Син ул агачларны суга салырга куш. Суга салгач, оч башы өскә калкыбрак, төп башы төпкә батыбрак торыр,— ди.

Иртәгесен егет торып китә. Барып керә. Моңа шопшома итеп юнылган ике агачны әзерләп тә куйганнар.

— Менә сиңа ике бүрәнә, юнып та карама, күтәрмә дә, кайсы башы оч, кайсы башы төп икәнен болай гына бел,— диләр.

Егет:

— Суга салып карагыз әле,— ди.

Суга салалар, бүрәнәләрнең бер башы бата, икенче башы өскә калка. Егет әйтә:

— Менә бу башы оч, бусы төп була,— ди.

Тагын белде бит инде бу. Патша бик гаҗәпләнә моңа. Гаҗәпләнә дә егеттән сорый:

— Моны сиңа кем өйрәтте? — ди.

Егет әйтә:

— Үзем белдем,— ди.

— Юк, син әле моны белерлек түгел, яхшылык белән әйтмәсәң, мин сине астырам,— ди патша.

Егет әйтмичә булдыра алмый:

— Минем җитмеш яшьлек әтием бар, мин аны үтертмичә яшереп асрыйм, миңа шул акыл бирә,— ди.

Шуннан соң патша әйтә:

— Яхшы, дөньяда картлар да кирәк икән, картлардан башка дөнья бармый икән. Моннан соң картларга тимәскә,— ди.

КЕМ КӨЧЛЕ?

Борын-борын заманда булган икән ди бер кеше. Бу кешенең исеме Нарый булган ди, кесә төбе тар булган ди, тар булса да, бер пот тары сыя торган булган ди.

Көннәрдән беркөнне Нарый чыгып киткән юлга. Барган да барган ди бу. Бара торгач, барып кергән ди ялтырап торган боз өстенә. Боз өстенә барып та кергән, аягы таеп, әйләнеп тә төшкән. Шул чакны бөтен тарысы чәчелеп тә киткән моның. Ачуланып сикереп торган да Нарый бозга әйткән:

— Боз, син нидән көчле болай? — дигән.

— Көчле булсам,— дигән боз,— мине кояш эретә алмас иде.

— Кояш, син нидән көчле? — дигән Нарый.

— Көчле булсам, мине болыт капламас иде.

— Болыт син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине яңгыр тишеп чыкмас иде.

— Яңгыр, син нидән көчле?

— Көчле булсам,— дигән яңгыр,— мине җир сеңдермәс иде.

— Җир, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине үлән тишеп чыкмас иде.

— Үлән, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине сыер ашамас иде.

— Сыер, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине пычак кисмәс иде.

Хәзер пычактан сорый инде Нарый:

— Пычак, син нидән көчле? — ди.

— Көчле булсам, мине ут эретмәс иде.

— Ут, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине су сүндермәс иде.

— Су, ә син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине кеше җиңмәс иде, ә ул мине җиңә, тегермәннәр әйләндерергә җигә! — ди су.

Шуннан соң Нарый, кешедән дә көчле нәрсә юк икән дип, үз юлына китә, шуның белән әкият тә бетә.

ӨЧ КЫЗ ТУГАН

Борын-борын заманда булган ди бер хатын. Аның булган ди өч кызы. Бу хатын, кызларымның өсте бөтен, тамаклары тук булсын ди-ди, көне-төне эшләгән ди.

Менә кызлар буйга да җиткәннәр. Алар берсе-берсеннән матур ди, бер битләре ай, бер битләре кояш ди, буй-сыннары карлыгачтай сылу ди. Өч кыз туган бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар.

Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына тереклек иткәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урманда тиен-дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:

— Тиен-дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче,— дигән.

Тиен шундук чыгып чапкан. Тиен барып тәрәзә какканда олы кызы җиз ләгәннәр тазартып торадыр иде ди.

— Һай,— дип әйткән ди олы кыз,— бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы ләгәннәрне тазартып бетерәсем бар иде шул,— дигән ди.

Тиен моңар бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! — дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан китереп тә кысканнар. Олы кыз егылган да шунда ук ташбакага әверелгән.

Тиен уртанчы кызга чыгып чапкан. Уртанчы кыз бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә киндер суга икән. Тиенгә әйткән:

— Һай,— дигән,—әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул,— дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син гомереңә буе киндер сугып кына тор! — дигән.

Уртанчы кыз шундук үрмәкүчкә әверелгән.

Тиен тәрәзәсен какканда, кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән.

Тиен кече кызга әйткән:

— И сөекле бала,— дигән,— гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар,— дигән.

Кече кыз чыннан да бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан ди.

КҮКЕ КЫЧКЫРГАЧ, КӨТҮЧЕ ХЕЗМӘТ ХАКЫ АЛА

Борын-борын заманда Атбасар исемле хайван асраучы бер бай булган ди. Ул үзе дә, хатыны да бик саран да, комсыз да икәннәр. Бер елны җәйнең эссе көнендә Атбасарның көтүчесе баена ачуланып чыгып киткән. Бай көтүчесез калган. Байга кеше кирәген бер егет ишеткән дә Атбасарга ялланырга килгән ди. Бай моңар:

— Нихәл, егет, нәрсә кирәк? — ди икән. Егет үзенең көтүче икәнен әйткән.

— Сездә урын бар дип ишеттем,— дигән. Атбасар:

— Урын барын бар, син безнең эшне булдыра алырсыңмы икән,— дип сорый икән. Егет:

— Мин бар эшне дә булдыра алам,— ди икән. Атбасар:

— Минем ат көтүем бар, шуны көт. Хакын мин атнадан да, айдан да, елдан да түләмәм, күке кычкыргач түләрмен. Минем бакчамда күке кычкырса, шунда сиңа йөз сум,— дигән. Егет уйлый: «Күке язҗәй айларында бик еш кычкыра, шулай булгач, акча күп төшәр»,— ди.

Атбасар кич белән атларын күрсәткән ди. Алар бары да симезләр, усаллар, кап-кара төстәләр, үзләре һаман бер-берсе белән тибешеп кенә торалар икән ди. Егет:

— Атлар бик усал икән, алай да көтәрмен, тик мине юк-бар өчен тиргәмәссең,— дигән. Бай моңа риза булган.

Иртә белән егет иртә үк атларны алып чыккан. Бай ашарга бирмәгән: «Көндез үзем алып барырмын»,— дигән. Егет атларын кырга алып чыккан. Атбасар:

— Кара, берсен дә югалтма! — дип кычкырып калган. Кырга чыгуга, атлар бар да таралып беткәннәр. Егет куркуга калган. Атлар артыннан чабып та караган. Берсен дә тота алмаган. Аптырап арып, хәлдән таеп бер агач төбенә яткан икән, йоклап киткән.

Төшендә аңа бер карт килеп:

— Син, улым, бер агач башына мен дә: «Карлыгач күк кара тулпарларым, җыелыгыз!» — дип әйт. Бары да җыелыр, дигән. Егет йокыдан уянгач, шулай кычкырган икән,— атлар бары да җыелганнар. Менә төш җиткән,— егеткә ашарга китерүче юк. Ул аптырап тормаган: бер колынны суйган да пешереп ашаган.

Кич белән Атбасар килгән. Атларның җыелып торганын күреп, хәйран калган ди.

— Бер колын кая? — дип ачулана башлаган икән, егет:

— Син ачуланмаска вәгъдә бирдең бит,— дигән.

Атбасар, монысы да көтүне ташлап китәр дип куркып, сүз әйтмәгән. Икенче көнне бай тагын да ашарга китермәгән. Көтүче тагын да бер атны суеп ашаган ди. Шуннан соң көндез Атбасарның аш китермичә хәле булмаган.

Шулай итеп, көн артлы көн үткән, күке кычкырмаган ди. Беркөнне егет, атларын кырда калдырып, бакчага килгән. Килсә, бакча буйлап, байның хатыны — сихерче карчык йөри ди. Агачка менеп кычкырырга теләгән һәр күкене ул куа торган булган ди. Егет үзенең камчысы белән хатынга бер суккан икән,

хатын «эх» тә итә алмыйча үлеп калган. Аны кем үтергәнне дә белмәгәннәр.

Менә шуннан соң күкеләр бик еш кычкыра башлаганнар. Атбасарга бу эш бер дә ошамаган. Күке кычкырган саен, көтүчегә йөз сум түләргә кирәк бит. Ул егеттән котылу юлын эзли башлаган ди. Беркөнне, бик каты иттереп мунча яктырган: мунча ташына агу салдырган да беренче парына егетне кертмәкче булган. Егет бу эшне сизгән. Керүгә мунчаның ташларын алып, яңа ташлар куйган. Пар сала-сала юынган, бернәрсә дә булмаган. Чыкканда агулы ташларны мунча мичен͏ә салып чыккан ди.

Егет артыннан мунчага Атбасар кергән. Үзе салган агуга үзе тончыгып үлгән ди.

ХӨРХӨР

Борын заманда Хөрхөр исемле бер кыз булган ди. Аның җиде агасы булган ди. Хөрхөр урамга уйнарга чыккач гел әйтәләр икән моңа: «Синең җиде агаң бар», дип. Кыз бер сорый инәсеннән, ике сорый, өч сорый: «Минем агаларым бармы?» — дип, инәсе бер дә әйтми, юк кына дип җавап бирә икән. Аптырата торгач, инәсе әйтеп бирә: «Агаларың бар иде шул, ди, мин сине җибәрәсем килмәгәнгә генә әйтмәгән идем», ди. «Алай булгач,— ди кыз,— син миңа җил арба эшләтеп бир, мин агаларымны эзли чыгам»,— ди.

Уллары юлга чыгып киткәндә әйтәләр инәләренә: «Без киткәч кыз тапсаң, өй кыегына көзге менгереп куй, ул тапсаң ук менгереп куй», дип.

Боларның күршеләрендә усал гына бер карчык булган икән. Шул карчык боларның өй кыегында көзге торганны күрә дә ук белән алмаштырып куя. Бу кызның агалары кайталар икән дә өй кыегында ук торганны күреп: «Ә, энебез булган икән», дип китеп тә баралар икән.

Ярар. Кызның инәсе җил арбаны ясатып бирә. Бер кәчек, бер песәй, бер этәч бирә дә, иптәшкә күрше кызын да чакыралар болар. Инәсе әйтә күрше кызына: «Минем кызымны какма, сукма, ди, бергәләп дус кына барыгыз»,— ди.

Ярар. Утырып китәләр болар җил арбага, әй шәп баралар ди болар. Юлга чыкканда инәсе кызның тәненә язган була агалары танысын дип:

— Әй, җил арбам, җил арбам,
Җиде агага җитәек,
Җиде диңгез кичәек.
Мияула, песәем, мияула,
Тычкан килгәнне сизәек.
Өр, көчегем, өр, өр, өр,
Бүре килгәнне сизәек.
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң атканны сизәек,—

дип.

Болар бара-бара җитәләр бер су буена. Су буена җиткәч иптәш кызы әйтә моңа: «Әйдә, су керәек»,— ди. Су керәләр болар. Су кергәч күрше кызы тиз генә судан чыга да Хөрхөрнең күлмәген кимәкче була. Хөрхөр үзе дә судан чыккач тәнен күрә дә: «Әй, кара әле, инәй нәрсә дип язган»,— ди. Шуннан соң күрше кызы: «Я, мин тегеләй генә, күлмәгеңне алмыйм бит»,— ди. Күрше кызының күңеле гел начарлыкта була инде, Хөрхөрнең күлмәкләрен киеп, сеңелләре булып барасы килә, алдамакчы була инде.

Бара торгач, тагын диңгезгә җитәләр болар. Диңгез янына җиткәч күрше кызы тагын су керик, ди. Су кереп чыккач күрше кызы тагын моның күлмәген кимәкче була. Шулай иткәч бу тагын: «Кара әле, инәй минем тәнемә нәрсә язган»,— дип күрсәтә. Язуны күргәч: «Я, мин тегеләй генә, күлмәгеңне алмыйм бит»,— ди тагын күрше кызы.

Болар җиде диңгез кичкәнче су коеналар шулай. Соңгы мәртәбә коенганда инде кыз тәнендәге язу беткән була. Күрше кызы моның тәнендәге язу беткәнне күрә дә: «Хәзер моны абыйлары таный алмый инде»,— дип судан тиз генә чыга да Хөрхөрнең күлмәген киеп җил арбаның түренә кереп утыра. Ә Хөрхөрне арбаның алдына кучерга утырта бу.

Ярар. Барып керәләр болар абыйларына. Бик яхшы каршы алалар боларны: «Сеңлебез килгән икән, сеңлебез килгән» дип, түрдәге кызны күтәреп алалар.

Җиңгәләре дә хөрмәт итә инде. Ә үз сеңелләре бу хәлне күреп бер кырыйга китә дә елый башлый. Монардан агалары сорыйлар:

— Нигә елый ул кыз? — дип.

— Әй, ул күрше кызы, өйгә кайтасы килә торгандыр, бер дә исегез китмәсен,— ди.

Ә бу кыз һаман елый икән, ашамый да башлый бу. Бервакытны: «Бар, ат эчереп кайт әле»,— дип, моны су буена җибәрәләр ди. Болар бит инде белмичә үз сеңелләрен җибәрәләр. Кыз ат эчерергә барганда җырлый-җырлый бара икән.

— Әй, канатым, аткынам,
Күрдеңме минем әнкәмне,—

дип. Ә ат җавап бирә икән:

— Күрдем синең әнкәңне,
Пыяла чарлак эчендә,
Ефәктән тастар чүплидер,
Хөрхөрем дип елыйдыр,—

дип.

Шулай итеп, бер бара бу кыз ат эчерергә, ике бара, өч бара. Өченче барганда инде озак тора бу су буенда. Агалары: «Нишләп озак тора икән бу?» — дип су буена төшсәләр, сеңлесе җырлап утырганны ишетә дә аптырап кала. «Әй, сеңлем, без бит белмәдек, үзең дә әйтмәдең»,— ди. Шуннан соң ат белән кайтканда кыз агасына сөйли инде ничек булганны. Хәзер агалары моны хөрмәтли башлыйлар инде, күрше кызын бөтенләй куып чыгарып җибәрәләр.

Шулай тыныч кына торганда, җиңгәләре көнләшә башлыйлар бу кыздан.

Беркөнне җиңгәсе Хөрхөргә әйтә: «Әйдә, урманга чәчәк җыярга чыгыйк»,— ди. Шулай дип кызны алдап урманга алып китәләр дә болар, адаштырып кал-

дыралар. Өйгә кайткач: «Әллә кая китеп югалды», дип әйтәләр. Шулай дигәч, моның агалары урманга чыгып китәләр сеңелләрен эзләргә дип. Эзләгәндә агалары такмак әйтә-әйтә эзлиләр ди:

— И Җанбикәч, Җанбикәч,
Өйдә микән Җанбикәч;
Өйдә дә юк Җанбикәч,
Кырда да юк Җанбикәч.

Шул такмакны әйтә-әйтә эзли торгач, табалар болар сеңелләрен. Алып кайталар өйгә. Өйгә кайткач агалары җиңгәләренә әйткән: «Кырык сырак * кирәкме, кырык чана утын кирәкме»,— дип. «Кырык чана утын»,— дигәннәр җиңгәләре. Шулай дигәч, кырык чана утын китереп, җиңгәләренең өсләренә өйгәннәр дә ди, яндырып үтергәннәр ди начарлык эшләгәннәре өчен. Ә үзләре әниләре янына кайтып киткәннәр ди.

Әле дә булса шулай бергә-бергә шатланышып торалар ди.

---

* Сырак — ат.

ШОМБАЙ

Бер бай күрше авылга хезмәтче эзләргә чыга. Капкага сөялеп тора бер егет.

— Иптәш, ди, сезнең авылда хезмәткә керүче булмас микән? — ди.

— Булыр, ди, без үзебез өч агай-эне, хакын бирсәң, мин үзем үк керермен, ди. Хакы ничек булыр соң? — ди.

Бай әйтә:

— Эшнең хакы шулай булыр: минем өй артымда шомырт агачы бар, шул шомыртка сандугач килеп сайраганда, ике йөз тәңкә, ди. Тик, ди, бер дә рәнҗештән булмасын, рәнҗесәң, ике йөз тәңкә үзең түләргә,— ди.

Ярар, килешәләр дә кайтып китәләр болар. Төн куналар да иртә белән чыгалар борчак сугарга. Борчакны ике җәем сугалар да ашарга керергә җыеналар болар. Байның хатыны да болар белән суга. «Болар белән сугу рәхәт миңа»,— дип уйлый хезмәтче. Хатыны көндезгегә аш әзерләргә керә. Бераздан чыгып кычкыра:

— Ашау җитте! — ди. Өйгә керсәләр, өстәл тулы нигъмәт. «И, ди, болай булгач, эшләр бик шәп»,— ди егет.

Бүлмәнең теге ягында бер сабый бала елый башлый.

— Син, егет, ди, кулың да юмаган бугай әле, ми-

нем малайны өй алдына алып чыгып тәпиен генә тотып кер әле,— ди бай.

Ярар, тәпиен тота торгач, бик озак утырды бу малай. Бетереп керсә, өстәл өстендә бертөрле дә ризык калмаган. Бу сөмсерләре коелып өстәлгә таба карап утыра. Бай моңа әйтә:

— Нигә сөмсерләрең бик коелды, миңа рәнҗедең мәллә? — ди.

— Бәй, рәнҗемәскә, ди, мин сезнең белән бергә эшләдем бит,— ди.

Бай әйтә:

— Алай рәнҗесәң, бир ике йөз тәңкәңне, кайт өеңә, ди.

Бу кайтып китә инде.

Болар өч агай-эне иде бит.

— Нишләп бик тиз кайттың? — диләр.

— Барыгыз, үзегез барып карагыз әле,— ди.

Уртанчы малай да барып, шулай алданып кайта.

Хәзер кече уллары Шомбай бармакчы булып тора.

Килә теге бай:

— Сезнең авылда хезмәткә керүче булыр микән? — ди.

— Хакын яхшы бирсәң, үзем үк керермен,— ди.

— Хакы, туганай, ди, сандугач сайраудан, ди. Бәхетле булсаң, бер көннән үк сайрар, иң бәхетсез кеше булсаң да бер айдан калмый,— ди.

Бу егет әйтә:

— Ике йөз тәңкә айга бик күп бит ул, барам,— ди инде.

Китәләр болар. Борчакның ике җәемен сугалар. Өченче җәемдә бай әйтә:

— Син, көндезге ашка ризык әзерлә,— ди, хатынын өйгә кертә.

Ярар, керә, бик яхшы итеп әзерли ашарга, эндәшә боларны. Эндәшкәч, керәләр, керсәләр, өстәл өсте ри-

зык белән тулган. «И, ди, абыйлар шундый рәхәттә тора белмәгәннәр бит»,— ди егет.

Ярар, кулын юып керим дисә, теге бала тагы елый бүлмәнең теге ягында.

Бай әйтә:

— Туганай, ди, синең кулың юмаган бугай, син шуның тәпиен генә тотып керсәнә,— ди.

Тәпиен тотарга чыга. Малай бик озак утыра.

— Юк, малай,— ди егет,— абыйларны да шулай җәзалагансың син,— ди. Калдыра да керә малайны ишегалдында. Малай елый башлый. Байлар йөгереп чыгалар ирле-хатынлы икесе. Чыгалар да хәйран калып тик торалар.

— Нигә шаккаттыгыз? — ди.

— Бәй, ди, балабызны кыйнагансың бит! — ди.

— Әллә рәнҗисезме? — ди.

— Бәй, рәнҗемәскә...— ди, бай әйтә.

— Рәнҗесәң, ике йөз тәңкәне бир әле монда,— ди.

Ярар. Хәзер болар киңәш итәләр:

— Бу егетне нишләтик микән? — диеп.

Хатыны әйтә:

— Ике ат белән чирәм ертырга җибәрик, ди, атын ташлар да кайтып китәр авылына,— ди.

Бай әйтә:

— Егет, ди, җитен чәчәсе җирне сукалап ташлыйк микән әллә? — ди.

— Ярар,— ди егет.

Бик усал ике ат җигәләр дә китәләр болар яңа җир ертырга. Җирне ун сажин иңенә, алтмыш сажин буена итеп ерып ала да бай әйтә:

— Шушыны кичкә хәтле сукалап бетереп кайт,— ди.

Ярар. Теге бай ике атны моңа куеп кайтып киткәч тә, ике атны да суеп, тиреләрен тәртәгә киптерергә элә Шомбай. Үзе ял итеп карап ята.

Бай җиренә килеп җитсә, ике тирене күреп, хәйран булып тик тора.

— Егет, синең нишләвең бу? — ди.

— Менә шулай эшләвем, ди, әллә рәнҗисеңме? — ди.

— Рәнҗеми нишлим? — ди.

— Кая, бир әле ике йөз тәңкәне,— ди.

Тагы киңәш итәләр инде. Боларның дию тегермәне бар, кырык биш чакрым җирдә. Анда бер кеше дә он тарта алмый. Моны шунда җибәрергә итәләр. Биш капчык ындыр чүбен төяп куялар. Бу егет, биш капчыкны салып, төн уртасыннан элек, әлегә тегермәнгә барып керә. Барып кергәч: «Тиз генә тартып бирегез әле!» — дип, бик кызу гына кычкыра бу. Диюнең милнеге * үзенең малае икән. Чыга. Ашлыкны карый. Караса, капчыкта орлык түгел, чүп кенә. «Бу нинди исәп белән килде икән?» — дип күңеленә сала.

— Ярар, менә син мондый сыбай суга торган бүкәнне күздән югалганчы күккә чөйсәң, ашлыгыңны тартырмын,— ди.

Шомбай әйтә:

— Хәзер җибәрәм, күккә таба карап тор, башыңа төшмәсен,— ди.

Теге һавага таба караган чакта, бүкәнгә үзенең бишмәтен каплый да өстенә утыра.

— Әле тиз төшмәс, бар, әтиеңне алып чык,— ди.

Теге әтисен алып чыгарга кереп китә. Шомбай бүкәнне тәгәрәтеп суга төшерә. Дулкын кагып тора бит инде суга салгач.

— Әнә төште,— ди су дулкынланып торгач.

— Ярар,— ди дию,— син минем малайның сүзен тыңлагансың, инде минем сүзне дә тыңла. Менә син минем малай белән йөгерешеп кара, аннан узсаң,

---

* Тегермәнчесе, «мельник» сүзеннән бозылган.

мин сиңа чүп урынына теләсә нинди ашлык төяп җибәрермен,— ди.

Бу инде диюгә каршы әйтә:

— Син малаеңны йөгерткәч, мин дә малаемны гына җибәрәм алайса,— ди.

— Синең малаең юк бит,— ди дию.

— Минем малай бар, күренмичә генә тора, ди, синең малай йөгереп китсә, мин аңар: «Бар, улым, йөгер»,— дип әйтермен.

Ярар. Малайга әйтә:

— Син фәлән агачка хәтле йөгер, мин дә малайга кычкырырмын,— ди.

Теге диюнең малае йөгерә инде. Бу йөгергәч, теге: «Һап!» — дип кычкырып җибәрә. Моның бәхетенә каршы, агач артыннан бер куян чыгып, дию малаен узып та китә. Малай кайта.

— Әй, эти, ди, малаеның койрыгын да күрер хәл юк, ди. Без моның белән дус булыйк, теләгең үтик,— ди.

Тегеләр булган яхшы оннарны төяп биреп җибәрәләр.

Байга алып кайтып китә. Бай моңар әйтә:

— Кайда лач су җир бар, шунда бушат,— ди.

Шомбай онны пычракка аудара да кереп китә. Иртә белән бай чыга, караса, ишегалды тулы он.

— И балам, ди, син юләр икәнсең, кеше бу онны ашарга тапмый, син баткакка тараткансың,— ди.

— Әллә рәнҗимсең син моңар, бай? — ди.

— Рәнҗемәскә, дөнья көтмәгәнлегең әллә каян билгеле бит,— ди.

— Рәнҗесәң ике йөз тәңкәңне бир әле монда,— ди.

Ярар. Бай керә дә:

— Карчык, нишлибез, бөлдерә бит бу безне,— ди.

Хатыны талый торган айгырга башак бирдерергә куша. Бай әйтә:

— Улым, әнә анда безнең бер айгыр бар, аңар бер чиләк су бир, тәмле генә итеп башак болгат,— ди.

Ярар. Шомбай ике чиләк су алып кайта да келәттәге бөтен онны утарга сибеп бетерә. Утарда булган атларны, сарыкларны ачып җибәрә, барысы бергә ашарга тотыналар. «Инде бу беткәндер»,— дип чыксалар, атлар, сыерлар, сарыклар — бар да камыр ашыйлар. Шомбай үзе кырыйдан карап тора. Ярар. Теге, хәйран-вәйран булып, амбарга кереп караса, бер чеметем он да калмаган, барын сибеп бетергән. Бу егет әйтә:

— Ник болай бик хәйран булып торасың? — ди.

— Балам, соң иртәгә нәрсә ашарбыз, бер тамчы да он калдырмагансың бит? — ди бай.

— Рәнҗисеңме әллә син, бай, ди, рәнҗесәң, ике йөз тәңкәңне бир әле монда,— ди.

Ярар. Көндезге чәйне эчәргә утыралар. Чәй эчкәндә, шомыртка кунып сандугач сайрый.

— Әнә, улым, шомыртта сандугач сайрый, елың тулды, бәхетле бала икәнсең,— ди.

— Бай, ул сандугач нинди була икән? — дип барып караса, байның унсигез яшәр кызы, шомыртка менеп, сандугач булып сайрый икән. Бу егет кызны бәрә дә төшерә шомырттан.

— И балам,— ди бай,— баламны харап иттең бит,— ди.

— Әллә, бай, рәнҗисеңме син, ди. Рәнҗесәң, ике йөз тәңкәңне бир әле монда, мин кайтам инде,— ди.

Әллә нихәтле акча алып кайтып китә өенә.

ДИЮЛӘРНЕ ҖИҢГӘН

Бер авылның бакча артында гына урманы бар, аударсаң, бакча коймалары өстенә төшәр, шундый якын. Тик бу урманнан бер агач та ала алмыйлар, урман каравылчысы җибәрми.

Көннәрдән беркөн куркак кына бер кеше гайрәтләнеп урманга чыгып китә. Колач җитмәстәй ике чыршыны кисә дә аудара бу. Менә бер заман урман каравылчысы килеп чыга:

— Нишлисең син? — ди.

— Менә тәрәзә астында ике бүрәнә черегән, шуңа ике бүрәнә алып кайтам әле,— ди.

— Синең атың кайда? — ди каравылчы.

— Ат нигә аңа? Икесен ике култык астыма кыстырам да кигәм,— ди бу.

— Әйдә, бүрәнәләрең качмас,— ди каравылчы,— безгә чәйгә кер.

Ярар, керә бу. Урман каравылчысы дию затыннан икән. Ярлыны төнлә берәр төрле җай белән дөньядан юк итәргә уйлыйлар.

Бик сыйладылар моны. Кичкесен түбән өйгә урын җәеп бирделәр. Аларның пышын-пышын нинди сүз сөйләшкәннәрен бу азрак аңышты. Толып астына чыралар салды да бу, үзе мич артына кереп утырды. Бер заман югары өйдән җәйгән урын өстенә дөбердәп тегермән ташы килеп төште. Шуннан соң бу ятты да

йоклады. Иртә белән хуҗалар коймак пешергәннәр дә моны чәйгә уяталар. Килеп утыра бу әйбәт кенә.

— Төшеңдәниләр күрдең? — диләр.

— Төштә, ди, әллә ни күрмәдем. Киленнең орчык башы төшкән иде дә, мин аны аяк очынарак куеп йокладым,— ди.

— Уф алла,— диләр болар, аталы-балалы шакка-тыштылар.

— Тагын бер кич кун инде син,— диләр. Бу кунарга була.

Тагы кич булды шулай. Егерме чиләк су кайнаталар болар, төнлә моның өстенә су коймакчы булалар. Ярар. Бервакыт кайнар суны коялар, бу тагы мич артына кереп утыра. Коеп бетергәнче көтә дә, ята да йоклый бу.

Иртәгесен тагы ашау-эчү әзерлиләр. Ашарга эндәшәләр, тагы әйбәт кенә барып утыра бу. Ярар.

— Соң, нихәл, кунак, тыныч кына йокладыңмы? — диләр.

— Бик тыныч йокладым,— ди бу әйтә,— тик беразжылы яңгыр гына сибәләп үтте,— ди. Тегеләрнең моңа исләре китә. Китәр алдыннан бу кеше әйтә:

— Бик әйбәт дус булдык инде без, ди. Сез мине илтеп тә куегыз инде, ди. Моннан соң бер-беребезне өстебезгә атландырып йөртешле булсын,— ди.

Тегеләр әйтәләр:

— Бик шәп, бик яхшы булыр,— диләр. Атасы әйтә:

— Улым, син үзең атландырып илт инде, алайса,— ди.

Урман каравылчысының малае моны атландырып илтергә чыга. Юлда тамыры белән ауган бер чыршы күрәләр.

— Иптәш, ди, син бу чыршыны да ал әле, сиңа казан ассак кирәк булыр,— ди. Теге чыршыны да өстерәп кайта.

Кайта-кайта, бер юл чатлыгында тегермән ташы күрәләр.

Бу әйтә:

— Менә бу, ди, барыбызда да була торган хәл инде, ди, әни белән хатын оршышканнар ахры, ди, әни ачу белән хатынның орчыкбашын * тәгәрәтеп җибәргән, без алып кайтыйк инде аны,— ди. Каравылчы малае моны да күтәрде.

Кайтып керделәр. Урман каравылчысының улын түр башына, тәрәзә янына утыртты. Ул арада чәй дә өлгерде. Чәй эчеп утырганда ире әйтә хатынына:

— Аш пешер әле, кунакны сыйларга кирәк бит,— ди. Хатыны әйтә:

— Әй, син тагын, үз чамаңны үзең белмисең, бернәрсә дә юк бит,— ди.

— Ник булмасын, ди, ире әйтә,— амбарда бөтен дию бар, шуны сал, ул да җитмәсә, әнә түрдә тагын бер дию утыра, шуны ботарлап бирермен,— ди.

Бу дию тәрәзәне бәреп чыга да йөгерә. Ах-вах килеп йөгерәдер иде, бер төлке очрады моңа:

— Кая бардың, дию иптәш, ник тының-көнең беткән? — ди. Дию әйтә:

— Әҗәлдән котылып калдым әле, ди, менә шушы авылда бер кечкенә генә кеше дию ашап ята икән, көчкә чыгып качтым,— ди. Төлке әйтә:

— Ул кеше җилле көнне урамга чыгарга да курка бит, әйдә, үзем тотып бирәм,— ди.

Кире баралар иде, бу кеше өйалды башына чыккан да карап тора икән. Төлке белән диюнең килгәнен күрә дә төлкегә әйтә:

— Атаңның бурычын түләргә киләсеңмени? — ди.— Атаңның җитмеш дию бирәсе бар иде, монысын

---

* Орчыкбаш — авырайту өчен орчыкның нәзек башына киертеп куела торган тимер бөҗра.

китергәч, алтмыш тугыз кала инде, әйдә китер, ди. Моны ишеткәч, дию төлкене сугып ега да әйтә:

— Атаңның бурычын түләп йөрисең икән әле син,— ди. Тагын кача дию.

Кайта торгач, бер куян моның юлын аркылы чыга. Куян әйтә:

— Болай тирләп-пешеп кая барасың, малай? — ди.

— Бу авылда бер кечкенә генә кеше дию ашап ята икән, көчкә чыгып качтым әле,— ди. Куян әйтә:

— Бик куркак кеше ул, булмас, әйдә, үзем тотып бирәм,— ди. Дию әйтә:

— Атаңның ничә дию бирәсе бар иде? Сез диюләрне закладка салып йөрисез икән,— ди. Куянны сугып ега да йөгерүен генә белә бу.

ЙОРТ ТОТМАС

Әүвәл заманда, кәҗә команда, саескан сотник, карга үрәтник чагында торганнар икән ди бер авылда карт белән бер карчык. Боларның бердәнбер генә кызлары да бар икән. Картлар үзләре ярлы гына булсалар да чамадан тыш һавалы булганнар. Шуңар күрә аларның кызларын әллә ничә урыннан кияүгә сорасалар да, сораучыларның әле бер җиреннән, әле икенче җиреннән гаеп тапкан булып кире кайтарып җибәрәләр икән.

Шулай итеп еллар узган. Бара-тора кызларын берәү дә сорамас булган. Бик озак көтеп-көтеп тә яучы килмәгәч, ахырда үзләренә чыгарга туры килгән. Үз авылларына, күрше авылларга сүз салганнар, ләкин кияү чыкмаган. Шуннан соң алар ил-күршедән өметләрен өзеп, алтмыш чакрымдагы чит авылга киткәннәр.

Авылга барып керсәләр каралтысыз, коймасыз бер өй буенда сәләмә генә киенгән бер егет утыра. Картлар аның катына барып сорашырга тотынганнар.

— Ни хәл, егет, исәнме?

— Шөкер, үзегез, саулар гынамы?

— Хатының бармы?

— Юк.

— Өйләнергә исәбең юкмы соң?

— Исәп юк түгел.

Картлар бер-берсенә карашып куйганнар. Карчык егеттән:

— Атың ничек соң, углым? — дип сораган.

— Атым Йорт тотмас,— дип җавап биргән егәт. Картлар колактан колакка сөйләшкәннәр дә рәте-чираты да күренми, йорты-җиренең дә юне юк. Исеме дә җитмәсә шундый күңелсез икән дип, алга таба киткәннәр.

Бу егет шушы авылда бер ялгызы тора; атасы-анасы юк, үзе бик ялкау, эшлексез нәрсә икән. Аны шул рәтсезлеге, дөнья көтә белмәве өчен авылдашлары «Йорт тотмас» дип йөри торган булганнар. Һәммә кеше «Йорт тотмас» та «Йорт тотмас» дип йөргәнгә аның чын исемен белүче дә юк икән. Тора-бара ул үзенең чын исемен үзе дә оныткан.

Эшлексез булса да Йорт тотмас үзе хәйләкәр икән. Картларның сөйләшүеннән аларның ни өчен килгәнлекләрен аңлаган да, тиз генә өй артларыннан әйләнеп барып, икенче бер өйнең капкасы төбендә басып торган икән ди бу. Карт белән карчыкның икесенең дә күзләре начар күргәнгә аны танымыйча башка егет дип белеп баягыча сорашырга тотынганнар. Ахырда:

— Син ни атлы соң үзең? — дип сораганга каршы, ул:

— Йорт тотмас,— дип җавап биргән. Картлар аның исемен яратмыйча тагын алга таба киткәннәр. Йорт тотмас тагын әллә кайлардан әйләнеп икенче капка алдында аларны көтеп торган. Картлар тагын аны танымаганнар. Эш исемгә килеп җиткән.

— Син ни атлы?

— Йорт тотмас.

Картлар аптырашканнар, уйлашканнар-уйлашканнар да, бу авылда һәммә халык Йорт тотмас атлыдыр ахры... Инде бәхетебез шуннандыр дип, кызларын Йорт тотмаска бирергә булганнар.

Туй уткәч Йорт тотмасны үзләренә йортка керткәннәр. Картлар йортында тора башлау белән, ул үзенең йорт тотмаслыгын күрсәтергә тотынган.

Каенатасы беркөнне аңар ат җигеп урманга утынга барырга кушкан. Йорт тотмас билен буып, балтасын кыстырган да урманга киткән. Атны агачка бәйләп куеп, шунда якында гына үскән юан бер наратны бик батырланып кисәргә тотынган. Агач ауганда ат өстенә килеп төшеп арбаны да ваткан, атны да үтергән.

Инде ни эшләргә кирәк? Йорт тотмас бераз башын кашып торганнан соң кулын селкеп өйгә таба кайтып киткән. Кайтып барышлый бер күл яныннан узганда күрә: күл өстендә үрдәкләр йөзеп йөри. Йорт тотмас, һич булмаса үрдәк алып кайтырмын дип, балтасын шуларга төзәп ыргыткан икән, үрдәкләр очканнар, балта су төбенә төшеп югалган.

Йорт тотмас күп уйлап тормыйча өстен-башын чишенеп ташлап балтаны эзләргә суга кереп киткән. Күл төбенә чумып бик озак эзләгән, таба алмаган. Кырыйга чыкса, күрә: киемнәре юк, алар урынында җилләр исә. Бу балта эзләп маташканда, бер карак килеп аның киемнәрен урлап качкан икән. Йорт тотмаска өйгә ялангач кайтырга туры килгән. Шулай ул атсыз, арбасыз, утынсыз, балтасыз, киемсез көе яшеренеп кенә авылга кайткан да шыпырт кына сәндерәгә менеп яткан. Аның кайтканын берәү дә белми калган.

Менә бер заман каенаталары белән хатыны килеп кергәннәр. Шул көнне икмәк салганнар икән. Хатыны мичтән икмәк алырга тотынган. Ипиләрне, бусы этигә, бусы әнигә, бусы үземә, бусы иремә дип, аерып-аерып куя икән. Йорт тотмасның тамагы бик ачкан икән, ул үзенә дигән ипи зур микән дип карар өчен үрелгәндә сәндерәдән егылып төшкән. Ул төшкән турыда ук идәндә дәү бер әрҗә белән каз мамыгы тора икән.

Йорт тотмас әрҗәнең эченук килеп төшкән. Аның әрҗә эченнән чыгып килгәнен күреп өйдәге халык һәммәсе җен дип белеп кычкыра-кычкыра чыгып качканнар. Алар артыннан: «Мин ул, мин!» — дип кычкырып Йорт тотмас та чыгып йөгергән. Аның өсте юеш булганга бөтен тәненә каз мамыгы сырышып, ул мамыктан әвәләгән төсле булган икән. Бер төркем халык җен дип аннан качарга, икенче төркем халык аны тотар өчен артыннан куарга тотынганнар. Шулай итеп, авыл буенча байтак чапкач, аны тотып алганнар. Йорт тотмас икәнен белгәч, җыелган халык шаркылдап көләргә тотынган. Ул оялуыннан җир тишегенә керерлек булган.

Шуннан соң аны өйгә алып кайтып мамыктан әрчегәннәр, киендергәннәр дә кулына табак биреп бал алып менәргә базга төшереп җибәргәннәр. Үзенә дигән икмәкне, табакны күтәреп, Йорт тотмас базга киткән. Икмәкне бусагага куйган да үзе баз эченә төшеп мичкәдән бал агыза башлаган. Шул вакытта гөнаһ шомлыгына каршы бер эт килеп бусага өстендәге икмәкне алып китмәсенме? Моны күреп Йорт тотмас баздан сикереп чыккан да, бал мичкәсенең чөмәкәе * белән табакны ата-ата, этне куарга тотынган. Куа-куа әллә нихәтле җир киткән. Агып калган бал мичкәдә беткәнче аккан, баздагы карны эретеп саз ясаган.

Өйдәгеләр Йорт тотмасны көткәннәр-көткәннәр дә, ахырда каенанасы аның артыннан базга киткән. Баскычтан төшкәндә аягы таеп егылган да баз эчендәге баткакка башы белән төшеп җан биргән.

Йорт тотмас этне куып-куып та икмәкне ала алмый кайтып, баздагы бу хәлне күргәч, куркып, өйгә дә кермичә, бу авылдан чыгып качкан.

---

* Чөмәкәй — мичкәнең агач бөкесе.

САРАН БЕЛӘН ЮМАРТ

Борын-борын заманда, карга казначы, козгын азанчы булып торган чагында, булган икән ди бер Саран белән бер Юмарт. Көннәрдән беркөнне болар юлга чыкканнар. Кич булгач, бер җиргә ашарга утырганнар. Саран әйткән Юмартка:

— Минем капчыкның авызы чишелми, синең ризыкларыңны гына ашап торыйк әле,— дигән.

— Ярый, ашасак ашыйк,— дигән Юмарт.

Ашаганнар Юмарт азыгын. Бер көн ашаганнар болар Юмарт азыгын, ике көн ашаганнар, өченче көнне аның азыгы беткән. Кич булгач, Саран Юмартның йокыга киткәнен саклап кына яткан да торып качкан. Юмарт йокысыннан торса, Саран юк. Юмарт аптырап калмаган, үзенә бер юл белән киткән.

Бара торгач, Юмарт бер йортка килеп җиткән. Йортка керсә, анда беркем юк ди, өстәл өстендә ярты калач кына ята ди. Юмарт шул калачтан бер телем генә кисеп ашаган да: «Бу өйнең иясе бардыр әле»,— дип, сәке астына кереп яткан.

Бервакытны бу өйгә аю, төлке, тычкан килеп кергәннәр. Тычкан иптәшләренә әйткән:

— Минем мич башында бер чүлмәк көмешем бар иде, мич башыннан сикереп төшкәндә ул «чылтырт» итеп кала торган иде,— дигән.

Аю әйткән:

— Минем казылмалы кара юл буенда ат башыдай

алтыным бар иде, аны берәү казып караган, аз гына төшеп җитмәгән,— дигән.

Төлке әйткән:

— Минем дә казылмалы кара юл янында куй башыдай көмешем бар иде, аны кемдер казып караган, аз гына төшеп җитмәгән,— дигән.

Аю, төлке, тычкан, бу өйдә төн кунып, иртә белән тагын чыгып китканнәр. Болар чыгып киткәч, Юмарт мич башыннан караган икән, анда бер чүлмәк көмеш утыра ди. Алган бу моны. Аннан киткән казылмалы кара юл белән. Казылмалы юл буендагы ат башыдай алтынны да казып алган. Бераз киткәч, тагын бер казыла башлаган җир күргән. Казып караса, монысында куй башыдай көмеш ята ди. Аны да алган.

Юмарт, бара торгач, бер урманга барып кергән. Урман эченнән барганда бер юан имән төбендә тапталган урын күргән дә бу:

— Тукта әле, дигән, агач башына менеп утырыйм әле, нәрсә булыр икән? — дигән. Шулай дигән дә агач башына менеп утырган. Кич булып, кояш баегач, имән төбенә пәри-җеннәр җыела башлаган. Байтагысы җыелгач, җеннәр башлыгы уртага килеп утырган да әйткән:

— Сукыр җен кайда? — дигән.

Сукыр җен килеп җитмәгән икән, аны алып килергә дип ике җенне җибәргән. Тегеләр барып, сукыр җенне бик хөрмәтләп күтәреп алып килгәннәр. Әлеге җеннәр башлыгы бу сукыр җеннән сораган:

— Син нигә соңга калдың? — дигән.

Сукыр җен торып әйткән:

— Минем кичегүемнең сәбәбе бар,— дигән.— Мин бер хан кызын сихерләп утырдым, аны инде миннән башка беркем дә дәвалый алмас,— дигән.

— Шулай да ничек дәвалыйсын сөйләп бир,— дигән җеннәрнең олысы.

Сукыр җен әйткән:

Зирәк карт. 36 биткә.

Күке кычкыргач, көтүче хезмәт хакы ала. 43 биткә.

— Ул ханның, дигән, өч ел буена кысыр йөргән бер кара сыеры бар. Әгәр хан шул сыерын суеп ите белән шәһәр халкын сыйласа, бу кыз һичшиксез савыгыр,— дигән.

Таң атуга җеннәр тагын таралып беткәннәр.

Юмарт туп-туры әлеге хан шәһәренә киткән. Барып җиткәч, шәһәр читендәге бер ялгыз йортка кергән. Исәнлек-саулык сорашкач:

— Я, хуҗа, сезнең шәһәрдә нинди яңалыклар бар? — дип сораган.

— Яңалык шул,— дигән йорт хуҗасы,— безнең ханның кызы бик нык авырып китте, аның авыруына дару тапкан кешегә хан үзенең ханлыгын да, кызын да бирергә булды,— дигән.

— Ярый, дигән Юмарт,— мин хан янына барып карыйм әле,— дигән.

Барган бу сарайга. Сарай сакчыларына үзенең дәвалаучы икәнен әйтеп, хан янына керергә рөхсәт сораган. Хан бу кешене сарайга кертергә кушкан. Кергәннән соң, Юмарт үзенең китабын караган була икән. Китабына карап торганнан соң әйткән бу:

— Синең көтүеңдә өч ел кысыр калган бер кара сыерың булыр, шул сыерны суеп, шәһәр халкын ашатып-эчертсәң, кызың терелер,— дигән.

Хан, моңа риза булып, нәкъ Юмарт әйткәнчә эшләгән. Күп тә узмаган, берничә көннән соң, ханның кызы терелгән. Хан Юмартка үзенең кызын да биргән, ханлыгын да биргән.

Көннәрдән беркөнне әлеге Саран да шушы шәһәргә килеп чыккан. Юмарт янына кереп, аннан ничек хан булуы, ничек патша кызына өйләнүе турында сораша башлаган. Юмарт моңа башыннан кичергәннәрнең барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп биргән.

Саран моның болай тиз баюына бик кызыккан. Ул да чыгып киткән киекләр торган йортны эзләп. Барып кергән бу әлеге өй эченә. Барып керсә, өстәлдә

баягыча ярты калач ята ди. Саран ул калачны алган да үзенең капчыгына салган. Аннары, Юмарт өйрәтүенчә, сәке астына кереп яткан. Бервакытны кайтып кергән иң беренче булып тычкан, аннан соң кайтып кергән төлке, иң соңыннан аю кайтып кергән лап-лап басып.

Карасалар, өстәлдә калач юк. Киекләргә шик төшкән.

— Мөгаен, монда кем дә булса берәү кергән булыр,— дигән төлке. Аю тычканга әйткән:

— Эзләп кара әле, кем бар икән монда? — дигән.

Тычкан мич башын караган, анда һичкем күренмәгән. Аю әйткән:

— Сәке астына кереп кара! — дигән.

Тычкан сәке астына кереп киткән дә Саранны тартып чыгарган. Тычкан Саранның өстенә сикергән, төлке битен тырнап ерткан, аю моны сугып еккан.

Шулай итеп, Саран үзенең саранлыгы аркасында хур булган, баемаган да, артмаган да.

ГӨЛЧӘЧӘК

Борын-борын заманда, зур карурман эчендә бер убырлы карчык торган ди. Аның бер улы белән Гөлчәчәк атлы бер килене булган ди. Карчык бик явыз икән ди, гомер-гомергә яхшы кешеләрне簡дырып, батырларны юлдан яздырып йөргән ди. Карчыкның улы, анасының явызлыгына түзә алмыйча, дөнья гизәргә, бәхет эзләргә чыгып киткән.

Гөлчәчәк әниләрен бик сагына икән, тик аны каенанасы — убырлы карчык бер җиргә дә чыгармый икән, үзе төннәрен яхшы кешеләрне аздырырга, батырларны юлдан яздырырга чыгып киткәндә дә киленен өендә биклөп калдыра икән ди.

Төннәрдән бертөнне, убырлы карчык үзе чыгып киткәндә ишеккә йозак салырга оныткан ди. Кәлгә салган көмәчләрен дә калдырып киткән ди.

Аның чыгып китүе булган ди, ишекнең ачык калуын белгәч гә, Гөлчәчәк әниләренә китәргә җыена башлаган ди:

— Урман эче бик якты,
Күктә айлар калыкты.
Көлдән күмәч аламын,
Әниләргә барамын,
Әниләргә барамын,—

дип җырлый-җырлый, куенына төче күмәч кыстырган да ди, әниләренә кунакка дип чыгып киткән ди.

Төн киткән, көн киткән, бара торгач, байтак җир киткән. Ул арада убырлы карчык кире әйләнеп кайткан да, килене артыннан куа чыккан. Соры бүре төсенә кергән дә ди, җирне исни-исни чабып киткән ди, чаба торгач, киленен куып җиткән ди. Гөлчәчәкнең каршысына төшкән дә ди, калын тавыш белән улап җибәргән ди:

— Келтә-келтә койрыгым,
Болгый-болгый улаем.
Күмәчләремне бирмәсәң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан, күмәч биреп кенә котылыр иде дә, ул вакытта инде аның күмәче калмаган. Ары каранган ди, бире каранган ди, якында гына тузгак башлы, куыш эчле зур бер карама күргән ди, шул карамага ялына башлаган ди:

— Әйләнмәле карама,
Бәйләнмәле карама,
Соры бүре куып җитте,
Яшерсәнә, карама,
Яшерсәнә, карама.

Әйләнмәле карама Гөлчәчәкне бик кызганды ди, тиеннәр чикләвек җыеп, ярканатлар куныш чыга торган кечкенә куышының ишеген ачып җибәргән иде ди, Гөлчәчәк куышка керде дә качты ди.

Соры бүре карама төбен тырный-тырный улаган да ди, Гөлчәчәкне чыгара алмагач, таң алдыннан өенә кайтып киткән ди.

Ул арада таң аткан, кояш чыккан, көн булган. Гөлчәчәк, карамага рәхмәт әйтеп, тагын үз юлына чыгып киткән. Бара торгач кич булган, соры бүре, килененең эзеннән исни-исни барып, тагын куып җиткән.

Гөлчәчәкнең алдына төшеп, тагын улап җибәргән ди:

— Көлтә-көлтә койрыгым,
Болгый-болгый улаем.
Кумәчләремне бирмәсәң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан ди. Ары караган ди, бире караган ди, түгәрәк аланда бик матур бер күл бар икән, Гөлчәчәк шул күлгә ялына башлаган ди:

— Түгәрәк алан, көмеш күл,
Көмеш күлнең суы мул.
Соры бүре куып җитте,
Яшерсәнә, көмеш күл,
Яшерсәнә, көмеш күл.

Көмеш күл Гөлчәчәкне бик кызганган ди, тирән суын айкалдырып, дулкыннарын чайкалдырып, Гөлчәчәк басып торган җирне тирән су белән урап алган ди, соры бүре күл читендә бүленеп калган ди.

Соры бүре күл читен тырный-тырный төн буе улаган да, Гөлчәчәк янына керә алмагач, таң алдыннан тагын өенә кайтып киткән ди.

Ул арада таң аткан, кояш чыккан, көн булган. Гөлчәчәк көмеш күлгә рәхмәт әйтеп, тагын үз юлына чыгып киткән. Барган ди, барган ди, иртә киткән, кич киткән, китә торгач урманның кырыена ук чыгып җиткән. Инде әниләренең өй түбәләре дә күренә башлаган ди. Тик шул урында соры бүре тагын куып җиткән дә ди, бу юлы бигрәк тә каты ачуланып улап җибәргән ди:

— Көлтә-көлтә койрыгым,
Болгый-болгый улаем.
Кумәчеңне ашатмасаң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан. Ары каранган, бире каранган да басу кырыенда үсеп утырган кушкаенга менеп киткән ди. Соры бүре кушкаенның тамырларын казый башлаган ди.

Гөлчәчәк бик курка икән ди.

— Инде монда кайгып җиткәч тә әниләрне күрмичә үләрмен микәнни соң,— дип әйтеп, бик елап утыра икән ди, шунда кушкаен башына бер сыерчык килеп кунган ди. Гөлчәчәк сыерчыкка ялына башлаган ди:

— Ала муен сыерчык,
Кола муен сыерчык,
Чәч бөртегем эманәтем,
Илтеп бирче, сыерчык,
Илтеп бирче, сыерчык.

Гөлчәчәк сыерчыкка бер-ике чәч бөртеген алып биргән ди, сыерчык аны алып Гөлчәчәкләрнең әниләренә очып киткән дә ди, чәч бөртеген аларның капкаларына элеп куйган ди.

Гөлчәчәкнең абыйсы капка төбенә чыккан икән, чәч бөртекләрен күргән.

— Әһә, кара юргам кашынып торганда ял бөртекләре калган икән дип әйтеп, чәч бөртеген алып кереп думбрага кыл итеп тарткан ди.

Гөлчәчәкнең җиңгәсе думбраны аяк тибеп бии-бии уйный башлаган икән, думбра кылы Гөлчәчәк булып җырлап җибәргән:

— Бии-бии уйнама,
Бил генәем авырта,
Тибә-тибә уйнама,
Түбәләрем авырта...

Моңар җиңгәсенең исе киткән:

— Әбәү, бу думбрага ни булган? — дип әйтеп, думбраны иренә биргән. Ире чиертеп-чиертеп уйный башлаган икән, думбра тагын җырларга тотынган:

— Басма, басма, абыем,
Башкынаем авырта.
Чиртмә-чиртмә, абыем,
Чәчкенәем авырта.
Урман буе кушкаен,
Кушкаенда сеңлең бар,
Кушкаенның төбендә
Каенанам убыр бар.
Думбраңны куй, абый,
Кушкаенга кил, абый.

Шуннан соң абыйсы:

— Карасана, Гөлчәчәк сеңлем харап була язган бит,— дип, чукмарын алган да ди, бүре тибә торган атына атланып, урман буена чапкан ди. Ул барып җиткәндә, соры бүре кушкаенның тамырларын актарып бетерә язган иде ди, кушкаен менә авам, менә авам дип кенә торадыр иде ди.

Гөлчәчәкнең абыйсы соры бүрене бәреп үтергән дә ди, Гөлчәчәкне өйләренә алып кайткан ди.

Шуннан бирле Гөлчәчәк бик әйбәт гомер итә башлаган ди.

Бүген барып кичә кайттым, мин дә булдым аларда. Сый-хөрмәт бик дан булды, ашатканнары май, эчергәннәре бал булды. Ике мичкә, бер чүмеч, теләсәң күпме эч. Тик авызга эләкми, мыек кына чылана.

КАРЧЫК БЕЛӘН АЮ

Борын заманда күрше авылдан кайтып килгән чагында бер карчыкны аю тотып алган, ди. Аю карчыкны урманга алып керә дә кунак итә башлый. Бал ашата, җиләк ашата. Карчык ашаса да ашый, ашамаса да ашый. Бераз шулай кунак булганнан соң, карчык әйтә:

— Аю дус, ди, мин карчык кеше инде, син мине җибәр, ди. Өйдә минем өч кызым бар, алар өчесе дә бик матурлар. Шуларның берәрсенә өйлән, булмаса, кайсын теләсәң, шунысын алырсың, ди. Кызларның олысы Сак-сок кына атлы, икенчесе — Бик-бик кенә, өченчесе Инде-инде генә атлы,— ди.

Ярый, аю карчыкны кайтарып җибәрде, ди. Кич булды, караңгы төште. Караңгы төшү белән аю лаплап басып кызлар йоклый торган келәт янына килде. Дөбердәтә бу келәт ишеген:

— Сак-сок кына, ишекне ач әле! — ди.

Олы кыз әйтә:

— Үзебез дә сакланып кына ятабыз, ди, йөрмә монда,— ди.

— Бик-бик кенә, ишекне ач әле,— ди.

Уртанчы кыз әйтә:

— Үзебез дә бикләнеп кенә ятабыз, йөрмә монда,— ди.

Аю өченче тапкыр дөбердәтә:

— Инде-инде генә, ишекне ач әле,— ди.

Кече кыз әйтә:

— Инде моннан соң урманга җиләккә дә бармабыз, йөрмә монда,— ди.

Шуннан соң этләр бик каты өрә башлыйлар. Аю куркуга төшә: «Их, ди, карчык башы белән мине алдап китте бит!» — дип урманга кача.

ҮТКЕН КИЯҮ

Әүвәлге заманда,— песиләре яланда, эте ята саламда,— бер кеше кызын кияүгә биргән ди. Алар башта үзара бик тату булганнар, кияүне бик яратканнар, тик соңыннан нилектәндер аралары бозыла башлаган ди.

Бердәнбер көнне кияү бабаларына киткән. Бабалары пешергән икән ул көнне юка белән каз. Кияү килгәнне күргәч, казны тыкканнар юллыкка, юканы кыстырганнар түшәк астына. Кияү моны тәрәзәдән күреп калган.

Кияү кергән, шулай, утырган. Кияүнең бик боек утырганын күргәч, бабасы әйткән:

— Кияү, ишеткәнне-күргәнне сөйләшә утырыйк,— дигән.

Кияү әйткән:

— Бабай, ишеткәнне сөйләсәң, ялган булыр, күргәнне генә сөйлик,— дигән.

Бабасы әйткән:

— Ярый алайса, күргәнне генә сөйлә,— дигән.

Кияү сөйли башлаган:

— Менә, бабай, сезгә килгәндә, дигән, авыл башында күрдем бер елан. Шул еланга юллыктагы каз хәтле бер таш белән китереп бәргән идем, түшәк астындагы юка шикелле җәелде дә китте! — дигән.

Карт әйткән карчыгына:

— Кая, карчык, болай булмады бу, казны да китер, юканы да китер! — дигән.

Шуннан соң алар бик тату яши башлаганнар ди.

ХӘЙЛӘКӘР КЕШЕ

Борын заманда бер тегүче шәһәрдә тегү тегеп торган. Аңа шул шәһәрдәге кешеләр бер-ике аршын туладан чикмән тегәргә кушалар икән дә ди, бу шуннан чикмән тегеп бирә икән, ди. Шулай булса да бу тегүчегә «Урлап каласың»,— дип әйтәләр икән ди. Бу тегүче, боларның сүзеннән котылыйм дип, беркөнне кич белән шәһәрдән чыгып киткән. Юлда барганда моңар бер шайтан очраган. Исәнлек-саулык сорашып, берберсенә хәлләрен сөйләгәннәр.

Тегүче әйткән:

— Фәлән шәһәрдә тегү тегәдер идем, шәһәр кешеләре ике аршын тула китерсәләр, шуннан чикмән тегеп бирә идем, шулай да һәрвакытта, син урлап каласың, дип әйттеләр. Менә шуңа чыдый алмый шәһәрдән чыгып киттем,— диган.

— Мин дә бер авыру, зәгыйфь шайтанмын. Башка сәламәт шайтаннар зарар итсәләр, алдасалар да миңа ябалар иде, җанымны газаплыйлар иде. Без икебез дә бертөсле икәнбез, шулай булгач без икебез дус булыйк,— ди шайтан. Болар дус булып тагын киткәннәр. Бара торгач, боларга очраган бер аю. Болар икесе дә хәлләрен аюга сөйләп биргәннәр. Аю да әйткән:

— Мине дә бик борчыйлар. Шушы тирәдәге авыл кешеләренең сарык, сыерларын бүреләр ашап китәләр дә, аны миңа сылтап, урынсызга бәла ягалар. Без өчебез дә бертөсле икәнбез,— дип, өчесе дә дус булып, бергә киткәннәр.

Бара-бара болар барып җиткәннәр бер карурманга.

— Шушы урында йорт салып торсак яхшы булыр,— дигән тегүче.

Өчесе бергәләп бер йорт салып, кибет ачып сату итә башлаганнар. Көннәрдән беркөнне тегүче белән шайтан авылга чыгып киткәннәр. Йорттагы, кибеттәге нәрсәләрне аюга калдырып, карап торырга кушканнар. Бер заман аю янына дию пәрие килгән.

— Ни эшләп утырасың? — дигән.

— Йортлар, кибетләр карап, сату итеп торамын,— дигән аю.

Дию пәрие, монда нинди әйберләрең бар, фәлән дип сорашып йөргән булып, барлык әйберләрен ашап бетереп, аюның үзен кыйнап киткән.

Бер заман тегүче белән шайтан кайтканнар. Аю аларга бернәрсә дә сөйләмәгән. Икенче көнне шайтан калган. Дию пәрие тагын килеп, шайтанны кыйнап, булган әйберләрен ашап киткән. Өченче көнне тегүче калган йортлар саклап. Дию пәрие килеп тегүчедән:

— Нишләп утырасың? — дип сораган.

Тегүче әйткән:

— Музыка уйнап утырам,— дигән. Ул арада бу кеше кабыктан кубыз ясап алган икән.

Дию пәрие әйткән:

— Миңа да ясап бирсәнә,— дигән. Тегүче әйткән:

— Ясавын ясар идем дә бит, кабык юк,— дигән. Дию әйткән:

— Кабыкны каян табарбыз икән? — дигән. Тегүче:

— Кабык ерак түгел, менә минем белән барсаң, кабыкның кайда икәнен күрерсең,— дип, диюне үзе белән алып киткән. Кеше кулына балтасын алып бер бик каты агачка чапкан да әйткән пәригә:

— Тык кулыңны шушы ярыкка,— дигән. Пәри кулын тыгуы булган, тегүче балтасын алган. Пәринең

кулы бик каты кысылган. Шуннан соң тегүче балтасы белән пәрине кыйный башлаган. Дию пәрие, зинһар кулымны җибәрсәнә, дип тегүчегә ялына башлаган. Тегүче:

— Миңа ике алтын китереп бирәсеңме, җибәрәм,— дигән. Дию пәрие тегүчегә ике алтын китереп бирергә сүз биргән ди. Шул арада аю белән шайтан да кайтып җиткәннәр дә, алар да диюне вата башлаганнар.

Дию боларга бер дә тимәскә ант иткән. Шуннан соң гына тегүче диюне җибәргән. Икенче көнне диюдән ике алтын килгән. Болар алтынны бүләргә булып, өйгә кереп утырып, алтыннарны саный башлаганнар. Шул арада дию килеп харап итмәсен дип, берәм-берәм каравыл торалар икән. Әүвәл торган аю шак-шок итеп, икенче булып шайтан торган, өченчесенә тегүче чыккан. Бу тегүче бераз вакыт шакылдатып йөргән дә, өйгә йөгереп кереп:

— Харап булдык, дию пәрие гаскәрләрен алып килеп җитте,— дигән. Аю белән шайтан тәрәзә ватып чыгып качканнар. Тегүче барлык маллар, алтыннарны җыеп алып, авылына кайтып, йорт салдырып җибәргән ди.

ЯХШЫЛЫККА ЯМАНЛЫК

Борын заманнарда булган икән ди бер карт кеше. Көннәрдән беркөнне бу карт капчыгын алып киткән ди күрше авыл базарына. Ярты юлны үтеп урман эченә керү белән моның артыннан бер бүре куып җитә. Бүре әйтә:

— Әй, бабай, ди, минем артымнан Ялан атлы * ике кеше куып килә, ди, зинһар, син мине алар кулыннан коткарып кал, миңа яхшылык итә күр инде,— ди.

— Яхшылык итәр идем дә бит,— ди карт,— мин сине ничек итеп кенә коткарырмын икән соң?

— Капчыгыңа салып күтәреп китә алсаң, алар күрми үтеп китәрләр еле,— ди бүре.

Әлеге бабай бу бүрене капчыгына салып күтәреп алып китә. Озак та үтми, теге атка атланган ике кеше килеп җитә бу карт артыннан.

— Әй, бабай,— ди берсе бу егетләрнең,— сине берәр бүре куып җитеп узмадымы? — ди. Карт:

— Юк, улым, ди, бернинди җан иясен күрмәдем, ди, мине куып җитүче дә, узып китүче дә булмады,— ди.

Ярар. Атка атланган аучылар, ах, бу бүре юл ялгыштырып читкә сикергәндер ахры, башка берәр якка киткәндер дип уйлап, кире борылып китәләр, ди. Боларның кире китүен белү белән капчыктагы бүре телгә килеп:

---

* Ялан атлы — атка атланган кеше.

— Ярар, ди, алар инде монда кире борылып кайтмаслар, син мине бушата күр *, мин үз юлым белән китим инде,— ди. Карт капчыгын җилкәсеннән төшереп бүрене чыгарып җибәрә. Капчыктан килеп чыгу белән бүре:

— Ярар, бабай, син мине аучылар кулыннан коткарып алып калдың, ди, ә хәзер инде менә мин синең үзеңне ашыйм, ди. Бу дөньяда яхшылыкка яхшылык түгел, яхшылыкка яманлык кына,— ди.

Бүредән бу сүзләрне ишеткәч, бабай бик каты куркып, аптырашка калды. Шуннан соң бабай курка-курка гына:

— Ярар, ди, без бу турыда өч җан иясен күреп: «Бу дөньяда яхшылыкка яхшылыкмы, әллә яхшылыкка яманлыкмы?» — дип сорап карыйк ди. Алар яхшылыкка яманлык дип әйтсәләр, син мине тотып ашарсың,— ди.

— Ярар,— ди бүре.

Шулай сөйләшәләр дә китәләр болар бер юлга төшеп. Бара торгач очрыйлар болар үлән ашап йөргән бер атка. Бу ат янына барып бабай сорады моннан:

— Ну, ничек, ди, бу дөньяда яхшылыкка яхшылыкмы, әллә яхшылыкка яманлыкмы? — ди. Ат бик озак уйлап тормыйча гына:

— Менә мин, ди, егерме биш ел буена гомер иттем, бөтен авыр эшләрне эшләдем, хуҗама иген игәргә булыштым, ди, әмма ләкин, ди, картая башлау белән хуҗам мине таяклап куып чыгарды,— ди.

Ат яныннан китеп, чыбыклыклар үтеп барып җиттеләр, ди, болар бер нуга **. Анда бер сыерга очрадылар. Бу сыер бик картайган, мөгезләре кыйшайган, иреннәре салынып төшкән иде, ди. Бабай сыер янына барып:

---

* Бушата күр — җибәрә күр.
** Ну — болынлык.

— Син бик күп гомер иткәнсең күренә, әйт әле, бу дөньяда яхшылыкка яхшылыкмы, әллә яхшылыкка яманлыкмы? — ди. Сыер уйлап та тормады:

— Менә ничек, ди, мин, ди, хуҗама бик күп сөт бирдем, аның үзен, бала-чагасын сөт-майга мохтаҗ итмәдем, ди. Картая башлау белән куып чыгарды, ди. Бу дөньяда, ди, сыер әйтә, яхшылыкка яманлыктан башка нәрсә юк,— ди.

Киттеләр болар өченче җан иясен эзләп. Бардылар, йөрделәр ди бу карт белән әлеге бүре, йөри торгач очрадылар ди болар бер төлкегә. Төлкене каршыларына утыртып сөйләп бирделәр ди болар нинди-нинди хәлләр булганын. Төлкә тыңлап торды-торды да ди:

— Ярар, бабай,— дип әйтте ди,— сабыр ит, ике арагызда ниләр булганын бүре үз авызы белән сөйләп бирсен әле,— ди.

Бүре бәйнә-бәйнә сөйләп бирде:

— Бу дөньяда яхшылыкка яманлык кына бар, шуның өчен менә мин бу картны ашарга тиешмен,— ди.

— Ә соң, ди, төлке, ул сине менә шушы капчыкка салып коткарып калдымыни? — ди.

— Ийе,— ди бүре,— капчыгына салып алып калды,— ди.

— Ышануы кыен,— ди төлке,— син ул капчыкка сыярлык хайван түгел бит,— ди.

— Ышанмасаң, менә мин кереп күрсәтә алам,— ди бүре.

— Күрсәт, сыймыйсың бит син анда,— ди. Бүренең капчыкка кереп ятуы була, бабай капчык авызын бәйләп тә куя. Шуннан соң төлке сорый моннан:

— Я, бабай, ди, ашлыгыгызны урып алгач көлтә итеп бәйләгәнсездер. Көлтәләреңнең башагын ничек итеп койдың соң син? — ди. Бабай зур гына бер таяк алып капчыктагы бүренең башына суга башлады:

— Менә шулай итеп койдык без ашлыкның башагын,— дип. Шулай итеп, бабай бүрене үтерде.

КӘКРЕ КАЕННЫ ТЕРӘТКӘН

Борынгы заманда бер алдакчы кеше бар икән, теләсә кемне алдый ала икән. Үзен бик акыллыга санап йөргән тагын бер кеше бар икән, шул кеше әйтә икән:

— Мин шул Алдарга очрасам, аңа һич тә алдатмас идем,— ди икән.

Бервакыт бу кеше юл буйлап барганда күрә, әлеге Алдар бер кәкре каенны терәп тора, имеш. Бу аның янына барып әйткән:

— Я, дус, сине алдарга бик оста дип әйтәләр, мине дә алдый алырсыңмы икән, я, алдап кара әле,— дигән. Алдар әйткән:

— Нигә сине алдый алмам икән? Бик тиз алдар идем дә янымда алдар капчыгым юк шул, өйдә калды,— дигән. Бу кеше Алдарга әйткән:

— Бар, өеңнән капчыгыңны алып кил, мин монда көтеп торырмын,— дигән. Алдар аңа әйткән:

— Өйгә бик кайтыр идем дә, менә бу каен аварга тора, китәргә ярамый бит,— дигән. Бу кеше, бик үрсәләнеп:

— Барсана, капчыгыңны китерсәнә, син килгәнче каенны үзем терәп торырмын,— дип, кәкре каенны терәп калган.

Алдар шул китүдән киткән ди, бу кеше әле дә булса кәкре каенны терәп тора ди.

ШӘРӘ БҮРЕ

Булган ди бер соры бүре. Беркөнне ул ары чапкан, бире чапкан, бер дә ашар нәрсә тапмаган. Йөри торгач, яланда бер бик шәп айгырны очраткан. Бүре айгырга әйткән:

— Айгыр, мин сине ашыйм, минем хәзер өч көннән бирле бернәрсә дә ашаганым юк, — дигән.

Айгыр әйткән:

— Ашасаң ашарсың, тик минем бер үтенечем генә бар, шуны гына тыңлый күр,— дигән.

— Нинди үтенеч ул, әйт тизрәк,— дигән бүре.

Айгыр әйткән:

— Минем койрык очында бик кыйммәтле алтын кыл бар, шул кылны йолкып ала күрсәнә, аннан соң ашарсың,— дигән.

Бүре, алтын кылны йолкырга дип, аның койрыгына барып тотынган икән, айгыр кушаяклап бүрегә тибеп җибәргән. Бүре әйләнә-әйләнә барып төшкән, ә айгыр авылга таба чабып киткән. Бүре һушыннан китеп бик озак ятканнан соң торган да: «У-у... у... ач калдым... Атның койрыгында алтын кыл булганын кайчан күргәнең бар...» — дип улап җибәргән. Аннары акрын гына атлап су буена төшеп киткән. Йөри торгач, су буенда бер зур үгезне күреп алган да:

— Әй, хайван, яхшы очрадың әле, бик симез дә икәнсең, мин сине ашыйм,— дигән. Үгез каушап калмаган:

— Бүре абзый, ашасаң ашарсың, мин каршы килмим. Менә минем колагымда бер сәгать бар, шуны элек читкә алып куй, ватылып әрәм булмасын, аннан соң ашарсың,— дигән.

Бүре каршы килмәгән. Сәгатьне алып куйыйм дип үгезнең колагына таба килә башлаган. Үгез чамалап кына торган да, бүрене, мөгезләре белән эләктереп, баш аркылы чөеп җибәргән. Бүре бөтерелә-бөтерелә барып төшкән. Үгез койрыгын селти-селти чапкан. Бүре бераз яткач торган да улап җибәргән: «У-у... у... ач калдым... Үгезнең колагында сәгать булганын каян күргәнең бар...» Шуннан соң бүре, салмак кына атлап, авылга таба киткән.

Авылда инде халык йоклаган булган. Бүре авыл башындагы бер кешенең абзарына барып кергән. Ул абзарда бер кәҗә генә тора икән. Бүре кәҗәгә:

— Кәҗә сеңлем, мин сине ашарга килдем,— дигән.

Кәҗә, сакалларын селкеп, бераз уйлап торган да:

— Бүре абзый,— дигән,— ашасаң ашарсың, мин һич тә каршы килә алмыйм. Үзең беләсең, мин юаш хайван, тик син ашаганчы, мин үземнең бер эшемне генә үтәп калыйм, аннан соң ашарсың,— дигән.

— Нинди эш ул тагын?— дип җикеренгән бүре.

Кәҗә мескенләнеп кенә болай дигән:

— Безнең авылның мәзине үлде. Мин шуның урынында калдым. Мин тиз генә абзар түбәсенә менеп азан әйтеп төшим. Аннан соң ашарсың,— дигән. Бүре каршы килмәгән. Кәҗә абзар түбәсенә менгән дә: «Мул-ла-га-ли-и!.. Мул-ла-га-ли-и!..» — дип кычкыра башлаган. Кәҗәнең хуҗасы Муллагали исемле икән. Ул тиз генә өеннән тимер сәнәк күтәреп чыккан да бүрене куа башлаган. Бүре кая керергә урын тапмыйча урманга таба качкан.

Аптырап йөри торгач, бүре авыл очындагы тегермәнгә барып чыккан. Тегермәндә ул бер кешене дә

очратмаган. Анда бары тик хәйләкәр төлке генә булган. Бүре төлкегә әйткән:

— Төлке туган, бик яхшы очрадың әле. Өч көннән бирле инде тамагыма бернәрсә дә капканым юк. Хәзер нәрсә туры килсә шуны ашыйм дигән сүзем бар. Без синең белән бер урманда торсак та, мин сине бүген барыбер ашыйм инде,— дигән. Төлке бүрегә әйткән:

— Әй, бүре абзый, син бит урмандагы җәнлекләрнең патшасы. Матурларның-матуры, акыллыларның-акыллысы. Синең сүзгә каршы килү мөмкинме соң?! Тик менә шунысы бар. Мин бит монда хәзер укытучы булып эшлим. Төрле җәнлекләрнең балаларын укытам. Әгәр дә син мине ашасаң, ул вакытта минем укучыларым надан калалар бит. Мин сиңа бик яхшы бер киңәш бирәм. Син ач булсаң, мин синең тамагыңны туйдырырмын. Менә синең дә балаларың бар. Алар укымыйча надан калмасыннар. Син аларны миңа китер. Мин аларны укырга-язарга өйрәтермен. Картайган көнеңдә үзең дә миңа рәхмәт әйтерсең,— дигән. Бүрегә он салып биргән, бүре онны ялап туйган да, шундук өенә кайтып, балаларын төлкегә укырга китергән.

Бүре кайтып киткәч, төлке ашыйсы килгән саен моның балаларын берәм-берәм тотып ашап бетергән. Бераз вакыт үткәч, бүре тегермәнгә килгән дә:

— Балаларымның хәлен белеп кайтыйм әле дип килдем. Ничек укыйлар, бик шаярмыйлармы?— дип, төлкедән сораштыра башлаган. Төлке бик ялагайланып кына болай дигән:

— Бик хуш килдең, бүре дус. Балаларың ай-һай зирәк булып чыктылар, бик шәп укыйлар. Хәзер укырга да, язарга да өйрәнеп киләләр. Үзләре хәзер генә су буена уйнарга, гимнастика дәресенә киттеләр. Мин аларны хәзер алып кайтырмын, син монда он

ялый тор,— дигән. Шулай дигән дә тегермән ташы өстенә он салып биргән. Бүре тыныч кына он яларга тотынган. Ул арада хәйләкәр төлке, иплән кенә чыккан да, тегермәннең арыгын ачып җибәргән. Тегермән ташы шундук бик кызу әйләнә башлаган. Таш өстендә он ялап торган бүре бәтерелә-бәтерелә тегермән стенасына барып бәрелгән. Ул арада төлке инде үз юлына сызган. Бүре, бик озак һушсыз ятканнан соң торган да, тегермән янындагы тау башына менеп: «У-у-у... ач та калдым, балаларсыз да калдым... Дөньяда төлкенең укытучы булганын каян күргәнең бар»,— дип, сузып-сузып улаган да урманга таба юл алган.

Ач бүре, аптырап йөри торгач, тагын төлкене очраткан. Төлке бер печән кибәне төбендә бик тәмләп кенә ит ашап утыра икән. Бүре, төлкене күрү белән үк:

— Әһә, алдакчы, эләктеңме? Хәзер мине хәйләләп котыла алмассың инде,— дип, тегенә таба килә башлаган. Төлке бүре янында тагын ялагайланырга тотынган:

— Әй, бүре абзыкаем! Мин синең сүзләреңә каршы килмим бит. Тик мине ашап кына тамагың туймас шул. Мин үзем дә синең кебек күп вакыт ач йөрим ич. Итемнең дә тәме булмас, коры сөяк кенә булыр. Син минем итемне ашаганчы, сарык ите аша.— Төлке шулай дип, кибән астыннан бер калҗа сарык ите чыгарып биргән. Бүре аны кабып та йоткан.

— Әгәр аз дип әйтсәң,— дигән төлке хәйлә корып,— әнә теге сарыкларны кибән янына куып китерермен. Теләгәнең үзең тотып ашарсың,— дигән. Тау буенда сарык көтүе утлап йөри икән. Сарыкларны күргәч, бүренең күзләре кызган. Төлкенең тәкъдименә берсүзсез риза булган ул. Ә төлке аңа болай дигән:

— Алайса син, шушы кибән башына мен дә печәнгә күмелеп утыр. Юкса, сарыклар сине күреп куркырлар, килмәсләр. Ә мин аларны тиз генә кибән янына куып китерермен. Алар кибән янына килеп печән ашарга тотынгач та, син кибән өстеннән төшәрсең дә теләгәнеңне тотып ашарсың,— дигән.

Бүре шатлана-шатлана кибән башына менеп яшеренгән. Аның яшеренүе булган, төлке печән кибәненә ут төртеп җибәргән. Печән чатыр-чотыр яна башлаган. Бүре, кибән янган тавышны ишетеп, үз-үзенә: «Әнә киләләр, аяк тавышлары да күп ишетелә. Менә тамак туя!» — дип шатланып печәнгә тагын да тирәнрәк күмелә икән. Ул арада ут бүрене бөтенләй үк камап алган. Мескен бүре ялкын эченнән көчкә генә котылып чыккан. Ләкин тәнендә бер генә бөртек тә йоны калмаган, көеп беткән. Шәрә бүре, артына карый-карый, урманга таба чапкан. Шулай чабып барганда, күрше авылдан кайтып килүче бер тегүчене очраткан. Бүре тегүчегә:

— Әй, кеше, яхшы очрадың әле. Менә бер атналап инде тамагыма бернәрсә дә капканым юк. Мин сине хәзер ашыйм, — дигән. Тегүче бер дә аптырап калмаган, бүрегә әйткән:

— Ашасаң ашарсың, сиңа каршы килеп булмас,— дигән,— тик менә сиңа карап торам да кызганам үзеңне: йоның бер дә калмаган икән, ә бит озакламый салкын кыш җитә. Ул вакытта болай шәрә килеш яшәве сиңа бик кыен булыр. Мин үзем бик оста тегүче, каршы килмәсәң, сиңа шушы билбавымнан бик яхшы бер бишмәт тегеп бирер идем. Аннан соң ашасаң ашарсың. Тамагың да туяр, өстең дә бөтәер.

Шулай дигәч, тегүче бүрегә бишмәт үлчәргә керешкән. Бүре каршы килмәгән. Тегүче бүренең койрыгыннан урап тоткан да, кулындагы тимер аршыны белән:

— Бер аршын... ике аршын... өч аршын...— дип, тегенең кабыргаларын бик әйбәтләп саный башлаган. Бүре, кабыргалары авыртуына түзә алмыйча:

— Я, җитәр инде, тегүче абзый. Бик озын булмасын, мин бит бик күп җирләрдә йөрим. Артык озын булса, итәкләре пычранып әрәм булыр,— дип, тегүчегә ялына башлаган. Тегүче аның ялынуына карамаган, бүренең кирәген биргән дә биргән. Ахырда шәрә бүре хәлдән таеп җиргә егылган, ә тегүче көлә-көлә үз юлына киткән.

КАЛАЧ

Карт белән карчык булган ди. Ашарларына бетеп киткән ди. Әле карчык чыга да бура төпләреннән онны себереп ала. Себереп ала да калач пешерә. Калачны пешерә дә тәрәзә төбенә куя. Караса, калач тәрәзә төбеннән тәгәрәп төшә дә китеп бара.

Бара торгач калачка бүре очрый.

— Син кая барасың, калач,— ди бүре,— минем карыным ач, сине ашыйм,— ди.

— Син мине ашама,— ди калач,— мин сиңа җыр җырлыйм,— ди.

— Я, җырыңны җырла,— ди. Калач җырын җырларга тотына.

Әбиемнән дә качтым мин,
Бабамнан да качтым мин,
Синнән качам да качам,—

ди. Шулай дигәч, бүре моны ашамый узып китә. Шулай барганда калачка аю очрый. Аю да шулай ук әйтә:

— Минем карыным ач, мин сине ашыйм,— ди.

— Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм,— ди калач.

— Я, җырла җырыңны,— ди аю.

Әбиемнән дә качтым мин,
Бабамнан да качтым мин,
Бүредән дә качтым мин,
Синнән качам да качам,—

дип тагын такмаклый бу. Аюга да бу җыр бик кызык булып күренә. Бу да ашамый узып китә.

Тагын китә бу. Бара торгач моңарга төлке очрый. Төлке хәйләкәр була инде.

— Кая барасың, калач агай,— ди төлке.

— Барам әле,— ди.

— Мин сине ашыйм хәзер,— ди төлке.

— Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм,— ди калач.

— Я, җырлап кара,— ди төлке.

Әбиемнән дә качтым мин,
Бабамнан да качтым мин,
Бүредән дә качтым мин,
Аюдан да качтым мин,
Синнән качам да качам,—

ди калач.

— Ярар, алай булгач чалкан ятып кара әле,— ди төлке.

Калач чалкан яткан иде, төлке моны ашый да китә. Шуның белән әкият тә бетә.

АК АЮ

Борын заманда бер карчыкның өч кызы булган ди. Олы кызы моның гел җиләккә барам дип аптырата икән ди.

Беркөнне иптәш кызлары белән җиләк җыярга киткән бу. Урманга барып җиләк җыя башлаганнар икән, теге кызны ак аю күтәреп алып киткән. Иптәш кызлары моны күреп куркып кайтып киткәннәр. Бу кызны әнисе көтә-көтә дә кайтмагач иптәш кызларына бара сорарга.

— Минем кызым кайтмады, кая ул,— дигән.

— Син кызыңны көтмә инде, аны ак аю алып китте,— дигәннәр.

Әнисе елый-елый кайтып киткән ди.

Берничә көннәр үткәч, икенче кызы да җиләккә барам дип аптырата башлый. Бусы да иптәш кызлары белән җиләккә киткән. Җиләк җыя гына башлаганнар икән, моны ак аю күтәреп алып киткән ди. Иптәш кызлары куркып кайтып киткәннәр. Кызлар өйгә кайталар, ә теге кызның әнисе көтә-көтә, бу юк. Тагын китә иптәш кызларына.

— Көтмә инде син кызыңны, аны ак аю алып китте,— диләр тегеләр. Әнисе елый-елый өенә кайтып киткән ди.

Күп тә үтми, өченче кыз җиләккә барам дип аптырата башлаган. Әнисенең җибәрәсе килми: «Икә апаңны да ак аю алып китте, сине дә алып китәр»,—

ди. Алай да кыз чыгып китә. Барып җиләк җыя гына башлаганнар икән, бу кызны да ак аю күтәреп алып киткән ди. Әнисе кызны көтә-көтә дә кайтмагач кайгырып иптәш кызларына бара.

— Син кызыңны көтмә инде, аны ак аю алып китте,— диләр.

— Өч кызымнан берсе дә калмады,— дип елый-елый өенә кайтып китә әнисе.

Моның зур кызы бик үткен булган икән. Ак аю чыгып йөри торган булган. Бер дә бер заман әйткән бу аюга:

— Мин әнигә посылка җибәрер идем,— дигән.

— Ярар,— дигән аю,— хәзерләп куй, үзем илтеп кайтырмын,— дигән.

Олы кыз иң кече сеңлесен капчыкның төбенә салып, өстенә ашый торган әйберләр: ләвәшләр, бәлешләр салып капчыкның авызын бәйләп куйган ди. Ак аю кайткан, ашаган-эчкән дә посылканы күтәреп чыгып киткән ди. Кыз әйткән:

— Кара аны, ачып карыйсы булма, мин җиллектән * карап торырмын, син нәрсә эшләсәң дә күрермен,— дигән. Кыз җиллеккә бер яулык менгереп элә, яулык җил белән җилфер-җилфер селкенеп тора икән ди.

Аю капчыкны күтәреп бераз бара да:

— Арпадан да үттем,
Көрпәдән дә үттем,
Инде ачып караем, му-му,—

дип әйткән ди.

Капчыктагы кыз моның сүзләрен ишетеп:

— Күрекле күзем күрәләй,— дигән.

Ак аю җиллеккә караса, яулык селкенеп тора икән. Әй, карап тора икән дип, капчыкны күтәреп тагын алга таба киткән ди.

---

* Җ и л л е к — чорма тәрәзәсе.

Бераз баргач, яңадан посылканы куеп:

— Арпадан да үттем,
Көрпәдән дә үттем,
Инде ачып караем, му-му,—

дип әйткән.

Капчыктагы кыз моны ишетеп:

— Күрекле күзем күрәләй,— дигән.

И, һаман күреп тора икән әле дип, тагын посылкасын күтәреп киткән ди. Аю әбиләр өенә барып җиткә дә ишекне шакылдата. Әби:

— Кем бар?— ди.

— Менә сезгә посылка китердем,— дигән ак аю.

Әби ишекне ачып, китер дип, посылканы тартып алган да ишекне бикләп куйган ди. Посылканы ачып караса, өстендә ләвәшләр, бәлешләр, аста иң кече кызы ди.

— И, кызым кайткан, кызым кайткан!— дип куанган ди энисе.

Берничә көннәр үткәч, олы кыз тагын ак аюга әйткән:

— Мин эниләргә посылка җибәрер идем,— дип.

— Ярар,— дигән ак аю,— хәзерләп куй, мин үзем илтеп килермен,— дигән. Кыз тагын капчык төбенә уртанчы сеңлесен утыртып, өстенә ләвәшләр, бәлешләр салган да ди, капчык авызын бәйләп, хәзерләп куйган ди. Ак аю кайтып ашап-эчкән дә посылканы күтәреп чыгып киткән ди. Кыз әйткән:

— Ачып карама, мин җиллектән карап торырмын,— дигән. Бераз баргач, аю посылканы куя да:

— Арпадан да үттем,
Көрпәдән дә үттем,
Инде ачып караем, му-му,—

дигән.

Капчык төбендәге кыз әйткән:

— Күрекле күзем күрәләй,— дип. Шуннан соң, бу тагын посылканы күтәреп киткән ди. Бераз гына бара да посылканы куеп:

— Арпадан да үттем,
Көрпәдән дә үттем,
Инде ачып караем, му-му,—

ди. Җиллеккә күтәрелеп караса, яулык селкенеп тора икән. Капчыктагы кыз:

— Күрекле күзем күрәләй,— дигән.

— И, һаман күрә икән әле,— дип, посылканы күтәреп, алып киткән ди. Барып җитә дә әбиләр өенә, ишекләрен шакылдата.

— Кем бар? — дип әби чыга.

— Мин сезгә посылка китердем,— ди ак аю.

Әби, китер дигән дә посылканы тартып алып, ишекне бикләп кереп тә киткән ди. Посылканы ачып караса, өстендә бәлешләр, аста икенче кызы икән ди. Тагын шатланышып күрешәләр болар.

Шулай итеп торганда олы кыз тагын әйтә аюга:

— Мин әниләргә посылка хәзерләп җибәрер идем,— ди.

— Ярар,— ди ак аю,— хәзерләп куярсың, мин илтеп килермен,— ди.

— Мин посылканы хәзерләп куярмын, ди, үзем өйдә булмам. Син үзең алып барырсың. Ачып карама, мин җиллектән карап торырмын,— ди.

Кыз капчык төбенә үзе утыра да, өстенә бәлешләр, ләвәшләр салып, капчык авызын бәйләп куя. Ак аю кайта да ашап-эчеп посылканы күтәреп чыгып китә, ди. Бераз баргач, посылканы куеп:

— Арпадан да үттем,
Көрпәдән дә үттем,
Инде ачып караем, му-му,—

ди. Үзе җиллеккә караган икән, яулык селкенеп тора, ди. Капчыктагы кыз:

— Күрекле күзем күрәләй,— дигән.

— И, һаман карап тора икән,— дип, посылканы күтәреп, тагын китеп барган. Бара-бара да тагын посылканы куеп:

— Арпадан да үттем,
Көрпәдән дә үттем,
Инде ачып караем, му-му,—

дигән. Кыз:

— Күрекле күзем күрәләй,— дигән. Тагын посылканы күтәреп киткән дә әбиләргә барып җиткән. Ишекләрен шакылдаткан икән:

— Кем бар? — дигән әби.

— Посылка китердем сезгә,— дигән аю.

Әби тиз генә ишекне ачып посылканы алган да ишекне бикләп кереп киткән ди. Өйгә кергәч, посылканы ачып караса, ни күрсен, өченче кызы да кайткан. Күрешеп, шатланышып бергәләп тора башлаганнар ди болар.

Ак аю өйгә кайтса, өч кызның берсе дә калмаган. Тукта, мин аларны барып алып кайтыйм әле дип, яңадан чыгып киткән ди.

Кызлар аюның киләсен белеп тирән итеп чокыр казыганнар ди. Өстен аннан-моннан гына каплап, эченә утын тутырып, ут төртеп куйганнар ди. Ак аю килә икән боларга, чокырга төшкән дә киткән ди. Әй аю акыра икән, әй акыра икән: «Чокырдан чыгарсагыз, бер дә тимәс идем!» — дип. Аюны чыгаручы булмаган, шунда янып үлгән ди.

Кызлар әле дә булса әниләре белән бергә-бергә матур итеп яшиләр ди.

АЙ БЕЛӘН КОЯШ

Ай белән кояш элек заманда гел бер җирдә генә тормакчы булганнар. Шуннан соң, бөтен кошларны җыеп, шул турыда җыелыш ясаганнар. Бөтен кошлар, боларның бер җирдә торуларына риза булып, шуңар кул куйганнар. Болар арасында бары бер генә кош кул куймыйча кала. Ул була ярканат. Бүтән кошлар ярканаттан сорыйлар:

— Бөтен кошлар кул куйганда, нилектән син генә кул куймадың? — диләр.

— Кулны мин, — ди ярканат, — шул сәбәпле куймадым, ди: кояш белән ай бер җирдә генә торсалар, җил бер генә яктан исәр, агачлар кәкре булып үсәр, игеннәр дә кояш төшкән җирдә генә үсәр, кояш төшмәгән җирдә үсмәс, — ди.

Шуннан соң бүтән кошлар әйтәләр:

— Дөрес әйтә шул, кояш төшмәгән җирдә иген үсми инде ул, — диләр.

Ай белән кояшка икесенә дә, бер җирдә тормаска, әйләнеп йөрергә, дип карар чыгаралар.

Шуннан соң кояш әйтә ярканатка:

— Мин сине үземнең яктылыгымда йөртмәм, — ди.

Шунлыктан ярканат кон яктысына чыгып йөри алмый икән.

Аңа ай сүз әйтмәгән, шуңа күрә ул ай яктысында бик әйбәт йөри, ди.

Ай белән кояшның болай әйләнеп йөрүен бөтен кош-кортлар, бөтен халыклар бик дөрес дип кабул иткәннәр ди. Шуннан соң игеннәр дә яхшы була башлаган ди

Гөлчәчәк. 69 биткә.

Кәкре каенны терәткән. 81 биткә.

ШҮРӘЛЕ

Әүвәле берәү урманда утын кисә икән, аның янына бер шүрәле килеп чыккан ди. Шүрәле аңа:

— Син ни атлы? — дигән. Ул кеше:

— Мин Былтыр атлы,— дигән. Шүрәле кешегә:

— Әйдә, кети-кети уйныйк әле,— дигән.

— Ярар, элгәре менә бу тумранны ярыйк әле, аннары уйнарбыз,— дигән кеше.

Кеше тумранга балта белән чапкан икән, тумран азрак ярылган. Шуннан соң бу кеше шүрәлегә әйткән:

— Мин икенче чапканчы, син шунда бармагыңны кыстырып торсана,— дигән. Шүрәле бармагын ярыкка куйган икән, кеше балтасын алгач, ул шунда кысылган да калган. Кеше балтасын алган да качкан. Шүрәле шыр-шыр кычкыра башлаган ди.

— Бармагымны Былтыр кысты, Былтыр кысты!— дип.

Менә аның янына бүтән шүрәлеләр җыелган, аннан:

— Кем кысты? — дип сорыйлар икән. Ул:

— Былтыр кысты,— дип әйткән ди. Алар аңа әйткәннәр ди:

— Быел кысса, табар идек, былтыр кыскач, каян табасың,— дигәннәр ди.

— Соң син былтырдан бирле ник кычкырмый тордың,— дигәннәр, ди. Шүрәле аларга авыртуыннан юньләп әйтә дә алмаган ди.

Ул шүрәле, бармагы кысылган көе тумранын аркасына күтәреп, әле һаман да шулай кычкырып йөри ди.

ХӘЙЛӘГӘ КАРШЫ ХӘЙЛӘ

Беркөнне төлке торнаны кунакка чакырган. Табага бераз гына сыек кесәл салып кунагының алдына куйган. Торна томшыгы белән «тук», «тук» итә, имеш. Кесәлне ничаклы чукыса да, томшыгына бернәрсә дә эләкми, имеш.

Әмма төлке:

— Ашасана, сылу кунагым,— ди-ди, кесәлнең барысын да үзе ялап бетергән, имеш, кунагын ач калдырган, имеш.

Торна төлкенең бу хәйләсен эченә салып, беркөн төлкене үзе дә кунакка чакырган. Тар авызлы тирән чүлмәкнең төбенә бераз борчак салып төлкенең алдына куйган.

Торна төлкегә әйтә икән:

— Ашасана, кунагым, син мине фәләнчә вакытта кесәл белән сыйлаган идең, ник бер дә ашамыйсың!— ди икән.

Төлке бик ашамакчы була икән дә, чүлмәккә авызы сыймый ди. Торна шулай, борчакны үзе генә чукып бетереп, төлкене ач калдырган ди.

КӘҖӘ БЕЛӘН САРЫК

Бервакыт бер кеше кәҗә белән сарык алган. Кыш көне моның хайваннары яши торган урыны бик салкын булган. Шуңа күрә кәҗә сарыкка аркасын терәп ята да икән, бик әйбәт җылынып йоклый икән. Шунда кәҗә сарыкка әйтә ди:

— Сарык агай, кил, без синең белән дус булыйк. Мин сине беркайчан сөзмәм дә, аерым йөртмәм дә. Шулай дус кына җәен дә, кышын да яшәрбез. Көтүдә дә бергә-бергә йөрербез,— ди.

Сарык та моңа бик риза була. Бу ике дус кыш көнен шулай бик тату гына үткәрәләр.

Кыш үтә, яз килеп җитә. Хуҗалары боларны көтүгә җибәрә. Җәйнең матур, җылы көннәре дә килеп җитә. Шул вакыт кәҗә сарык белән дус булганын оныта.

Көтүдә кәҗәнең тигез җирдә генә йөрмәвен һәркем белә. Шулай беркөн сарык елга читендә үлән ашый икән. Моның өстенә елга ярыннан туфраклар коела башлый. Шунда сарык башын күтәрә дә:

— Кем анда яр башыннан минем өскә туфраклар коя?— ди.

Тегеннән яр башыннан:

— Мин, кәҗә морзаң,— дип кенә җавап бирә кәҗә.

Йортка кич кунарга кайткач та, кәҗә йорт уртасына ята да янына сарык килә башласа:

— Минем яныма килмә, синнән ис килә,— ди, сарыкны якын да җибәрми.

Җылы, матур көннәрнең үткәнен кәҗә сизми дә кала. Суык кыш та килеп җитә. Шунда инде кәҗә оятыннан сарык янына җылынырга килми, абзарның караңгы почмагына кысыла да салкыннан дерелдәп ята.

Сарык моның тавышын ишетә дә:

— Кем анда караңгы почмакта дерелди? — дип сорый.

— Кәҗә мескенең,— дип кенә җавап бирә кәҗә.

Сарык моңа:

— Яныма яткызыр идем дә, минем яннан ис килә шул,— ди дә, йортка чыгып, ап-ак кар өстенә ята.

МӘЧЕ, ЮЛБАРЫС ҺӘМ КЕШЕ

Беркөнне мәче белән юлбарыс очрашалар. Юлбарыс мәчедән сорый:

— И энем, ни булды сиңа, ник болай бәләкәй калдың син? —ди.

Мәче әйтә:

— И абый-абыкай, минем хуҗам шундый усал, шундый көчле,— ди.— Мине ул шулай бәләкәй калдырды,— ди.

Юлбарыс әйтә:

— Чыннан да шулай көчлеменн ул? — ди.— Әллә миннән дә көчлерәкме? —ди.

— Көчле, синнән дә көчлерәк,— ди мәче.

— Бар алайса, чакыр тизрәк, көчебезне сынашабыз без аның белән,— ди юлбарыс.

Мәче кешене чакырып килә. Кеше килгәч, юлбарыс сорый:

— Синме моның хуҗасы? —ди.

— Әйе, мин, — ди кеше.

— Сине бик көчле диләр, әйдә сынашабыз, кем көчлерәк икән,— ди юлбарыс.

Кеше әйтә:

— Бик сынашыр идем дә, көчемне өйдә калдырганмын шул,— ди.

— Бар, тизрәк алып кил,— ди юлбарыс.

— Барып алып килер идем дә, син качарсың дип куркамын,— ди кеше.

— Ник качарга? Юк, юк, качасым юк,— ди юлбарыс.

— Мин сиңа ышанмыйм шул,— ди кеше. — Кая, аяк-кулларыңны бәйләп калдырыйм алайса,— ди.

— Бәйләсәң бәйләрсең,— ди теге.

Кеше кесәсеннән бау ала да бик әйбәтләп кенә юлбарысның аякларын бәйләп ташлый. Шуннан якындагы урманга кереп бик шәп күсәк алып чыга. Күсәк алып чыга да юлбарыска бирепме бирә: кай төшең кычыта! Кыйный торгач, юлбарысның җаны кыл өстендә генә кала. Шунда ул мәчене күрә дә әйтә:

— Кара әле, энекәш, хуҗаңнан сора әле: мине дә синең кебек калганчы кыйнармы ул, әллә үтерерме? — ди.

— Белмим шул,— ди мәче.

Кеше, шулай итеп, мактанчык юлбарысны кыйнап үтерә.

БАКА, ТЫЧКАН, ЧАБАТА

Борын-борын заманда булган бер семья. Беркенне атасы малаен чакыра да моңа унбиш тиен акча бирә.

— Бар кибеткә, алып кайт миңа шырпы белән тәмәке,— ди.

Китә малай кибеткә. Юлда барганда моңа туры килә бер тычкан.

— Әй, малай, бир миңа биш тиен акча,— ди.

— Каян алыйм? —ди малай.

— Бир, зинһар, бераэр кирәгеңә ярармын,— ди.

Малай уйлый да бирә моңа акчаны. Бераз китә. Моның каршысына сикерә-сикерә бака килә.

— Әй, малай, бир миңа биш тиен акча, бер зур кирәгеңә ярармын,— ди.

Малай уйлый-уйлый да тагы бирә. Очрый моңа чабата. Бусы да биш тиен акча сорый. Малай, әтигә югалттым дип әйтермен дип, чабатага да биш тиен акчасын бирә. Бераз киткәч, борылып караса, өчесе бергә — тычкан да, бака да, чабата да моның артыннан киләләр, әйтәләр моңа:

— Син бик әйбәт малай икәнсең, сине юмартлыгың өчен буш итмибез,— диләр.— Бер патша бар, аның бик чибәр кызы бар. Кем дә кем аның кызын көлдерә алса, кызны шуңа бирә, диләр. Без аны сиңа алып бирәбез,— диләр.

Шулай дип, тычкан белән бака җигеләләр чабатага. Малайны утырталар да алып китәләр патша

сараена. Малай кулында чыбыркы. И чаптыралар болар, и чаптыралар.

— Юлдан китегез!— дип, малай кычкыруын гына белә.

Барып җитәләр болар патша сараена. Патша сараеның болдырында патша кызы белән патша үзе басып тора икән. Карыйлар болар. Патша кызы чабатага җигелгән тычкан белән бакага карый да чыдый алмый көләргә тотына. Эче катып көлә бу хәзер. Патша әйтә:

— Эһе, көлдең, хәзер үзеңне шул егеткә бирәбез,— ди.

Патша шулай дигәч, кыз да риза инде. Егетне алып керәләр патша сараена. Кияү булды бит хәзер. Ашыйлар, эчәләр. Ул арада кич тә була. Кыз бу егетне бик ярата башлый. Тик моның яратуын вәзир малае ошатмый. Вәзир малае кызны үзенә алмакчы булган икән. Әлеге егетне үтермәкче булып йөри. Беренче кичне теге малайны кыз белән үзләрен генә калдырмыйлар. Йокларга ята бу патша белән бер бүлмәдә. Шунда вәзир малае да керә. Йоклыйлар болар. Тычкан, бака, чабата сөйләшәләр: «Бу вәзир малае безнең егетне харап итмәкче була бит, әйдә без аның үзен кызык итик,— диләр.— Әйдә, урлап борчак китерик»,— диләр.

Китәләр борчак урларга. Тычкан берәүнең келәтенә кереп борчак урлап чыга, бака аны чабатага сала да кайтып та китәләр. Кайтып туп-туры патша бүлмәсенә керәләр. Бака борчакны вәзир малаеның борыны эченә сала, тычкан борын тишегенә койрыгын тыгып кытыклый башлый. Вәзир малае шул чак бик яман итеп төчкереп тә җибәрә, борчак очып барып патшаның маңгаена да тия. Патша куркып сикереп тора да:

— Кем эше бу? — дип кычкыра.

Вәзир малае, коты алынып:

— Мин идем, падишаһ хәзрәтләре, төчкергән идем,— ди.

— Син әле шулай мине мыскыл итәсеңме? — ди патша. Ялчыны чакырта да: — Менә бу юньсезне төрмәгә ябып куй,— ди.

Шулай итеп, вәзир малаен төрмәгә ябып куялар, чабатага утырып килгән егеткә зыян итүче булмый.

Икенче көнне туй ясыйлар. Патшаның туе була кырык көн, кырык төн. Туйны бик шәп итеп уздыралар да, малай кызны алып китәргә тиеш була инде. Җигәләр бик шәп атлар, арбаларга төйиләр маллар, байлык.

Тычкан, бака, чабата әйтәләр егеткә:

— Патша арбасына утырма, үземнеке бар дип әйт,— диләр.

— Безнең өй дә кыек бит әле, кыз белән нишләрбез икән? Кунаклар да күп булыр,— ди бу.

— Анысы синең эшең түгел, кайгырма,— диләр.

Малайны патша арбасына утыртмакчы булалар. Күпме әйтсәләр дә, утырмый. Кыз белән икәвесе чабатага утыралар. Кучер итеп алалар бер чикерткәне. Болар утыруга, бака белән тычкан бик яхшы айгыр булалар, чабаталары тарантаска әйләнә, ә чикерткә чибәр генә егет була. Патшаның да, аның якыннарының да исе китә бу эшкә. Туйны озата баралар. Малай кая барырга да, нишләргә дә белми, хур булырмын инде, ди. Кайта торгач, кайтып җитәләр. Атлар туктый зур бер сарай алдында. Капка төбендә егетне әтисе белән әнисе көтеп тора икән. Шуннан болар тагы кырык көн, кырык төн туй итәләр.

Туйларында мин дә булдым. Куйдылар бер иләк катык. Карга кычкырды: «Карр!» дип, миңа ишетелде: «Пожар!» дип, урамга чыктым янабыз дип. Анда чыксам, берни юк.

АЮ, ТӨЛКЕ, БАБАЙ

Борын заманда бер карт яшәгән ди. Көннәрдән беркөнне шалкан чәчеп торганда карт янына аю килеп чыккан ди.

— Нишлисең? — ди аю.

— Шалкан чәчәм,— ди карт.

— Әйдә уртагына чәчик,— ди.

— Әйдә,— ди карт.

Бергәләп шалкан чәчәргә тотыналар болар. Карт агач төбен казып тора, аю каерып алып тора. Шулай итеп тиз генә җирне әрчеп, шалканны чәчеп тә бетерәләр ди.

Шалкан җитешкәч, аюга әйтә карт:

— Ничек бүләбез? Син төбен аласыңмы, сабагын аласыңмы?—ди.

— Мин сабагын алам, — ди аю.

Ярар, аюга шалканның яфракларын кисеп бирә дә бу, үзе унбиш ат йөгенә төяп шалканны алып кайтып китә.

Бер заманны шалканны төяп базарга китеп барганда аю очрый моңа.

— Кая барасың? — ди.

— Базарга шалкан сатарга барам,— ди дә аюга ике шалкан ыргыта. Аю шалканны ашап карагач әйтә:

— Ай-һай, бабай, мине алдагансың бит син, ди. Икенче уртагына эшли калсам, төбен алам инде,—ди.

Икенче ел килеп җитә. Карт кырга барган икән, өлеге аю тагын моның янына килеп җитә.

— Бабай, нишлисең? — ди аю.

— Бодай чәчәм,— ди.

— Әйдә уртакка эшлик,— ди аю.

— Әйдә,— ди карт.

Шуннан тотыналар болар бодай чәчәргә. Карт чәчеп тора, аю койрыгы белән себереп кенә тора.

Бодай өлгерә, урып алыр вакыт та килеп җитә. Аю җәй буена бодай кырын саклап яткан була. Карт бөтен семьясы белән урак урырга китә. Шул вакытны аю да моның янына килә:

— Син нишлисең, аю дус, астын аласыңмы, сабагын аласыңмы? — ди карт.

— Мин быел астын алам инде,— ди аю.

— Ярый, —ди карт,— син астын алсаң, мин сабагын алырмын,— ди.

Карт бодайны урып, сугып, тегермәндә он ясап, күмәчен дә ашап карый.

Бервакытны он төяп базарга барганда аю очрый моңа. Карт: «Мә сиңа бергә иккән игеннең күмәче»,— дип, ярты күмәч тоттырып китә. Күмәчне ашап карагач, аюның тагын да ачуы килә. Ачудан, алдаган өчен мин хәзер бу картны үтерәм,— ди аю.

Аюның бу сүзен төлке ишетә дә картка килеп әйтә: аю шулай-шулай дип әйтә дип. Аннан төлке әйтә:

— Бу хәбәрне белдергән өчен син миңа нәрсә бирәсең? — ди.

— Тавык бирермен,— ди карт.— Но, ди, иң элек безгә аюның үзен үтерергә кирәк, шуның хәйләсен табыйк,— ди. Төлке:

— Мин аюның кайда ятканын белеп килим, ди, аннан соң ничек үтерү турында уйлашырбыз,— ди.

Берничә вакыттан соң төлке аюның оясын белеп, картка килеп әйтә.

Карт аучыларны җыя да аюның оясына алып ба-

ра. Шулай итеп алар аюны атып алалар. Шуннан соң озак та үтми, төлке яңадан карт янына килеп җитә.

— Ну, бабай, ди, мин сиңа аюны үтерергә ярдәм иттем, моның өчен син миңа нәрсә бирәсең?— ди.

— Тавык,— ди карт.

— Соң ул тавыкны каян алабыз,— ди.

— Әйдә, минем белән арбага утыр да безгә бар, тавыкны биреп җибәрермен,— ди.

— Юк,— ди төлке,— авылга кайтсам, мине этләр күреп харап итәрләр,— ди.

— Мин этләргә харап итәргә бирмәм, арбага чыбыклар салып, чыбыклар астына яшереп алып кайтырмын,— ди. Болай дигәч, төлке дә риза була. Шуннан соң карт төлкене арбадагы чыбыклар астына яшереп, өйгә алып кайтып китә. Ишегалдына килеп керүгә атны туктатып, чылбырдагы этне ычкындырып, арбаны аударып җибәрүгә чыбык астыннан төлке килеп чыга. Эт төлкене күреп тотына куарга. Әй куа, өй куа, куа торгач төлке койма аркылы сикереп урманга кача. Урманга барып җитеп, үзенең куышына кереп яткач, алгы аякларыннан сорый икән: «Эттән качканда син нишләдең?» — дип. Алгы аягы әйтә икән: «Мин колактан уздырыйм дип сикердем»,— ди икән. Арт аягыннан сорый икән: «Син нишләдең?» — дип. «Мин алгы аяклардан уздырыйм дип сикердем»,— ди икән. Койрыгыннан сорый: «Син нишләдең?» — дип. Койрык: «Мин этләр тотсын дип селкендем»,— ди икән. Ул арада куып килгән эт төлке артыннан килеп җитеп койрыкның селкенгәнен күреп, төлкене тотып та ала, шуның белән әкият тә бетә.

ХӘЙЛӘКӘР ТӨЛКЕ

Элек заманда бер төлке юлдан сарык аягы тапкан. Бара-бара бу бер авылга кереп, бер кешедән йокларга фатир сораган. Бу кеше әйткән:

— Безнең өебез бик кечкенә, син сыярлык урын юк,— дигән.

Төлке әйткән:

— Мин үзем кечкенә генә сәкедә ятармын, ә койрыгымны сәке астына куярмын,— дигән.

Фатир иясе:

— Алай булса, ярар, керерсең,— дигән.

Төлке кереп урнашкач, фатир хуҗасына әлеге сарык аягын биреп:

— Бу сарык аягын җыеп куегыз әле, иртәгә алырмын,— дигән. Хуҗа сарык аягын җыеп куйган. Төлке хуҗаның сарык аягын кая куйганын карап торган. Хуҗалар йоклагач, төлке төнлә торып аякны икенче җиргә алып куйган. Иртә торганнар. Төлке хуҗадан теге аякны сорый икән. Хуҗа куйган җиреннән алып бирмәкче булып караса, аяк урынында юк.

— Аяк булмаса, аның урынына бер тавык бирерсең,— ди икән төлке.

Хуҗа төлкегә бер тавык биреп җибәргән. Төлке тавыкны алып чыгып киткән. Икенче авылга барып җитеп, төлке тагын бер кешедән фатир сорап кергән, хуҗага әйткән төлке:

— Зинһар, шушы тавыкны җыеп куйсагыз ла,— дигән.

Хуҗа тавыкны җыеп куйган. Төнлә торып төлке тавыкны икенче урынга яшергән. Иртә торганнар. Төлке хуҗадан тавыгын сораган. Хуҗа караса, куйган җирендә тавык юк. Төлке әйткән:

— Булмаса булмас, тавык урынына миңа бер каз бирсәң дә ярар,— дигән.

Хуҗа тавык урынына бер каз биреп җибәргән. Төлке казны да, тавыкны да алып чыгып киткән. Өченче төнне төлке өченче авылга барып бер кешегә фатирга кергән. Хуҗага казны биреп:

— Җыеп куйсагыз ла,— дигән. Хуҗа җыеп куйган. Төлке төнлә торып бу казны икенче урынга алып куйган. Иртә торганнар. Төлке хуҗадан казны сораган. Каз урынында юк. Төлке әйткән:

— Каз урынына бер үгез бирерсез инде,— дигән.

Хуҗа карап торган да, кеше малын югалткач түләми булмас дип уйлап, төлкегә бер үгез биреп җибәргән. Төлке үзенең сарык аягын, тавыгын, казын һәм үгезен алып чыгып киткән. Кайтып, барын суеп салам астына яшергән. Үгез тиресенә салам тутырып куйган.

Бераз гомер үткәч, моңар аю белән бүре килгән. Төлке әйткән аю белән бүрегә:

— Барыгыз, бар чана белән бер камыт урлагыз,— дигән.

Аю белән бүре каядыр барып чана белән камыт урлап китергәннәр. Төлке салам тутырган үгезне җиккән. Төлке, аю, бүре чанага менеп утырганнар да, үгезне куа башлаганнар. Үгез бер дә кыймылдамаган. Төлке, аю белән бүрегә ачуланып, чанадан төшеп киткән дә барган. Аю белән бүре:

— Синең безгә китүең генә кирәк иде, китсәң кит, кадал, үгез безгә калды,— дип, үгезгә ташланганнар. Тиресен ертып-ертып карасалар, ит урынына салам килеп чыккан. Шулай итеп, хәйләкәр төлке өч кешене алдап, аю белән бүрене алдап качкан.

БАТЫР ӘТӘЧ

Борын-борын заманнарда бер авылда яшәгән икән ди бер бабай. Бу бабайның бер кызы, бер кәҗәсеннән башка бернәрсәсе дә булмаган ди. Бик ярлы булган бу.

Көннәрдән беркөнне бабай үзенең кызын болынга кәҗәсен көтәргә җибәргән. Кыз кәҗәне көн буена болында кәтеп йөргән, кичкырын гына алып кайтып ишегалдына кертеп япкан ди. Бабай кәҗә янына чыгып:

— Я, кәҗәкәем, көне буена болында булып, ни ашадың, ни эчтең? — дип сорый икән. Кәҗә моңа:

— Бер яфрак ашадым да, бер кашык чамасы су эчтем,— дип җавап биргән ди.

Картның моңа бик каты ачуы килеп: «Бер кәҗәне дә туйганчы ашатып кайта алмагансың»,— дип, кызын бик каты ачуланган ди.

Икенче көнне карт болынга кәҗәне үзе алып киткән. Кәҗә көне буена болын буенда йөреп туйганчы ашаган, ял иткәләп алган да тагын торып ашарга тотынган ди. Бабай моны күреп бик шатланган. «Ярый, үзем алып килгәч, бик рәхәтләнеп, туйганчы ашады әле бу», — дип уйлый икән бабай. Шулай дип уйлаган да теге бабай, кич булганны да көтеп тормаган, кәҗәсен калдырып өенә кайтып киткән ди.

Кич булып караңгы төшүгә, кәҗә дә болыннан кайтып кергән ди. Бабай сорый инде бу кәҗәдән:

Хәйләкәр әтәч. 121 биткә.

Куркак юлдаш. 138 биткә.

— Нихәл, кәҗәкәем, көне буена болында йөрдең, ни ашадың, ни эчтең? — ди. Кәҗә аңа:

— Бер яфрак ашадым, бер кашык чамасы су эчтем,— дип җавап биргән ди.

Картның моңа бик каты ачуы килгән. Гаеп кызда түгел, бу кәҗә үзе бик ялганчы хайван икән ди. Шуннан соң бабай: «Бу ялганчы кәҗәдән барыбер рәхәт тә күрмәссең», дип уйлый да кәҗәсен суеп ашарга була. Икенче көнне бабай кәҗәне ике мөгезеннән тотып алып, аякларын бәйләп сала. Бабай пычак алырга дип өенә кереп киткән арада, кәҗә аякларын ычкындыра да чыгып сыза.

Китә бу. Бара-бара, барып җитә бу кечкенә генә бер өйгә. Бу куян йорты икән. Барып керә. Өй эчендә беркем дә юк. Бу барып кергәндә куянның чыгып киткән вакыты булган икән ди.

Кояш баеп караңгы төшә башлауга, куян үзенең өенә кайтып керә. Кайтып керсә, ни күзе белән күрсен, теге кәҗә түр башына менеп, мөгезләрен тырпайтып, сакалын селкеп утыра икән ди. Куян моны күреп бик каты курыккан да, алдына-артына карамастан, урманга таба торып чапкан ди.

Урманга барып керүгә, бу куянга очраган ди бер бүре. Бүрене күрү белән куян елый башлаган. Моны күреп бүре:

— Нигә елыйсың, сиңа ни булды? — дип сорый икән.

Куян моңа:

— Нигә еламаска, көне буена урманда йөреп, өемә әйләнеп кайтсам, түр башында бик куркыныч бер нәрсә утыра, күрү белән йөрәгем ярыла язды,— ди. Моны ишетү белән бүре батырланып:

— Әйдә киттек, без аны хәзер куып чыгарырбыз,— ди.

Китәләр. Куян өенә барып җитү белән бүре үзе дә курка-курка гына ишекне ача. Караңгы өйдә зур

мөгезле, озын сакаллы кәҗә башын күрү белән бүренең дә котлары чыга. Бүре тиз генә өй ишеген яба да урманга карап сыза. Куян аның артыннан китә. Куянның урманга барып керүе була, моның каршысына лап-лап басып килә икән ди бер аю. Аюны күрүгә куян тагын кычкырып елап җибәрә:

— Коткарыгыз, харап булдым, өемә куркыныч бер нәрсә кергән,— ди.

Аю бик батырланып:

— Ташла әле, юкка-барга елап күз яшеңне әрәм итмә, без аны хәзер куып чыгарырбыз,— ди икән.

Китәләр. Караңгы төшүгә куян өенә барып җитәләр. Аю бик батырланып өй ишеген ачып җибәрүгә сәке өстенә менеп утырган зур мөгезле, озын сакаллы кәҗәне күрү белән бик каты куркуга төшә. Аю да куркуыннан алдына-артына карамый урманга чаба. Куян — аның артыннан.

Куянның урманга барып керүе була, очрый инде моңа бер төлке. Төлке дә бик батырланып бара. Караңгы бүлмәдә кукраеп утырган кәҗәне күрү белән төлкенең дә котлары чыга. Кача бу.

Куян нишләсен, йорт-җирен калдырып чыгып китә урманга.

Таң атып яктыра башлауга, барып җитә бу бер урман каравылчысының йортына. Бу йортның койма башында утыра икән ди бер әтәч. Әтәчне күрү белән куян гадәтенчә тагын да кычкырыбрак елап җибәрә ди.

— Нигә елыйсың соң син, куянкай? — ди әтәч, моннан сорый инде.

— Нигә еламаска,— ди куян,— минем өемә бер куркыныч нәрсә кереп утырды,— аны үзем дә, бүре белән аю да, хәтта төлке дә куып чыгара алмады,— ди.

— Юкка елама, куянкай, әйдә киттек, менә мин үзем сиңа ярдәм итәрмен,— ди әтәч.

Китәләр. Куян өенә барып җитүгә әтәч әйтә инде куянга:

— Миңа өй ишеген ачуы гына кыен булыр, син ишекне ачып мине кертеп җибәрерсең, калганын үзем белермен,— ди.

Өй янына барып җитү белән куянның ишекне ачып җибәрүе була, әтәчнең өй эченә кереп кәҗә мөгезләре арасына барып кунуы була. Кәҗә башына куна да бу чукый башлый кәҗәнең күзләрен. Кәҗә бернәрсә эшли алмый. Чыгып кача куян өеннән. Әтәч аны бик ераккa хәтле куып бара. Шулай итеп, батыр әтәч куянны ялганчы кәҗәдән коткарган ди.

АЮ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

Беркөнне аю төлкенең балык ашаганын күргән дә бик кызыккан.

— И төлке дус, балык тотарга мине дә өйрәтсәнә! — дигән.

Төлке аюга әйткән:

— Ярар, аю дус, өйрәтермен, — дигән. Аюның койрыгына бер кәрзин бәйләгән дә аны бәкегә төшергән. Аюга әйткән:

— Шунда кузгалмый гына утыр, кузгалсаң, кәрзингә балык кермәс,— дигән. Шулай дигән дә үзе качкан.

Әй утыра ди аю, өй утыра ди, балыклар качып бетмәсен тагын дип, бер дә селкенеп карамый ди. Шулай төн буе утырган ди. Утыра торгач, койрыгы бәке кырыена ябышып каткан ди.

Иртә белән хатыннар суга килсәләр, бәке өстендә аю утыра.

— Ник монда килеп утырдың? — дип, менә тотынганнар аюны кыйнарга. Аю, бичара, куркуыннан сикереп торган икән, койрыгы шарт итеп өзелгән ди. Аюның койрыгы шул вакытта кыскарып калган ди.

КӘҖӘ БЕЛӘН БҮРЕ

Борын-борын заманда булган ди дәү сакаллы, бик акыллы бер кәҗә. Аның булган ди өч бәтие.

Тагын булган ди бу кәҗәнең бер куышы. Кәҗә өч бәтие белән шул куышта рәхәт-рәхәт торалар икән ди. Көндезләрен кәҗә яшел болыннарда, киң тугайларда ашап-эчеп йөри икән дә, кич булгач, җырлый-җырлый балалары янына кайта икән:

Таудан тауга йөримен,
Тау җимеше җыямын.
Кырдан кырга йөримен,
Кыр җимеше җыямын.
Бер имиемә сөт җыям,
Бер имиемә май җыям.

— Ачыгыз, балакайларым! — дип, ишек төбенә килә икән ди. Кәҗә бәтиләре өйнең ишеген ачып җибәрәләр икән ди. Кәҗә өенә керә дә, бәтиләрен имезеп, тамакларын туйдыра икән ди. Шулай итеп, көн артыннан көн үтә, таң ата да кич була, кич артыннан төн җитә. Иртә торгач, кәҗә тагын яшел болыннарга, киң тугайларга чыгып китә ди, кичен тагын шулай җырлый-җырлый кайта ди. Боларга яңгыр үтми, җил тими, тамаклары тук, өсләре бөтен иде ди.

Бервакытны соры бүре боларны сагалап йөри башлаган. Кәҗәнең кичен шулай җырлап кайтканын ишеткән дә аның җырларын отып калган ди.

Менә беркөнне, кәҗә өеннән чыгып киткәч, бүре, кәҗә булып җырлый-җырлый, ишек төбенә килгән:

Таудан тауга йөримен,
Тау җимеше җыямын.
Кырдан кырга йөримен,
Кыр җимеше җыямын.
Бер имиемә сөт җыям,
Бер имиемә май җыям.

— Ачыгыз, балакайларым! — дип кычкырган ди.

Кәҗә бәтиләре ишекне ачмаганнар ди.

— Син безнең әни түгел, синең тавышың бик ямьсез,— дип әйткәннәр ди.— Аннары безнең әни бу вакытта кайтмый. Ул кич булгач кына кайта,— дип әйткәннәр ди.

Бүренең бик ачуы килгән ди, ул телен таптатып, тавышын нечкәртер өчен туп-туры тимерчегә киткән ди.

Су буенда алачыкта аю тимер суга икән.

— Исәнмесез, аю дус! — дип әйткән ди бүре.

— Бик һәйбәт әле, бүре дус! — дип әйткән ди аю.

Бүре исәнлек-саулык сорашканнан соң, аюга әйткән ди:

— Аю дус, минем телемне юкартып бирсәнә,— дип әйткән ди. Аю бүренең телен юкартырга риза булган ди.

— Без барыбер шул эш белән кәсепләнәбез,— дип әйткән ди,— эш хакы бер сарык булыр, ул булмаса, ике бәрән китерсәң дә ярар,— дип әйткән ди.

Бүре сарык китермәкче булган. Шуннан соң болар эшкә тотынганнар. Бүре телен чыгарган да сандалга китереп салган ди; аю, җиң сызганып, аны чүкечләргә тотынган ди. Бүре башта чинап җибәргән, аннары, чыдый алмыйча, улап җибәргән. Шулай да түзгән ди. Шуннан соң аның теле юп-юка булып калган ди.

Хәзер бүре, нәкъ кәҗә шикелле нечкә тавыш белән җырлый-җырлый, ишек төбенә киткән ди.

Таудан тауга йөримен,
Тау җимеше җыямын.
Кырдан кырга йөримен,
Кыр җимеше җыямын.
Бер имиемә сөт җыям,
Бер имиемә май җыям.

Кәҗә бәтиләре, бүрене әниләре дип белеп, ишекне ачып җибәргәннәр иде ди, ач бүре аларны берәм-берәм йоткан да урманга кереп киткән ди.

Кич булгач кәҗә әүвәлгечә җырлый-җырлый өенә кайтса, өйнең ишеге төбенә чаклы ачык калган, бәтиләре юк булган ди.

— Мики-ки-ки, мики-ки-ки, балакайларым, сез кайда?— дип кычкырган ди. Аңа җавап бирүче булмаган ди.

Шуннан соң кәҗә бик кайгырып бүре эзеннән туп-туры урманга чапкан. Бүре урман буенда кояшта корсагын җылытып ята, имеш. Кәҗәнең чабып килүе булган, бүренең корсагын мөгезе белән актарып ташлавы булган; кәҗә бәтиләре өчесе дә бүре корсагыннан чабышып килеп чыкканнар ди. Кәҗә өч бәтиен ияртеп сөенә-сөенә өенә кайтып киткән ди.

Алар тагын элеккечә рәхәт тормыш итә башлаганнар. Шулай да бүре тагын килер дип, бәтиләремне тагын ашап китәр дип, кәҗә гел кайгырып йөри икән ди.

Беркөнне кәҗә өч бәтие белән бер тар гына тирән чокыр казыганнар ди, чокырның өстенә ялганчы гына итеп чыбык-чабык түшәгәннәр дә чокыр кырыена күп итеп салам өйгәннәр ди.

Йөри торгач, бүре бик ачыккан да ди, кәҗә бәтиләрен ашап булмасмы икән дип, тагын юлга чыккан ди. Ярты юлда кәҗәне очраткан да алдашырга тотынган ди.

— Мин сине кунакка дәшергә дип киләдер идем, кәҗә дус,— дип әйткән ди.

Кәҗә аңа әйткән:

— Әйдә, алайса, бүре дус, әлек миңа керең чәй эчеп чыгыйк, анңары сиңа да җитешербез,— дип әйткән ди.

Киләләр, киләләр ди болар. Кәҗә бүрене туп-туры өлеге хәйләле чокырга таба алып килгән ди. Кәҗә үзе чокырны сиздермичә генә сикереп чыккан ди, бүре чокыр төбенә мәтәлеп барып төшкән ди.

Кәҗә балаларына дәшкән ди:

— Мики-ки-ки, мики-ки-ки, балакайларым, шырпы кая? Ут төртегез, янсын бүре, йөзе кара!— дип кычкырган икән ди, кәҗә бәтиләре салам өеменә ут төртеп, аны чокырга ишеп төшергәннәр ди.

Чокыр төбендә чатыр-чотыр яна башлагач, бүре ялынырга тотынган ди:

— Кәҗәкәем, колагым пешә, тартып ал!

Кәҗә аңа өстән кычкырган ди:

— Балаларымны ашаганда бик шәп иде. Кычкыра-кычкыра ян!

Бераздан бүре тагын кычкырып җибәргән ди:

— Кәҗәкәем, башым пешә, тартып ал!

Кәҗә аңа өстән тагын кычкырган ди:

— Балаларымны ашаганда бик шәп иде, кычкыра-кычкыра ян!

Бүре шунда янып үлгән ди. Кәҗә өч бәтие белән, җырлый-җырлый, бүрене шул чокырга күмеп куйганнар ди. Аннан соң тагын элеккечә рәхәт-рәхәт гомер итә башлаганнар ди.

ХӘЙЛӘКӘР ӘТӘЧ

Борын-борын заманда бик матур, бик батыр хәйләкәр бер әтәч булган. Әтәч бервакыт урамда йөргәндә алтын балдак таба да муенына кия. Моны бер бай күреп алтын балдагыңны бер атнага миңа биреп тор, мин сиңа тары бирәмен, ди. Әтәч тиз күнә. Байга бер атнага балдакны биреп, тары алып кайтып китә.

Бер атна үткәч, әтәч байдан барып балдакны сорый, ә бай бирмичә куып кайтарып җибәрә. Әтәч ике көн үткәч бай янына тагын бармакчы була. Бара-бара әтәчкә, бер зур аю очрый.

— Әтәч, кая барасың? — ди.

— Мин байга алтын балдагымны сорарга барам,— ди әтәч.

Аю:

— Мин дә барыйм әле,— ди.

— Әйдә кер эчкә,— ди әтәч. Аю әтәчнең авызыннан эчкә керә. Тагын китә бу. Бара-бара бүре очрый моңа. Шулай сөйләшкәннең соңында, бүре дә әтәч эченә керә. Әтәч тагын үз юлына китә. Шуннан әтәчкә төлке очрый. Төлке дә, әтәч белән сөйләшеп, шулай ук әтәчнең эченә кереп, әтәч белән китәләр. Байга барып җиткәч, әтәч капка башына менә дә: «Бай абый, алтын балдакны бир»,— дип, берничә мәртәбә кычкыра.

Бай хезмәтчеләренә әйтеп әтәчне тотарга куша. Шуннан әтәчне тотып, атлар тибеп үтерсен дип, атлар

абзарына ябалар. Әгәч абзарга ябу белән: «Аю, чык эчтән!» — ди. Аю чыгып бөтен атларны кыйнап үтерә дә әтәч эченә яңадан керә. Икенче көнне, казлар талап үтерсен дип, әтәчне казлар абзарына ябалар. Абзарга ябу белән, әтәч: «Төлке, чык эчтән!» — ди. Төлке әтәч эченнән чыгып бөтен казларны үтереп ашап бетерә дә әтәч эченә керә.

Болай да булмагач, өченче көнне әтәчне сарыклар, тәкәләр абзарына ябалар. Ябу белән әтәч тагын: «Бүре, чык эчтән!» — ди. Бүре әтәч эченнән чыгып бөтен сарыкларны буып үтерә дә әтәч эченә керә.

Инде болай булмый икән дип, әтәчне дүртенче көнне коега ташлыйлар. Коега төшү белән әтәч: «Су, кер эчкә!» — ди. Коедагы су әтәч эченә керә дә бетә; әтәч үлми кала.

Бишенче көнне мичкә бик көчле ягып, янып үлсен дип, мичкә аталар. Әтәч мичкә керү белән: «Су, чык эчтән!» — ди. Су әтәч эченнән чыгып мичне сүндерә дә яңадан әтәч эченә керә. Болай да булмагач, шул көнне пешереп ашарга дип әтәчне казанга салалар. Казанга салгач әтәч: «Су, чык эчтән!» — ди. Бөтен кое суы әтәч эченнән чыгып кайный торган казанны суындыра. Су казаннан ташып, учакка кереп, учакны сүндерә. Шуннан соң әтәч эченнән аю, төлке чыгып байны семьясы белән кыйнап ташлыйлар. Балдакны, байның бөтен малын алып, көлешә-көлешә кайтып китәләр ди болар. «Менә, алтын балдакка кызыксаң, шулай була ул»,— ди әтәч.

ӘТӘЧ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

Беркөнне әтәч батыр ирек ачар өчен авылдан читкә чыккан, имеш. Анда бер койма өстенә менеп, арыбире каранып, дөньяның иркенлегеннән, сәхраның хушлыгыннан кәефе килеп, канатларын кагып кычкырып җибәргән, имеш. Ул җирдә бер төлке бар икән. Әтәчнең тавышын ишетеп, моны миңа ходай бирде дип, койма төбенә килгән.

Әтәч моны күреп:

— Сиңа ни кирәк, ни йомышың бар? — дигән.

Төлке әйткән:

— Мин шәһәрдән кайтып киләмен, синең бик хуш авазыңны ишетеп, тавышыңнан ләззәт алыйм дип, синең яныңа кердем, дигән. Шәһәрдә бер яңа хәбәр ишеттем, шуны да сиңа әйтәсем килде,— дигән.

Әтәч:

— Ул нинди хәбәр, сөйләче, ишетим,— дигәч, төлке әйткән:

— Шушы көннәрдә патша хәзрәтләре фәрман кылган: минем йортымда, ягъни кул астымдагы бар халык бер-бере белән дус булсыннар, тату торсыннар, күңелләреннән усаллыкларын чыгарсыннар. Көчле көчсезгә кул сузмасын, арслан дәвәнең муенын өзмәсен, эт төлкенең туныи ертмасын, төлке тавыкны бумасын, тилгән чыпчыкны алмасын, бүре белән куй бер абзарда торсыннар, күгәрчен белән карчыга бер оялда тыныч торсыннар дип боерган, дигән. Шулай булгач,

безнең арабызда да ятлык булмасын, күңелләребездә бер-беребез хакында яманлык булмасын. Әтәч дус, син койма өстеннән төшеп минем яныма кил, ике дус бергә кочаклашып йөрсен, патша фәрманын җиренә җиткергәнне илгә күрсәтик,— дигән, имеш.

Әтәч төлкенең сүзләренә күп колак салмый койманың икенче ягына карап тора, имеш.

Төлке әйткән:

— Әй, әтәч дус, син патша фәрманын исеңә аласың килмиме, минем әйткән сүземә колак салмыйсың, кире якка карап торасың,— дигән.

Әтәч җавап биреп әйткән:

— Тукта әле, авыл ягыннан арык тунлы, зур колаклы, озын койрыклы бер җанвар бу якка таба чабып киләдер, шул нинди хайван икән дип, хәйран булып карап торамын,— дигән.

Төлке бу сүзне ишеткәч, әтәчне ауламак кайгысы калмый, үзенә сыенырга урын эзли башлый.

Әтәч әйтә:

— Ник тынычсызланасың? Тукта әле, ул монда килсен, күрик, ул нинди хайван икән? — дигән.

Төлке әйтә:

— Сүзеңә караганда ул эткә охшыйдыр, аның белән күрешүдә күп хәер юк. Килеп мине күрә калса, тунымны ертмый калмас,— дигән.

Әтәч әйткән:

— Син ни сөйлисең? Патша һичкем беркемгә залим итмәсен дип боерган дигән идең. Алай булгач, этнең ни куәте бар безгә тияргә? — дигән.

Төлке әйткән:

— Анысы дөрес, шулай булса да, аңа күренмәгәнем хәерлерәк. Ихтимал, ул патшаның фәрманын ишетмәгәндер,— дип, бер якка качып киткән, имеш.

Әтәч тә, аның хәйләсенә хәйлә корып, явызлыгыннан котылган, имеш.

АЮ, БҮРЕ, ТӨЛКЕ

Бервакытны аю, бүре, төлке үзара сөйләшеп бер фикергә килгәннәр ди. Без, диләр икән, моннан соң беркемгә дә тимәскә, үз көчебез белән көн күрергә дип сүз куешыйк, дигәннәр. Шулай итеп болар беркемгә дә зарар итмәскә сүз куештылар ди.

Болар бергә чыгып киттеләр. Юлда барганда болар бер дәвәгә юлыктылар ди. Дәвә болардан:

— Кая киттегез, дуслар? — дип сорый икән. Болар:

— Менә, без инде киттек әле, беркемгә дә зарар итмәскә сүз куештык,— диләр. Дәвә әйтә:

— Ярый, алай булгач мине дә алып китсәгезче,— ди.

Шуннан соң болар чыгып китәләр бергәләп юлга. Берничә көннәр баралар. Юлда дәвә үлән ашап тамагын туйдырып бара. Үлән ашау гөнаһ түгел инде. Аю, бүре, төлке барган саен ачыга, барган саен дәвәгә үчегәләр: «Дәвә туенып бара, давай без моны үтерик»,— диләр. Озак та үтми, болар өчәүләп дәвәне буып ыргыталар. Шуннан аю әйтә: «Мин моның эчәк-карынын күлгә илтеп юып кайтыйм, мин кайтканчы сез бернәрсәсенә дә тимәгез»,— ди. Бу китте. Аю китү белән төлке бүрегә: «Әйдә әле, бүре дус, аю кайтканчы без моның бөерен ашап куйыйк, мин аңа үзем җавап бирермен, тик ул кайтып, бөер кайда дип сораса, син миңа әйләнеп кара»,— ди.

Аю әйләнеп кайта. Кайтып тикшереп караса, бөер юк. Бүрегә карап:

— Дәвәнең бөере юк бит, ул кая киткән? — ди. Шулай дигәч, бүре төлкегә әйләнеп карый. Төлке:

— Нигә син миңа карыйсың? Үзең бөерне ашап бетердең дә, хәзер миңа әйләнеп карыйсың, әйттем бит мин сиңа ашама дип,— ди. Шулай диюе була, аю бүрегә ачуланып, бүрене куып чыгып китә. Аю киту белән төлке дәвәнең итен камышлыкка ташып яшереп куя. Аю әйләнеп кайта, үзе арыган-талган була. Аюның кайтуына, төлке дәвә суйган урында елап утыра. Аю:

— Дәвәнең ите кая? — ди. Төлке әйтә:

— Аю абый, дәвәнең итен каракош килеп күтәреп алып китте, үзем дә менә шуны искә төшереп елап утырам,— ди.

Аю бик каты ачуланып, болар белән яшәп булмый дип, үз юлына китә, ә хәйләкәр төлке шул үзе яшереп куйган дәвә итен ашап әле дә булса көн итә икән ди.

ПЕСӘЙ

Бер әбинең бер кызы була. Боларның бер песәйләре була.

Кыз мич алдында борчак куыра, песәй мичкә каршы утыра ди. Табада борчаклар сикерүгә песәй куркып чыгып та китә ди. Бара торгач, моңа чүплек башында бер әтәч очрый ди.

— Песәй дус, кая барасың болай чаба-чаба? — ди әтәч.

— Борчак явы килә, шуннан качып китеп барам,— ди.

— Зинһар, мине дә ияртә күр,— ди әтәч.

— Әйдә, тизрәк киттек,— ди.

Китәләр болар икәү. Бара торгач, очрый боларга бер күркә.

— Песәй дус, кая барасың болай чаба-чаба? — ди.

— Менә, борчак явы килә, шуннан качып китеп барабыз,— ди.

— Мине дә үзегездән калдырмагыз инде,— ди күркә.

— Әйдә, ияр инде алай булгач,— ди.

Өчәү китеп баралар иде, торна очрый боларга.

— Кая барасың, песәй дус, болай ашыга-ашыга?— ди торна.

— Борчак явы килә, шуннан качып китеп барабыз,— ди.

— Мине дә калдырмагыз инде,— ди.

— Әйдә, ияр инде алай булгач,— ди.

Торна белән дүртәү китеп баралар иде, җиталәр бер су буена. Суда бер үрдәк боларның чаба-чаба китеп барганын күреп:

— Песәй дус, кая барасыз болай? — ди.

— Борчак явы килә, шуннан качып китеп барабыз,— ди.

— Мине дә ияртегез инде,— ди.

— Әйдә, ияр инде алай булгач,— дип алып китәләр моны да.

Болар юлдан тезелеп баралар: башта песәй, аның артыннан әтәч, аннан күркә, торна, үрдәк. Күргән бер кеше аптырап карап тора боларга, бу нинди хәл дип.

Бара торгач җиталәр болар бер тауга. Песәй әйтә: «Без килеп җиттек инде, шушында торыйк»,— ди. Сөйләштеләр дә, ярар дип, калырга булдылар болар. Үрдәк суга төшеп китте, күркә белән торна тирәк башына менде, песәй белән әтәч җирдә калдылар. Песәй тычкан тотып ашый, әтәч тырнанып туена. Шулай итеп көн итәләр ди болар.

Бер заманны көннәр суына башлый. Песәй әйтә: «Я, иптәшләр, нишлибез инде? Мин суыкта түзә алмыйм, бер өй салып керик»,— ди. «Юк,— диләр тегеләр,— безгә өй кирәкми»,— диләр. Күркә белән торна әйтәләр: «Без тирәк башында кышлыйбыз»,— диләр. Үрдәк әйтә: «Мин суда да кышлыйм. Ком ашыйм, су эчәм»,— ди. Әтәч әйтә: «Миңа чүплек булса җитә, шунда берәр төшкә кунаклыйм»,— ди. Песәй әйтә: «Мин өйсез тора алмыйм, җылы кирәк, ди. Алай булса сез теләсәгез нишләгез, мин үзем йорт салам»,— ди песәй. Кирпеч ватыкларын җыеп өй сала, мич чыгара, тәрәзә, ишек тишә дә чыпта элә. Үзе рәхәтләнеп җылы мич башына менеп ята.

Башлана суыклар, буранлы көннәр.

Бер заманны моның ишеген кагалар.

— Песэй дус, керт эле, тышта бик суык,— ди-торна.

— Бар, үзеңнең тирэк башыңда кышла,— ди песэй.

— Алай кертмэсэң, өй түбэңне ачам, куптарам,— ди.

Кертэ моны, нишлэсен.

Бераз гына торган иде, күркэ кага.

— Песэй дус, бик өшим, ди, керт инде,— ди.

— Бар, үзеңнең тирэк башыңда кышла,— ди.

— Кертмэсэң, ишек чыпталарыңны йолкып бетерэм,— ди.

Тагын кертэ бу.

Килэ этэч.

— Песэй дус, керт эле, бик суык, буран, туңам,— ди.

— Чүплек башында кышла, нигэ миңа килдең,— ди.

— Кертмэсэң, тэрэзэ пыялаларыңны ватып бетерэм,— ди.

Кертэ тагын моны да.

Үрдэкнең дэ күле туңа да песэй өе янына килеп ишек кага башлый.

— Песэй дус, кышларга керт эле,— ди.

— Үзеңнең күлеңдэ кышла,— ди.

— Кертмэсэң, өй түбэсеннэн керэм,— ди.

Болар шулай бергэлэп бэлэкэй генэ өйдэ көн итэлэр. Үрдэк үзенэ бер чокыр ясап су китереп сала. Этэч, торна, күркэ киштэгэ куналар. Песэй мич башында ята.

Беркөнне кич белэн ут яндырып утыралар иде, ике дию пэрие килэ: «Кеше булырга тиеш бу өйдэ, тавышлары да ишетелэ»,— дилэр. Берсе эйтэ, син кер дип, икенчесе — син кер, ди. Керергэ куркалар болар. Шулай да берсе барып керсэ, килеп ябышалар моңарга. Күркэ белэн үрдэк килеп тэннэрен борып

алалар, торна диюнең башын чукый, песәй килеп битен тырный, әтәч киштәдә кытыйк-кытыйк дип кычкыра. Дию пәрие чак кына чыгып качкан ди. Иптәшенә әйтә:

— Әй, харап була яздым бит. Кайсы боттан, кайсы баштан, кайсы битне тырный. Аның өстенә берсе «тотыйк-тотыйк» дип кычкыра,— ди.

Ярар, шулай итеп җәйгә чыкканнар болар. Яңадан тау башына менеп яши башлаганнар ди. Песәй әйтә: «Инде борчак явы киткәндер, авылга кайтыйк»,— ди. Шуннан кайтырга юлга чыгалар. Песәй алдан кайта, аның артыннан әтәч, күркә, торна, үрдәк тезелеп кайтып китәләр ди болар. Бөтен халык карап торалар кая булган икән болар дип. Юлда торна, күркә үз урыннарында калганнар. Су буена җиткәч үрдәк калган, әтәч чүплек башында калган. Песәй үз өенә кайтып киткән. Җыелган халык арасында бер әби: «Мынау әтәчем ике ел югалып торды, каян килеп чыкты»,— ди. Үрдәк хуҗасы да: «Кайдан килеп чыкты үрдәгем»,— дип шатлана ди. «Әй, песәем, бик озак югалып тордың, каян гына кайттың»,— дип шатлана ди песәй хуҗасы да. Ә песәй: «Инде борчак явы килмәс микән?» — дип һаман мичкә карап тора ди.

ӘЛӘКЧЕ

Бервакыт арслан киек авырый башлаган. Барча җанвар, киек хайваннар арсланның хәлен белергә килгәннәр. Монда бары төлке генә булмаган. Бүре арслан патшага әйткән:

— И патша, хәл белергә килү түгел, төлке сине патша дип тә белми,— дигән.

Ул арада төлке дә килеп җиткән. Арслан, төлкене күреп, бик каты кычкырган:

— Әһә, син шулай икәнсең әле,— дигән.

Төлке әйткән:

— И солтаным, сүземне әйтергә рөхсәт бирсәнә,— дигән.— Мин шуның өчен соңга калдым: синең авырганыңны ишеткәч, доктор эзләп төрле якларга чабып йөрдем. Әмма дәва тапкач килдем,— дигән.

Арслан әйткән:

— Нинди дәва таптың соң? — дигән.

Төлке моңар әйткән:

— Әгәр син бүрене үтереп, аның җылы тиресенә чорналып ятсаң, хәзер тазарырсың,— дигән.

Арслан шул вакытта ук бүрене үтергән.

ӘТӘЧ ПАТША

Элек заманда бер табык кетәгендә яшәгән икән ди бер әтәч.

Бу әтәч ишегалдында түшен кабартып, як-ягына карангалап, әре генә атлап йөрергә ярата икән ди. Беркөнне шулай кукраеп йөргән-йөргән дә бер биек койма башына менеп баскан ди бу:

— Ки-ке-ри-күк! Ки-ке-ри-күк! Мин — шаһ-әтәч, патша-әтәч, мин — хан-әтәч, солтан-әтәч! — дип кычкыра башлаган ди.

— Чибәркәйләрем, сөекле карабикәләрем, чуарбикәләрем, акбикәләрем! Әйтегезче, дөньяда матурлардан матур кем матур, батырлардан батыр кем батыр?

Шул тирәдә йөргән табыклар: карабикәләр, чуарбикәләр, акбикәләр йөгерә-йөгерә җыелдылар ди моның янына. Җыелдылар да ди, төрле яктан җырлый да башладылар ди.

— Кая инде, кая инде ул безнең бөек ханыбыз белән тиң булу. Кая инде, кая инде ул безнең мактаулы шаһыбыз, сөекле падишабыз белән тиңләшерлек кеше? Юк, юк, юк, юк инде ул, ханыбыз, солтаныбыз, синнән акыллы да, синнән матур да, синнән батыр да юк инде бу дөньяда!

Әтәч тагын да көчлерәк итеп:

— Ки-ке-ри-күк! Ки-ке-ри-күк! — дип кычкырды да ди, тагын сорады ди болардан:

— Арслан тавышыннан да көчлерәк тавыш кемдә бар? Кемнең аягы куәтлерәк тә, кемнең киеме зиннәтлерәк?

— Кемнең булсын, синең киемең зиннәтлерәк, падишабыз, синең аякларың тимердән дә ныграк, солтаныбыз, синең тавышың арслан тавышыннан да гайрәтлерәк, куәтле ханыбыз,— дип җырлаштылар ди тавыклар.

Әтәч масаюыннан шартларга җитте ди. Шуннан соң кикриген тагын да югарырак чөеп җибәрде дә ди:

— Ки-ке-ри-күк! Ки-ке-ри-күк! Карагыз әле, хатыннар, дөньяда кемнең тәхете биегрәк тә, кемнең башындагы таҗы затлырак?— дип сорады ди.

Тавыклар йөгерә-йөгерә биек койманың янына ук килделәр дә ди, кукраеп утырган әтәчкә башларын иеп:

— Тәхетләрдән биек — синең тәхетең биек, таҗлардан затлы — синең таҗың затлы! Син бит безнең бердәнбер шаһыбыз, син бит безнең бердәнбер падишабыз! — дип әйттеләр ди.

Шул арада өйдән юан пешекче чыгып, аяк очларына гына басып койма янына килде дә ди, әтәчне эләктереп тә алды ди.

— Менә бәла! Менә кайгы!

Пешекче биленнән пычагын алып бөек шаһның башын чабып өзде дә ди, мактаулы ханның зиннәтле киемнәрен йолкып ташлап, җиңелмәс солтанның итеннән тәмле шулпа пешерде ди.

Ә кешеләр ашыйлар-ашыйлар икән дә, ашны мактап:

— Ай-яй, тәмле икән бу әтәч! Ай-яй, симез икән бу әтәч!— дип әйтәләр икән ди.

ЯБАЛАК

Ябалак чыпчыкны тотты ди. Чыпчык ябалактан сорады ди:

— Үлгәнче синең исемеңне белеп калыймчы, син кем буласың? — дип әйтте ди.

Ябалак авызын зур ачып:

— Ябалак! — дип кычкырган иде ди, чыпчык чыкты да ычкынды ди.

— Аһ,— дип әйтте ди ябалак,— авызымны ачмыйча, «ябәләк» дип кенә әйтәсе калган, ул чагында ычкына алмаган булыр иде,— дип әйтте ди.

КАРТ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

Бер авылда карт белән карчык бар иде. Бервакытны шушы карт базарга барып балык алды да кайтырга чыкты. Кайта торгач, караса, юлда бер үлгән төлке ята. Карт моңа бик куанды.

— Менә бәхет, мин бу төлке тиресеннән хатынга тун тектерермен,— диде, төлкене алып чанасына салды. Төлке балыкларны берәм-берәм чанадан ташлап бетерде дә шыпырт кына үзе дә төшеп калды.

Менә бер заман карт өенә кайтып җитте. Ишекне ачып хатынына кычкырды:

— Карчык, сиңа яңа тун тектерәм, як утка искесен! — диде.

Карт, төлкене алып керим дип, чанасы янына чыкса, чанада төлке дә юк, балыклар да очкан, мичтә карчыкның туны да янып бетеп бара.

КОРЫ КУАНЫЧ

Көннәрдән беркөнне бер кеше басу буенча бара икән, бер куян күргән дә үз-үзенә әйткән:

— Мин бу куянны, качып кына барыйм да, таяк белән бәреп үтерим, тиресе белән итен калага алып барып сатармын да акчасына бер кәҗә алырмын; аны һәйбәтләп ашатсам, ул дүрт бәрән китерер. Болар тагын дүртәрне бәрәнләп, кәҗәләр күбәеп җиткәч, аларның барысын да сатармын да, үземә яңа йорт салып, рәхәтләнеп торырмын. Эх!— дип бик каты кычкырган икән, куян куркып сикереп чыккан да урманга чапкан.

ҖИДЕ БАҖАНЫ БЕР БҮРЕ АШАГАН

Әүвәлге заманда бер кешенең җиде кызы булган ди. Ул җиде кызын җиде кияүгә биргән. Бер көн кызларын кияүләре белән кунакка чакырып барысына да тигез сый куйган, һәммәсен дә бертигез хөрмәт иткән. Алай булса да, кияүләрнең һәркайсы каенатасы белән каенанасына баҗаларыннан сөеклерәк буласы килә икән. Шулай берничә көн сыйланганнан соң болар өйләренә кайтып киткәннәр.

Кайта торгач, юлда боларга бер ач бүре очрап җиде баҗаның берсен ашый башлаган. Калган баҗалары эчләреннән әйтәләр, имеш:

— Әйдә, ашый бирсен, каенатабыз аны бигрәк яхшы сыйлаган иде, ул булмаса, мин сөеклерәк булырмын,— диләр, имеш. Аннан соң бүре икенчесенә ябышкан, соңыннан өченчесенә. Озын сүзнең кыскасы, шул бүре бу җиде баҗаны берәм-берәм һәммәсен дә ашап бетергән, имеш.

КУРКАК ЮЛДАШ

Элекке заманда ике кеше, иптәш кушылып, юлга чыкканнар. Боларга зур урман аркылы үтәргә туры килгән. Урманга кергәннәр икән, боларның каршысына кинәт кенә бер аю килеп чыккан. Моны күргәч, боларның берсе, бик куркып, агач башына менеп качкан. Икенчесе, үлгән булып, тиз генә сузылып яткан.

Аю, бу юлда яткан кешенең янында әйләнә-әйләнә, башларын, аякларын иснәгән дә ди, бер дә тимичә үз юлына киткән ди.

Аю киткәннән соң, әлеге кеше агач башыннан төшеп иптәшеннән сораган:

— Аю синең колагыңа шыпырт кына нәрсә әйтте? — дигән. Бу кеше әйткән:

— Аю миңа, моннан соң шушындый куркак кеше белән юлга чыкма, дип әйтте,— дигән.

ЧЫДАМАДЫ

Булган икән бер бай аучы. Бу бай аучы мактанырга, ялганларга бик ярата икән. Моның ялганына бер заман ышанмас булганнар. Шуннан соң бу бер ярлы аучыга әйбәт кенә бер бишмәт биргән дә әйткән:

— Мин ни генә әйтсәм дә, син дөресләп торырсың, яме,— дигән.

— Ярар,— дигән теге.

Шулай бер заман кибет янына халык җыелгач, бай аучы тотынган мактанырга.

— Мин, дигән, бервакыт шундый хәлгә очрадым, дигән. Бер атуда бер куян белән бер төлке үтердем, дигән. Төлке куян артыннан чаба башлаган гына иде, мин икесенә берьюлы төбәдем дә — шарт! — атып та җибәрдем. Икесе бер тиң мәтәлчек тәгәрәп тә киттеләр,— дигән. Моңар әйткәннәр:

— Юкны сөйлисең, андый хәл буламы соң,— дигәннәр.

Бу бишмәтен биргән теге ярлы аучыга күрсәткән дә:

— Ышанмасагыз, әнә сорагыз, ул да шунда иде,— дигән.

— Дөрес, бик дөрес,— дигән ярлы.

Бай аучы туктамаган, тагын сөйләп киткән.

— Икенче бервакыт шулай үрдәк белән карчыга тап булды. Карчыга үрдәкне эләктерим дигәндә генә,

мин мылтыкны күтәрәм дә — шарт! — икесе берьюлы аяк төбемә үк төштеләр,— дигән.

Халык ышанмагач, теге ярлы тагын дәреслэгән:

— Ялган юк монда, чын,— дигән.

Ә бай һаман сөйли, һаман мактана икән:

— Бер заман һавада киек казлар очып бара иде,— ди икән бу,— шул чакны әллә каян бер бәркет килеп тә чыкты, казлар өстенә аткан ук булып ташланды да булды. Мин аптырап калмадым, шундук — шарт! — атып та җибәрдем. Яным, җиде каз, бер бәркет килеп тә төште,— ди икән.— Ышанмасагыз, әнә сорагыз,— ди икән, тегенә күрсәтеп.

Шунда ярлы аучы чыдамаган, әйткән:

— Мә, бишмәтеңне, бай абзый, намусым күтәрми, җыен сөйләгәнең ялган, дигән.

ИКЕ ЯЛКАУ

Әүвәлге заманда булган ди бик ялкау ике кеше. Болар бер тапкыр барганнар ди урманга. Ул урманда бик тәмле җимешләр бирә торган алма агачы бар ди. Болар бара торгач шул алма агачын күргәннәр. Алма агачын күргәч, олырагы әйткән ди:

— Әйдә, без бу алма агачын селкетеп алмасын коеп ашыйк,— дигән. Кечерәге әйткән:

— Иренмичә аны селеккәнче, әйдә, ичмаса, астына кереп ятыйк,— дигән. Болар шулай дип алма агачының күләгәсенә кереп яттылар ди. Байтак яткач, олысы, карыны ачканга чыдый алмагач, тагы әйтте ди:

— Ай, авызыма бер генә алма төшсен лә!— диде ди. Кечесе әйтте ди:

— Авызга төшсә, аны иренмичә ашавы да бар бит еле, мин булсам, авызыма төшсә дә чәйнәмәс идем,— диде ди.

Шулай итеп, алар ач көе өйләренә кайтып киттеләр ди.

ЯЛКАУ ХАТЫН

Булган ди бер кеше, аның булган ди хатыны. Бер дә беркөнне бу кеше хатынын уракка җибәргән ди. Бу хатын басуга барган да ятып йоклаган ди. Кич кайткач, ире хатыныннан сорады ди:

— Күп урдыңмы, карчык? — дип. Хатыны әйткән ди:

— Урып-урмадым, карап тормадым, торып торна санамадым, өчәр-өчәр көлтәдән өч өем көлтә урдым,— дигән ди. Карты әйтте ди:

— Һәй рәхмәт, карчык, бик күп урган икәнсең,— дип әйтте ди.

Шулай итеп, ире мич башында ятып, хатыны басуга барып йоклап, уражлары кешедән артка калып, ашлыклары коелып бетте ди.

ЭЧТӘЛЕК

Акыллы кыз 3
Үги кыз 8
Башмак 12
Акыллы килен 16
Камыр батыр 18
Тимерче малае 22
Үткен карт 30
Өч сорау 32
Зирәк карт 34
Кем көчле? 38
Өч кыз туган 40
Күке кычкыргач, кәтүче хезмәт хакы ала 42
Хәрхәр 45
Шомбай 49
Диюләрне җиңгән 55
Йорт тотмас 59
Саран белән юмарт 63
Гөлчәчәк 67
Карчык белән аю 72
Үткен кияү 74
Хәйләкәр кеше 75
Яхшылыкка яманлык 78
Кәкре каенны терәткән 81
Шәрә бүре 82
Калач 88
Ак аю 90
Ай белән кояш 95
Шүрәле 97
Хәйләгә каршы хәйлә 99
Кәҗә белән сарык 100
Мәче, юлбарыс һәм кеше 102
Бака, тычкан, чабата 104
Аю, төлке, бабай 107
Хәйләкәр төлке 110
Батыр әтәч 112
Аю белән төлке 116
Кәҗә белән бүре 117
Хәйләкәр әтәч 121
Әтәч белән төлке 123
Аю, бүре, төлке 125

Песәй 127
Әвәкче 131
Әтәч патша 132
Ябалак 134
Карт белән тәлке 135
Коры куаныч 136
Җиде бажаны бер бүре ашаган 137
Куркак юлдаш 138
Чыдамады 139
Ике ялкау 141
Ялкау катын 142

ТАТАРСКИЕ НАРОДНЫЕ СКАЗКИ

(на татарском языке)

Редакторы Т. Нурмөхәммәтов

Художество редакторы Г. Трифонов

Техник редакторы С. Әхмәтҗанова

Корректоры З. Бикмөхәмәтова

Наборга бирелде 25/X-1973 ел. Басарга кул куелды 25/XII-1973 ел. Типография кәгазе № 1. 84×108¹/₃₂. Учетн.-изд. табагы 5,05+рәс. 0,44. Якынча басма табагы 7,56+рәс. 0,42. Заказ Я-514. Тираж 30000. Бәясе 35 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

35 тиен